ISSN 2618-9623

Төбәк тарихы буенча журнал
Краеведческий журнал

# Туган җир

## Родной край

4*2019

Из «Обращения к нации Временного председателя Комиссии по осуществлению автономии»

18 августа 1917 г.

«Если мы сейчас приложим все усилия, то наша, до сих пор угнетавшаяся, обездоленная нация станет навеки вечные свободной, независимой ни от кого нацией-героем. Если же мы не сумеем осуществить это теперь, то какое это будет горе, какая досада!

Дети великого тюрко-татарского народа, в эти, впервые в истории появившиеся светлые дни свободы, мы умоляем вас: отложим временно в сторону другие, более мелкие дела. Осуществим же совместными усилиями национальную автономию, являющуюся общим идеалом для нас всех. Да будет жить наш народ в будущих веках свободной, автономной нацией..

Если молодое поколение в дни нашей старости спросит нас: «Вы, отец, дед, какие большие дела совершили в вашей жизни?», каждый из нас сможет ответить: «Мы, мой сын, детям тюркского народа, живущим на севере, исповедующим религию Ислама, обеспечили, без расчленения государства, национальную свободу и национальную автономию. Рассыпанные везде, радующие наши глаза национальные школы, библиотеки, богатая национальная литература, национальные университеты, национальные ученые, – все это плоды наших забот и трудов, выполненных в 1917 г...».

..Да здравствует наша нация, [да] здравствует автономия!

Источник: 100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов. Казань: Изд-во «Заман», 1917. С.334.

Бөтендөнья татар конгрессы
Татарстан Республикасы татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте

# ТУГАН ҖИР

Төбәк тарихы буенча журнал

**4*2019**

Казан – 2019

Всемирный конгресс татар
Общество татарских краеведов Республики Татарстан

# РОДНОЙ КРАЙ

Краеведческий журнал

**4*2019**

Казань – 2019

УДК 908
ББК 26.89 (2Рос.Тат)
Т 70

**Баш мөхәррир:**
Дамир Мәүләви улы Исхаков,
тарих фәннәре докторы

**Главный редактор:**
Дамир Мавлявеевич Исхаков,
доктор исторических наук

**Баш мөхәррир урынбасары:**
Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы,
тарих фәннәре кандидаты

**Заместитель главного редактора:**
Бурханов Альберт Ахметжанович,
кандидат исторических наук

**Редакцион коллегия:**
Аблязов Камил
Акчурин Мәгъсум
Бәйрәмова Фәүзия
Гатауллин Ринат
Гариф Нурулла
Гыйләҗев Искәндәр
Габдрафиков Илдар
Закиров Ринат
Измайлов Искәндәр
Ситдиков Айрат
Сафин Фаиль
Тычинских Зәйтүнә
Хисамов Олег
Шәйдуллин Рафаил

**Редколлегия:**
Аблязов Камиль
Акчурин Магъсум
Байрамова Фаузия
Гатауллин Ринат
Гариф Нурулла
Гилязов Искандер
Габдрафиков Ильдар
Закиров Ринат
Измайлов Искандер
Ситдиков Айрат
Сафин Фаиль
Тычинских Зайтуна
Хисамов Олег
Шайдуллин Рафаиль

**Редакцион-нәшер итү төркеме**
***Җаваплы сәркәтип:***
Сәгыйдуллина Мөнирә Хәлим кызы
***Чыгарылыш өчен җаваплы***
Дәүләтшина Гөлнара Фарикъ кызы

**Редакционно-издательская группа**
***Ответственный секретарь:***
Сагидуллина Мунира Халимовна
***Ответственный за выпуск***
Давлетшина Гульнара Фариковна

**Басманың адресы:**
Казан шәһәре, Карл Маркс ур., 38/5
e-mail: Monitoring_vkt@mail.ru
Татар төбәк тарихы буенча кварталлык журнал
Татар һәм рус телләрендә

**Адрес издания:**
г. Казань, ул. Карла Маркса, 38/5
e-mail: monitoring_vkt@mail.ru
Ежеквартальный журнал по татарскому краеведению
На татарском и русском языках

ISSN 2618-9623

**Туган җир:** Төбәк тарихы буенча журнал [Родной край: Краеведческий журнал]. № 4. Казан: Бөтендөнья татар конгрессы. 2019.

## Эчтәлек

*Миңзифа Әхмәтшина.*
Тарих учагында. .......... 10
Ел йомгаклары һәм алдагы бурычлар. .......... 11

***Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары***

*Д.М. Исхаков.*
Халкыбызның эпик әсәрләрендә яшеренгән милли тарихыбыз. Өченче язма: «Чура батыр» дастаны һәм «киләчәк буыннарны кисәтү» (ахыры).. 13

*Р.Ф. Гатауллин, С.Ш. Аслаева.*
1990–2017-нче елларда Башкортостан Республикасындагы институциональ үсешнең төп контурлары.......... 34

*М.Х. Бакиров.*
Болгарга тоташкан тамырларыбыз (ахыры). .......... 40

***Төбәк тарихы буенча фәнни мәкаләләр***

*Н.Г. Гариф.*
Казан ханлыгы чорына караган эпиграфик ташларны барлау һәм аларга статистик анализ. .......... 51

*Ф.Ә. Бәйрәмова.*
М.Г. Худяковның Татарстан тарихына керткән өлеше. .......... 60

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова.*
Әстерхан татарларында үзенчәлекле сәнгать төре – хушавазлар.......... 73

***Фәнни-популяр язмаларда төбәк тарихы***

*С.Ә. Хөсәинов.*
Сәхип-Гәрәй ярлыгы хакында уйлану.......... 84

*Р.Р. Әскаров.*
Кыйгы Терегуловлары. .......... 97

*И.Д. Биккинин.*
XVII гасыр башында Мордовия үзәгендәге татар зонасы. .......... 108

*А.А. Хәбибиуллин.*
XX–XXI гасыр башы үзгәрү шартларында Идел буе Саратов татарларының туган телен саклап калуы. ..........117

*Р.З. Салиев.*
Исламга кайту. .......... 125

*Т.Т. Нигъмәтҗанов.*
Җиде муза-алиһә клубы (ахыры). .......... 133

*Д.Н. Таҗи.*
Кыям Җәгъфәров: автобиографик истәлекләр (ахыры). ............................ 144

*С.М. Газизьянова, Ф.Ф. Сабирьянова.*
Татар төбәкләре тарихын өйрәнүне үстерү һәм Мари Эл Республикасы татар авылларының туристик потенциалы. ................................................ 158

***Мирасыбызның төбәк тарихына кагылышлысы***

«Идегә» дастаны (дәвамы). ......................................................................... 164

*И.Г. Закирова.*
«Ак Күбек» дастаны .................................................................................. 173

***Олуг Татар иле***

*А.Н. Гәрәева-Акчура.*
Төркиягә күченүләр. .................................................................................. 187

***Шәхесләребез***

*З.А. Тычинских.*
Төбәк тарихын өйрәнүче каһарман. Гөлсинә Газизова турында. ............. 198

*Р.И. Маликов.*
Танылган ишан Әхмәр хәзрәт Юнысны (1765–1810) искә алу кичәсендәге чыгыш. .................................................................................. 203

*Г.М. Гайнетдинова.*
Татарның бөек улы Атнабай. ..................................................................... 210

***Татар рухы***

*Д.М. Гыйсметдин.*
Демократия. ................................................................................................ 213

*А.К. Галимова.*
Расти мажаралары. ..................................................................................... 214

*А.Г. Хәйретдин.*
Коръәндә бәян ителгән реинкарнация тәгълиматы турында (дәвамы)..... 219

***Юбилярлар турында сүз***

Авызга су кабып яшикмени?! Р. Минһаҗ белән әңгәмә. ........................... 236

***Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар***

Хроника. ...................................................................................................... 241

Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр форумы резолюциясе.... 246

Бөтендөнья татар яшьләре форумының Болгарның 1100 ел элек ислам динен кабул итүгә багышланган мөрәҗәгате ............................................ 251

Бөтендөнья татар яшьләре форумының Угра елгасында Торуны бәйрәм итү уңаеннан мөрәҗәгате......................................................................253

Башкортостанның Татар иҗтимагый үзәгенә – 30 ел. ................................ 255

***Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр***

*З.Г.Хәбипова.*
«Карәбәк» романы турында. ..................................................................... 260

Муса Абдуллинның «Ә наратлар шаулыйлар да шаулыйлар...» китабының аннотациясе. .................................................................... 265

***2019 елда журналда басылган язмалар исемлеге.***

***2020 елда басыласы басмалар.***

***Авторлар буенча белешмә.***

## Содержание

*Минзифа Ахметшина.*
На костре истории ........ 10

Итоги года и задачи на будущее ........ 11

***Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения***

*Д.М. Исхаков.*
Наша национальная история, запрятанная в эпических произведениях народа. Третья публикация: дастан «Чура батыр» и «предупреждение будущих поколений» (заключение). ........ 13

*Р.Ф. Гатауллин, С.Ш. Аслаева.*
Основные контуры институционального развития Республики Башкортостан в 1990–2017 гг. ........ 34

*М.Х. Бакиров.*
Наши корни из Булгар (заключение). ........ 40

***Научные публикации по краеведению.***

*Н.Г. Гариф.*
Учет эпиграфических (надгробных) памятников периода Казанского ханства и их статистический анализ. ........ 51

*Ф.А. Байрамова.*
Вклад М.Г. Худякова в историю Татарстана. ........ 60

*Л.Х. Мухамметзянова.*
Особый вид искусства у астраханских татар – хушаваз. ........ 73

***Краеведение в научно-популярных публикациях.***

*С.А. Хусаинов.*
Размышления над ярлыком ярлыка Сахип-Гирея. ........ 84

*Р.Р. Аскаров.*
Кигинские Терегуловы. ........ 97

*И.Д. Биккинин.*
Татарская зона начала XVII в. в центре Мордовии. ........ 108

*А.А. Хабибиуллин.*
Сохранение родного языка у татар Саратовского Поволжья в условиях меняющихся реалий XX – начала XXI вв. ........ 117

*Р.З. Салиев.*
Возвращение в ислам ........ 125

*Т.Т. Нигаматзянов.*
Клуб семи муз (заключение). ........ 133

*Д.Н. Тажи.*
Киям Жагфаров: автобиографические воспоминания (заключение)........ 144

*С.М. Газизьянова, Ф.Ф. Сабирьянова.*
Развитие татарского краеведения и туристический потенциал татарских сел Республики Марий Эл.............................................................................................. 158

***Наше историко-краеведческое наследие***

Дастан «Идегә» (продолжение). ..................................................................... 164

*И.Г. Закирова.*
Дастан «Ак Күбек» .......................................................................................... 173

***Magna Tartaria***

*А.Н. Гараева-Акчура.*
Переселения в Турцию. .................................................................................. 187

***Известные личности***

*З.А. Тычинских.*
Краевед, подвижник. Слово о Гульсине Газизовой. .................................. 198

*Р.И. Маликов.*
Выступление на вечере памяти известного ишана Ахмера хазрета Юнусова (1765–1810) .................................................................................... 203

*Г.М. Гайнетдинова.*
Атнабай – великий сын татарского народа. ................................................ 210

***Татарский дух***

*Д.М. Гисметдин.*
Демократия. .................................................................................................... 213

*А.К. Галимова.*
Приключения Расти. ....................................................................................... 214

*А.Г. Хайрутдинов.*
Введение в учение о реинкарнации, изложенное в Коране (продолжение). ................................................................................................ 219

***Слово о юбилярах***

Жить, словно воды в рот набрали?! Интервью с Р. Мингазовым. ............. 236

***Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики***

Хроника............................................................................................................ 241

Резолюция Всероссийского форума татарских краеведов. ........................ 246

Обращение Всемирного форума татарской молодежи в честь памятной даты 1100-летия принятия ислама Волжской Булгарией ......................... 251

Обращение всемирного форума татарской молодежи по поводу празднования Стояния на р. Угре ............................................................ 253

Татарскому общественному центру Башкирии – 30 лет............................ 255

***Информация о краеведческих трудах. Рецензии***

*З.Г.Хабипова.*
О романе «Карабек»................................................................................ 260

Аннотация книги Мусы Абдуллина «Ә наратлар шаулыйлар да шаулыйлар…». ........................................................................................ 265

***Список материалов, опубликованных в журнале в 2019 году.***

***Публикации, планируемые на 2020 год.***

***Сведения об авторах.***

*Минзифа Әхмәтшина*

## ТАРИХ УЧАГЫНДА

Тарих төпкелендә сүнмәс учак –
Кайнар буын тота ут йотып.
Томскиның нуры яктысына
Төбәкчеләр килгән җыелып.

Газиз халкым кичкән дәрьяларның
Дулкыннары кага ургылып...
Җилкәннәрен киереп алга бара
Ватанпәрвәрләре бер булып.

Өченче көн тоташ болыт тора
Себер өсләрендә өелеп.
Тарих битләреннән әрвахларның
Күз яшьләре тама күренеп.

*14.09.2019.*

## Редакциядән

## От редакции

### Ел йомгаклары һәм алдагы бурычлар

*Агымдагы ел үтеп бара һәм ул бер дә гадиләрдән булмады – алдан ук әйтелгәнчә, ел дәверендә уңышлар белән бергә милләтебез зур югалтулар да кичерде, беренче чиратта сүз туган телебезне саклау һәм үстерү мөмкинлекләренең нык кимүе турында бара. Әйе, әлегә татар җәмгыяте, безнең зыялыларыбыз һәм сәясәтчеләребез ул вәзгыятьтән чыгу юлларын инде таптылар дип әйтеп булмый. Димәк, бу өлкәдәге хәрәкәтебезне, туган телебезне коткаруны оештыруны, төрле ысуллар кулланып, дәвам итәргә кирәк. Барыбызга да аңлашылсын иде – тел мәсьәләсендә ярдәмне читтән көтеп булмый, милләтебез ана телебезне бернигә дә кармастан үзе актив кулланса гына гасырлардан безнең буыннарга мирас булып килеп җиткән бу төп «фикерләү коралын» саклап калып булачак.*

*Киләсе елда халкыбыз тагы бер зур сынау алдында торачак – 2020-нче елның октябрь аенда халык исәбен алу көтелә. Моңарчы булган ике (2002 һәм 2010-нчы еллардагы) исәп алу вакытында да татар милләтен таркату, аны вак кисәкләргә бүлгәләү теләкләре булды, хәзер дә андый сәясәтне алга сөрергә теләүчеләр ил үзәгендә юк түгел. Бу сәясәтне коручылар бик мәкерле ысуллар кулланалар – миллилек белән туган тел арасында булган бәйлелекне инкарь итү дисеңме, берьюлы шәхеснең ике этноска (халыкка) карау мөмкинлеге турында сүзләр куертумы, яисә халыклар исемлеген төзегәндә анда инде күптән юкка чыккан этник төркемнәрне кертүме, барысы да әйләнештә. Шуңа күрә дә безгә уяу булырга, үзебезнең йөзләргә еллар дәвамында формалашкан «мин – татар», – дигән милли аңыбызны югалтмау турында уйланырга кирәк. Әлегә без, татарлар, Россия Федерациясе эчендә сан ягыннан икенче урында торган милләт. Бу – сан мәсьәләсе генә түгел, ә безнең илебез тарихындагы урыныбызны билгеләүче күрсәткеч тә. Нәкъ менә шушы якны истә тотып эш иткәндә генә 2020-нче елгы халык исәбе вакытында халкыбызның демографик күрсәткечләрен элекке еллардан артыграк дәрәҗәгә җиткерә алачакбыз. Моңа ирешү җиңел булмаячак, чәнки хәзер барлык ил халыклары белән бергә татарлар да тискәре демографик чор кичерәләр – бала туу кимеде, үлүчеләр саны арта бара, шуңа да әйтелгән өлкәдә вэгыять катлаулы булып кала.*

*Ләкин алдага елда безне шатландыра алырлык вакыйгалар да көтә. Аларның иң зурысы – Татарстаннның 100 еллыгын бәйрәм итү булачак. Республикабызының бер гасырлык юбилее – гаять әһәмиятле чара, ул татар халкының милләт булып оешып (ингиз телендәге «милләт» – «nation» төшенчәсе, дәүләтле халыкка карата гына кулланыла) яши алганлыгын раслаучы тарихи билге. Бу дата белән бергә суверенитетыбызны кире кайтару турындагы Деклорация кабул итүгә (1990-нчы елда) 30 ел тулачак. Нинди генә чикләүләр булса да, халкыбыз әйтелгән ике бөек вакыйганы билгеләп үтәргә тиеш, чөнки алар безнең кемлегебезне бөтен дөнья каршында күрсәтүче даталар.*

*Ә инде эчке редакцион мәсьәләләргә килсәк, аларны чишү уңышлы дәвам итә – журналыбызның портфеле язмалар белән тулган, гаять кызыклы һәм тирән эчтәлекле мәкаләләребез бар. Басмабызда яңа рубрикалар да ачылачак – әйтик, шулар арасында шәһәр татарлары турындагы рубриканы атап китә алабыз. Алга таба татар ризыклары һәм төрле милли ашлар пешерү һәм сәламәтләндерү рецептларын бастыру да күздә тотыла (укучыларыбыз бу өлкәгә караган язмаларын туплап, хәзер үк безгә җибәрә алалар). Булачак мәкаләләрнең исемлеге шушы номер журналда бирелә, аны карап чыга аласыз.*

*Төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең тәкъдиме белән килешеп, 2020-нче елдан башлап иң уңышлы язмалар өчен өч премия биреләчәк: Сәет Вахиди (Вахидов), Михаил Худяков һәм Ризаэддин Фәхретдин (соңгысы – яшьләр өчен) исемендәге. Безнең өчен бу зур яңалык һәм уңышлы эшләү өчен стимул да була ала.*

*Шулай итеп, сездән, хөрмәтле төбәк тарихын сөючеләр, яңа язмалар көтеп калабыз.*

*Барыгызны да якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйбыз, алдагы елны Аллаһыбыз рәхмәтеннән ташламасын сезне.*

*Дамир Исхаков, баш мөхәррир*

## Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары

## Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения

*Д.М. Исхаков*

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЭПИК ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЯШЕРЕНГӘН МИЛЛИ ТАРИХЫБЫЗ.
## Өченче язма: «Чура батыр» дастаны һәм «киләчәк буыннарны кисәтү».

*(Ахыры. Башын карагыз: № 3, 2019)*

**Чура Нарыков – «волостель», «воевода», «большой князь».**

Югарыда Чура Нарыковның затлы аксөякләрдән булганлыгы һәм Казан ханлыгында 1526–1546-нчы еллар арасында «князь», ягъни, бәк (би/бәй) титулы йөрткәнлеге инде ачыкланган иде. Ләкин аның социаль статусын билгеләгәндә дастаннарда чагылган кайбер каршылыкларны аңлатырга һәм бу турыда тәгаен генә бер фикергә килергә кирәк булачак. Эш шунда ки, дастаннарда, бер яктан, Чура батырның югары социаль статусы турында әйтелсә, икенче яктан ул «кара» кеше буларак билгеләнә. Мәсәлән, Идел-Урал буенда язылган дастан версияләрендә Чура үзе турында әйтә:

Мән Чурамын, Чурамын,
Түрә түгел карамын, – дип [Татар халык иҗаты: 1984. 118 б.].

Шул ук хәл Добруджа (Буджак) татарларындагы эпос вариантларында да күренә:

Töre tuvil, qaraman.
Egiz tuvil, daraman [Bozcigit: 1988; Чура Батыр: 1993. 53 б.].

Кырым татарлары версиләрендә дә шул ук хәл – аларда әйтелә:

Тёре дегиль, къараманман, – дип [Къырымтатар: 1991. 69 б.].

Нугайлардагы «Шора баьтир» дастанында Чураның атасы Нарик улының Али бийне үтерүе турында сөйләгәндә, әйтә:

Хан казагын (ягъни, Али бийне – Д.И.) оьтирген,
Кадемсез бизим Шора увыл ды.
........................................................

Тоьре тувыл, кара оьлтирген кутылмас,
Меним улым эр Шора, – дип [Ногай халк: 1969. 71 б.].

Фәкать тик казахларда гына Чура батырга багышланган эпик әсәрләр циклында аның анасы Меңди ару Чура турында син «Асыл тұған Шорасың», «Ақ сұйек туған төресiн», – дип белдерә [Батырлар жыры: 1989. 344, 351 бб.], ә Әделшә исемле хан (Казан ханы буларак телгә алына) аның турында «Ақ сүйек туган баласың», – дип кенә түгел, ә «Атаң Нәрiк хан едi», – дип тә әйтә [Батырлар жыры: 1989. 354–355 бб.].

Чынлыкта бу очракларда дастанның казах версияләре дөреслеккә якынырак, чөнки Чура Нарыков «асыл туган» һәм «аксөяк» буларак аталырга хаклы. Ә менә аның «кара» буларак искә алынуы һәм «түрә» булмаганлыгы турындагы информация барыбер игътибарга лаек, чөнки бу төшенчәләр артында кайбер тарихи яктан әһәмиятле булган чынбарлык ята. Беренчедән, кабилә бәкләре нәселеннән булган Чура кабиләдәшләреннән югары торса да, кабилә лидерлары арасыннан иң бөек дәрәҗәләргә күтәрелгән (императорлар статусына җиткән) Чыңгызхан нәселе вәкилләре каршында (аларның нәселен юкка гына «Алтын ыру/уруг» дип атамаганнар) барыбер «кара халык» (борыңгы төркиләрдә – *«будун»*) арасында саналган. Икенчедән, инде алда күрсәтелгәнчә, «чура» төшенчәсенең «вассал», «хезмәттәге төркем вәкиле» дигән мәгънәсе булуы да дастандагы Чура Нарыков фигурасына бераз «кара төс» өсти булса кирәк (өстәмә рәвештә ул тенденцияне «чура» атамасының «кол» дигән мәгънәсе булу да көчәйтә дип уйлый алабыз). Бу ике сәбәптән тыш Чура батырның үзенчәлекле социаль статусының тагы бер аңлатмасы бар, әмма аның «төбенә төшү» бик үк җиңел түгел. Сүз менә нәрсә турында бара.

Чура батырга багышланган казахларда язып алынган дастан вариантларында аның төп герое турында бер билгеләмә бирелә: «артык туган Шора», «артык туган төре», «артык туган султан», «артык аргын» [Батырлар жыры: 1989. 328, 334, 338, 344–345, 354, 366 бб.]. Ни өчен соң бу дастаннарда «аргын» дип билгеләнгән Чура (түрә буларакмы, солтан буларакмы) «артык» буларак искә алына? Ул кайсы яктан «артык» булган? Бу сорауларга җавап дастан эченнән эзләнергә һәм табылырга тиеш. Моның өчен яңадан аларның төрле версияләренең эчтәлегенә керәсе була.

Инде әйтелә башлаганча, Чура батыр Идел-Урал буйларында язып алынган дастан версияләре буенча атасы белән анасы Хаҗитархан шәһәреннән (аңарчы атасы Нарәң батыр «Дагстан йортында» яши ахрысы) күчеп барганда туа һәм ул туган җир Кырымга якын яисә Кырымда ук була. Үсеп җиткән дәвердә дастан герое «Идел тарафына» да сәяхәт ясый һәм аннан кире Кырымга кайта, чөнки дастанда атасының «үз йорты» шунда дип күрсәтелә. Аннан соң, Кырымда Гали бине үтереп Нарәң

улы Чура батыр Казанга килә һәм гомере беткәнче шунда кала (дөрес, бер тапкыр Кырымга кайтып килә аннан) (карагыз: [Татар халык иҗаты: 1984. 108, 109, 111, 113, 115, 116, 117, 118 бб.]). Игътибар итик: төрле күчешләргә карамастан, Идел-Урал буйларында таралган дастан вариантларында Чура батырның атасының биләмәсе «Кырымда», – дип күрсәтелә, «Казанга», ягъни, Казан ханлыгына да, дастанның төп герое Кырымнан килә. Тагы бер мөһим әйбер – Чура батыр Казан ханлыгында хезмәт иткәндә (бәлки, ахырга кадәр түгелдер) аның атасы әле исән була һәм үзенең Кырымдагы биләмәсен җитәкли, аннан бер тапкыр Казанга килеп тә китә.

Әгәр дә без Добруджа (Буджак) татарларыннан язып алынган дастанга килсәк, анда Чура батыр Казанга шулай ук Кырымнан килә, аның атасы да анда яши һәм Нарыкның җирләре «Көкешле Тамга» исемле кала янында булып, бу биләмәнең Кырым ханлыгы белән Казан ханлыгы чикләренә якын икәнлеге беленә. Алай гына да түгел, Чураның атасы Нарык үз вакытында Көкешле Тамгадагы биләмәгә «Казан ханлыгыннан» күчеп килгән дип белдерелә дастанның тикшерелә торган версиясендә. Шуңа күрә дә Чура Али (Гали) бәйне үтереп «Казан дигән илгә» китәргә карар кылгач, ул үзенең «атасы йортына», дөресрәге, элегрәк дәвердә аныкы булган биләмәгә, киткән булып чыга [Чура Батыр: 1993. 23, 283, 30, 32, 33, 44, 45, 50, 53, 54, 55, 56, 59–60 бб.]. Бу очракта да Чура батыр Кырымнан Казанга күчкәндә аның атасы әле исән була.

«Чора батыр» дастанының кырым татарлары арасында язып алынган вариантларында да Чураның атасы Нарик Кырымда, Көкешле Тамгада яшәде, – дип белдерелә, ә дастанның герое «Казанга казак булып» чыгып китәргә мәҗбүр булганда, аның атасы Көкешле Тамгада кала. Чура батыр Кырымнан китү өчен юлга чыкканда яңа биләмәдә, ягъни, Казан ханлыгында, «хан итсәләр, һич булмам, бәй итсәләр дә, анда һич тормам», – дип белдерә [Къырымтатар: 1991. 61–62, 66, 67, 69 бб.]. Күренә ки, кырым татарлары версиясендә Добруджа татарлары версиясе белән кайбер каршылыклар бар, ләкин бер ягы белән алар охшаш – Чура б. Нарык Казанга Кырымнан килә һәм ул Кырымны ташлап чыкканда аның атасының биләмәсе Көкешле Тамгада булып, Нарик батыр әле исән була.

Эпосның нугай версиясендә шул ук күренеш: Шора батыр Кырымда Али бийне үтергәч, Казанга килә, ләкин ул башта бу юнәлешкә китүне төшендә күрә. Улы Казанда яшәгәндә, Нарик аның янына килеп китә. Нарик әле улы Казанга җыенганда ук, аңа әйтә: «Казан элдә хан болсанъ», – дип. Бу илгә чыгып китүне дастан «казак шыгу» буларак кабул итә [Ногай халк: 1969. 71, 72, 74, 78–79 бб.]. Кызыгы шунда, дастанның шушы версиясендә Али бийне үтереп, Казанга җыенганда, дастан герое үзен «Нарик улы мен Шора», – дип атаганнан соң, өстәп куя: «Анамнан арам

тувган болайым», – дип [Ногай халк: 1969. 68 б.]. Бу җөмләнең мәгънәсе инде безгә таныш булган «артык туган» төшенчәсенә якын булса кирәк.

Хәзер безгә дастанның казахларда сакланган вариантларын күзәтү кирәк, чөнки аларда башка милли версияләр белән туры килмәүче аерымлыклар сакланган. Беренчедән, бу эпик әсәрнең казах варианталарында Нәрик (Нарык) турында аның «туган җире» Казан шәһәрендә иде, ул анда хәтта «хан» да булып торган, – дигән фикер әйтелә, ә аның ул төбәктән читкә (далага) китүе Али бийне үтерүе белән бәйләнелә (карагыз: [Батырлар жыры: 1989. 306–307, 313, 327, 334, 354 бб.]). Кайбер дастан варианларында исә бу бийне үтерүче дип Шора үзе күрсәтелә [Шунда ук: 333 б.]. Икенчедән, өйрәнелә торган дастан версияләрендә Шора (Ер-Шора) инде атасы каядыр «далада», аерым бер «төбәдә», хан булып утырган җирдән Казанга юнәлә. Аның анда китүенең дастанның казах вариантларында берничә сәбәбе күрсәтелә: 1) Шора Казанны «кяферләр алмасын», атасының «алтын тагы» – бу безгә таныш «алтын тәхет» инде – «яу кулында калмасын», – дип бара анда; 2) Ул Казан ханы булган Әдилшәнең Ханҗан атлы кызын хатынлыкка алу өчен дә китә бу җиргә [Шунда ук: 332–334, 352 бб.]. Шушы тарафка юнәлгәндә, Шора «Казанга хан боламын», – дип бара. Аны Казан җирендә каршы алган Әдилшә хан «Шора» дастанында Шораның атасы Нәрикнең анда туганлыгын һәм Казанда элек хан булып торганлыгын таный [Шунда ук: 354 б.].

Шулай итеп, Чура батырга багышланган дастаннарда аның атасының ватаны турында берничә аңлатма табабыз: ул башта Кырымнан тышта (Дагстанда, Хаҗи-Тарханда, Казанда, яисә далада) яши, аннан соң гына Кырымга килеп төпләнә. Күпчелек очракта аның улы Чура батыр Казанга Кырымнан килә. Ләкин, аның каяндыр Кырымнан читтә булган дала җирләреннән чыгып, Казанга бару мөмкинлеген дә күрсәтә «Чура батыр» дастаны. Димәк, дастан героеның Казанга ике төбәктән килү мөмкинлеге бар: берсе Кырым, икенчесе – конкретлаштырылмаган «дала җирләре». Соңгысы әһәмиятле, чөнки Чура батырның Кырымнан чыгуын алга чыгарган Идел-Урал буе татарлары арасында язып алынган дастан версияләрендә дә аның «Идел тарафында» йөреп кайтуы турында әйтелә. Ахрысы, Чура Нарыков Казанга туп-туры Кырымнан килеп урнашмаган, ә берникадәр вакыт «казак булып» яшәп анда барып җирләшкән. Ни өчен соң барлап чыгылган детальләр әһәмиятле? Чөнки алардан башка Чура батырның «артык туган» булуы турындагы мәгълүматны аңлатып булмый. Хәзер инде ул мәсьәләгә аерым рәвештә тукталу кирәк.

Башлап шуны искәртик: Алтын Урда таралганнан соң барлыкка килгән татар ханлыкларында аларның сәяси нигезен тәшкил иткән карачы бәкләр бирүче 4 кабилә системасында һәр кабилә аерым биләмә (бәйлек) тәшкил иткән һәм ул биләмәләрне шул кабиләләрнең лидерлары (титул-

лары – бий, бәй, бәк) җитәкләгән. Билгеле, кабилә лидеры берәү генә була ала. Шуның өстенә, һәрбер кабиләдә аны җитәкләүче затлы нәселнең тарихы ким дигәндә Чыңгызхан дәвереннән башланып (карагыз: [Дәфтәре: 2011]), башка нәсел вәкилләре белән алмаштырыла алмаган. Моның шулай икәнлеген Идегәй нәселенең, ягъни, мангыт кабиләсе лидерларының, дәвамлы һәм шактый яхшы билгеле булган тарихы бик ачык күрсәтә. Әмма, нәсел дәвамчылыгы мәсьәләсенең бер нечкәлеге бар – әгәр дә кабилә бүленеп төрле дәүләтләргә таралса (Алтын Урда җирлегендә бу еш кына шулай булган да), хөкем итүче бәкләр нәселе дә шул кабилә кисәкләре белән бүленеп чыгып, яңа урыннарда аерылган төркемнәрнең башларына басканнар. Аргын кабиләсе мисалында без мондый хәлне инде күрдек – Туктамыш ханнан һәм аның улларыннан соң тәхеткә килгән Олуг-Мөхәммәт дәверендә ул кабиләнең бер өлеше Кырымда кала, ә икенче бер төркеме элекке кабилә лидеры Кара-хуҗа бәк җитәкчелегендә Казан якларына күчә. Билгеле, мондый бүленгән нәсел аксөякләре арасында туганлык җепләре сакланган һәм аларның шәҗәрәләре, дәүләт чикләреннән чыга торган үзара элемтәләре аркылы, бу нәсел вәкилләре әлеге туганлык турында хәбардар булганнар. Шуңа күрә дә, аерым ханлыкта хөкем итүче карачы бәкләр белән бәйле кабиләләрдәге лидерларның нәселе өзелсә (мәсәлән, ир җенесеннән булган балалары калмаса), шул ук нәселәдән һәм кабиләдән булган аксөякне башка ханлыктан китереп бәклеккә билгели алганнар (моның өчен ханнарның карары кирәк булган). Билгеле, мондый очракта карачы бәкләр бирүче кабилә лидерының төп варислары түгел, ә улларының, яисә башка туганнарының балалары арасыннан берсен сайлап алып читкә җибәргәннәр. Ягъни, бу шәхескә чынлыкта үзләрендә «урын» биләү – бәклек статусын алу – мөмкинлеге булмагач, ул «артык» аксөяккә әйләнгән. Моңа тагы өстәп әйтергә кирәк – Кырым ханлыгы тарихыннан безгә мәгълүм: һәрбер солтанның үз сарае һәм аңа бәйле аксөякләре булган, шул исәптән, карачы бәкләр нәселеннән дә. Алар бу солтан белән ул тәхеткә килсә югарырак дәрәҗәгә дә күтәрелә алганнар. Әгәр дә ул солтан башка дәүләткә китеп хан дәрәҗәсенә ирешсә, аның янындагы аксөякләр аның белән бергә китеп тә бара алганнар. Мондый үзгәрешләр хан алмашкан вакытта да була алган. Онытмыйк: Алтын Урданың варислары булган барлык татар ханлыкларының җирләре «Алтын урук» вәкилләренең, ягъни Чыңгызыйларның, һәм аларга «беркетелгән» карачы бәкләр бирүче кабиләләрнең, уртак биләмәләре саналган. Бигрәк тә бу уртаклык Кырым, Касыйм һәм Казан ханлыкларына карый, чөнки нәкъ менә шуларда бер үк нәсел Чыңгызыйлар (Туктамыш хан нәселе) һәм бер үк төркем кабиләләр (аргын, барын, шырын, кыпчак) хөкем иткәннәр.

Әйткәннәрдән чыгып без шундый гипотеза формалаштыра алабыз: Чура батырның «артыклыгы» бәлки аның Али (Гали) бәйне үтерүе белән генә бәйле булмагандыр. Чөнки дастан буенча ул аңарчы да Идел тарафына китеп йөри, аның атасы да каядыр далада казак булып ала. Бу мәгълүмат Нарык батырның һәм аның улы Чура батырның аргын кабиләсе лидерлары нәселенә бәйле булсалар да, бәлки аларның «өлкән» тармагыннан булмыйча, яисә, сәяси сәбәпләр нәтиҗәсендә (мәсәлән, хан алмашудан) ул статусларын югалткан булулары турында сөйләми микән? Шундыйрак юнәлештә фикерләү өчен берничә нигез бар. Беренчедән, Чура батырның Идел-Урал буйларында язып алынган һәм алда китерелгән шәҗәрәләрендә аның башка ир туганнары да булганлыгы күренә. Икенчедән, Кырымда язып алынган «Чорабатыр» дастаныныда Нарикның Арик исемле агасы булуы турында әйтелә [Кърымтатар: 1991. 57б.]. Ә бу бит «өлкәнрәк» буын вәкиле. Кырымдагы аргын кабиләсе бәкләренең башка тармагы булганлыгы турында Кырым ханлыгы җирлегендә яшәгән инде китерелгән Кара-Коджа бәктән башланган шәҗәрә дә сөйли. Казахлар арасында язып алынган һәм русчага тәрҗемәдә сакланган «Тама» төркеменә багышланган дастанда да бертуган өч шәхес атала: өлкәне – Кариббай (Кара би?), уртанчысы – Нарикбай (Нарик би), кечесе – Исым бий [Сборник. Т.IV: 1895. С.2]. Күренә ки, монда да Чура батырның атасының ике ир туганы (берсе олырак, икенчесе кечерәк) атала. Әмма, башка бер казах телендә сакланган шул ук «Тама» дастанында бу исемнәр нишләптер искә алынмыйлар (карагыз: [Батырлар жыры: 1989. 271–285бб.]). Шуңа да карамастан, без югарыда китерелгән информацияне, шул исәптән, Кырым ханлыгы буенча билгеле тарихи чыганаклардан чыгып та, алга таба кулланырга тиешбез. Мәсәлән, инде әйтелеп үтелгәнчә, 1519-нчы елны Кырымда берьюлы ике аргын кабиләсеннән булган аксөяк – Али-Шукур һәм Корбан-Али «князь» титулы белән билгеләнә. Шулар ук 1524-нче елга караган Кырым ханлыгы аксөякләре исемлегендә дә күренәләр [Малиновский: 1863. С.115]. Ә бит аларның берсенең – Али Шукур бәкнең – исеме Кырымдагы аргын кабиләсе бәкләренең Кара Коджа бәктән башланган шәҗәрәләрендә бар. Димәк, бу очракта сүз шушы кабилә лидеры турында бара 1519, 1524-нче еллардагы документларда. Әгәр дә мондый нәтиҗәдән чыгып эш итсәк, ул вакытка кабилә лидеры Али-Шукурның замандашы Корбан-Али бәкнең («князьнең») статусын ничек билгеләргә соң, аны бит аргын кабиләсенең башлыгы дип карап булмый, чөнки берьюлы ике шәхес кабилә бәге урынында утыра алмый. Ахрысы, Корбан-Али «бәк» титулын башка юл белән алган. Әйтик, ул үзе, яисә аның атасы Кырымга башка ханлыктан инде «князь» (бәк) титулы алганнан соң килеп төпләнгән була ала. Һәрхәлдә, мондый гипотезага урын бар. Әйтергә кирәк, ул ханлыклар астында Казан,

яисә Касыйм биләмәләре күз алдында тотылырга мөмкин. Ничек кенә булмасын, безгә яңадан Кырым һәм Казан ханлыклары җирлегенә кире кайтканда китерелгән фикерләрне истә тотарга кирәк.

Сүзне Казан ханлыгыннан башларга туры килә, чөнки инде алда әйтелеп үткәнчә, нәкъ шушы биләмәдә 1521-нче елдан башлап тәхеткә Гәрәйләр династиясе вәкилләре утыртыла: 1521–1524-нче елларда анда хан тәхетен Сәхиб-Гәрәй, аннан соң аның энесе Сафа-Гәрәй 1524–1531, 1533–1546, 1546–1549-нчы елларда аерым өзеклекләр белән билиләр. Бу уңайдан мондый фикер туа: беренче тапкыр Казан ханлыгы җирләрендә 1526-нчы елны күренгән Чура б. Нарык шушы Гәрәй династиясе вәкилләре белән килеп чыкмаган микән монда? Бик мөмкин, бигрәк тә ул Кырымда «артык» булган булса һәм аның атасының (яисә бабаларының) Казан йортында электән дә биләмәләре яшәп килсә. Чура батырга караган дастанның кайбер урыннары моңа ишарә ясыйлар. Әйтик, Чура батырга багышланган Добруджа (Буджак) татарларында һәм казахларда язып алынган дастан версияләрендә геройның атасының биләмәсе итеп «Казан» күрсәтелә. Дөрес, соңыннан ул ниндидер сәбәпләр аркасында Кырымга килеп төпләнә (бу версия казахларда күренми). Менә бу Нарык батырның бер дәвер «Казанда» яшәгәнлеге турындагы информацияне без игътибардан читтә калдыра алмыйбыз. Дөрес, конкретлаштырылмаган мондый сюжет артында Казан ханлыгы җирлегендә аргын кабиләсенең аерым биләмәсе (бәклеге) булуы турындагы гомумиләштерелгән информация да ятарга мөмкин. Ә андый биләмә бар икән, аның башына Казанда династия алмашынганда (Гәрәйләр тәхеткә килеп утырганда) Кырым ханлыгыннан андагы аргыннар арасыннан чыккан затлы аксөяк тә китереп куела алган, моны истә тотарга кирәк. Шуны да онытмыйк: 1487–1518-нче еллар арасында Казанда тәхет өчен барган көрәшләрдә (анда 1496-нчы елны Шибанид Мамук та катнаша) төрле ханнар белән бәйле төп кабилә лидерлары «урынсыз» калган булырга бик тә мөмкиннәр. Бәлки шул дәвердә Чура батырның атасы Нарык, яисә аның бабасы, Казан ханлыгыннан читкә китеп барырга мәҗбүр булгандыр. Әйе, бу бер фараз гына, ләкин буш урында ясалган гипотеза түгел. Тагы бер тарихи фактны истән чыгармыйк – 1515-нче елны Кырым ханлыгы тәхетендә озак еллар утырган Меңгли-Гәрәй үлгәч властька килгән аның улы Мөхәммәд-Гәрәй 1523-нче елны Хаҗитарханда зур җиңүләрдән соң мангыт кабиләсе аксөякләре тарафыннан көтелмәгәндә үтерелгәч (карагыз: [Смирнов. Т.I: 2005. С.299–300], Кырымда сәяси тотырыксызлык килеп чыга. Бәлки кайбер мондагы аксөякләрнең читкә китүләре өчен дә бу вакыйгалар сәбәп булгандыр. Һәрхәлдә, Чура батырның атасы Нарыкның бер дәвердә «Хаҗитархан шәһәренә» килүе турындагы дастандагы хәбәр юкка гына булмас.

Шулай итеп, Чура б. Нарык Казан ханлыгында төпләнә һәм «Казанская история» исемле рус чыганагы аның турында ул «волостель», «воевода» һәм «большой князь» иде дип белдерә. Хәзер без бу төшенчәләрнең чын мәгънәләрен ачып сала алабыз.

*«Волостель»* – һичшиксез, бу термин артында төрки телдәге «олыс/улыс/улус» сүзе ята (әйтелгәнчә, русчадагы «волость» сүзе дә шуннан ясалган). Аңлашыладыр, «волостель» ул «улыс биләүче» булып чыга. Димәк, чынлыкта нәкъ шушы төшенчә Чура батырның Казан ханлыгында булган бер олысны, ягъни бәйлекне (бәклекне) биләгәнлеген күрсәтә. XVI–XVII-нче йөзләрдә, инде руслар Казан ханлыгын буйсындыргач, ул биләмә «Галицкая дорога (даруга)» дип аталган. Аның сәяси үзәге чиратлап Казаннан ерак булмаган Караби (Караваево) һәм Кара-Хуҗа, Җәке авылларында булган дип уйлый алабыз. Иделнең сул ягында (уң ягындагы чикләрен әлегә төгәл билгеләп булмый) бу биләмәнең чикләрен якынча чамаларга була [Исхаков: 1998. С. 42–56].

*«Большой князь»* – төшенчәсе турыдан-туры төрки-татар теленнән алынган «олы/олуг бәк/бий», яисә Кырым ханлыгы өчен хас «баш карачы [бәк]» [Inalcik: 1979–80. P. 447] терминыннан калька булып тора. Димәк, бу атама Чура б. Нарыкның Казан ханлыгында карачы бәк булганлыгын раслый. Тагы шунысы да читтә калмасын: Кырымда ике кабилә бәкләре – шырын һәм барын лидерлары, калган икесеннән (аргын һәм кыпчак кабиләләреннән) өстенрәк саналган [Сыроечковский: 1940. С. 29; Manz: 1987. P. 286]. Бу исә борынгы традиция белән бәйле булса кирәк. Казан ханлыгында да шул ук хәл күзәтелгәнме, бусы билгеле түгел. Әмма, Чура Нарыков кул астында булган гаскәриләр саныннан чыгып карасаң (алга таба сөйләнәчәк ул турыда), монда да аргыннар икенчел дәрәҗәдә булганнар дип уйлый алабыз.

*«Воевода»* – безнең фикеребезчә, бу төшенчәнең төрки эквиваленты – «батыр» дигән сүз. Ләкин аның шулай икәнлеген раслау өчен безгә кайбер Кырым ханлыгына кагылган тарихи чыганакларга күз салу кирәк. Иң башлап, игътибарны үзенә җәлеп иткән мондый информация бар: 1508-нче елны Кырым ханы Меңгли-Гәрәйнең Мәскәүгә җибәрелгән хатында (ул рус теленә тәрҗемәдә генә сакланган) 4 «князь», ягъни карачы бәкләр турында (Ширин Агиш, Барын Давлет, Аргын Мардан һәм Кыпчак Магмуд), «воеводы князи» дигән аңлатма бар [Малиновский: 1863. С. 185]. Китерелгән төшенчә «Идегәй» дастанындагы «Орыш бие Шырын» [Идегәй: 1988. 221 б.] сүзтезмәсенә мәгънәви яктан туры килә һәм бу бер дә юкка гына түгел, чөнки карачы бәкләр җитәкчелегендәге «кабилә гаскәрләре» татар ханлыкларында гвардия ролен үтәгәннәр һәм дәүләтнең хәрби көченең үзәген тәшкил иткәннәр. Шуңа күрә дә карачы бәкләр белән аларның кабиләдәшләреннән (гадәттә, 10–12 меӊ профессиональ сугышчылардан)

торган гаскәри төркем ниндидер сәбәпләр аркасында ханга каршы чыкса, ул хөкемдар бернәрсә дә эшли алмаган (карагыз: [Инальчик: 1995. С. 76–77]). Чура батырга багышланган дастаннардан да мондый үзенчәлек бик ачык күренә – бу затлы татарның төп «һөнәре» сугыш белән шөгельләнү булган. Сакланып калган рус чыганаклары да шул турыда сөйлиләр. Алардагы бер хәбәрдән (1540-нчы елга карый) Чура Нарыковның 8 мең кешелек гаскәр башында торганлыгы күренә, ләкин ул яуда татарлардан башка марилар һәм чувашлар да катнашкан, шунлыктан, аның татар өлешенең саны азрак булган булса кирәк. Кайбер Чура батырга багышланган казахларда язып алынган дастан версияләрендә аның герое һәм атасының кече энесе Исым бий, шулай ук безгә билгесез Тосан мурза, җитәкләгән гаскәрнең саны 6 мең сугышчыдан тора иде дип билгеләнә [Сборник материалов. T. IV: 1895. С. 86]. Чынлыкта исә реаль Чура бәкнең сугышчылары саны ул кадәр үк күп булмаган дип уйларга урын бар, чөнки «Казанская история» аның Казаннан качып китү эпизодын сурәтләгәндә аның белән 1000 «сугышчы» һәм 500 «хезмәтче коллары», ягъни, тулаем 1500 кешелек хәрби берләшмәсе булуы турында сөйли [Казанская история: 1954. С. 81]. Алда Кырым ханлыгы буенча да шуңа охшаган сан күренгән иде – 1543-нче елны берләштерелгән аргын һәм кыпчак кабиләләренең яуда катнашкан гаскәриләре саны 3000 кеше булганлыгы турында әйтелде. Әгәр дә без фараз буларак бу ике кабиләдән бертигез санда сугышчылар чыгарылган дип уйласак, Чура батыр гаскәренең Казан ханлыгындагы саны килеп чыгачак.

Шулай итеп, Чура Нарыков чынлап та «воевода» – «батыр», булып чыга. Аның «ир» дип аталуы да шул ук мәгънәгә ия, чөнки бу төшенчәнең дә эчтәлеге шундый ук (карагыз: [Орлов: 1945. С. 8]).

Чура батыр турында тупланган яңа мәгълүматка таянып, хәзер аның якты дөньядан китүе эпизодына да кире кайта алабыз. Әйтелгәнчә, бу мәсьәләне тикшергәндә без тарихи чынбарлык белән легендар (эпик) тасвирлау арасындагы аермалык белән очрашачакбыз. Әгәр дә шушы аермалыкның асылына төшенә алсак, без Казан ханлыгы егылу дәверендәге татар җәмгыятенең этник аңын, тарихи фикерләүен күзаллый алачакбыз. Нәкъ менә шул вакытта «Чура батыр» дастанына салынган киләчәк буыннарны «кисәтүнең» төп мәгънәсе дә аңлашылачак.

**Чура батырның үлеме һәм киләчәк буыннарны кисәтү.**

Чура Нарыковның үлүе мәсьәләсе тирәсендәге легендар һәм мифологик катламнардан арынып тарихи чынбарлыкны торгызу өчен башта яңадан рус чыганакларына мөрәҗәгать итү кирәк булачак. Ләкин бу очракта ул чыганакларны, алдарак ясалган анализлардан аермалы буларак, бик конкрет тикшерергә кирәк. Ә бу тикшерү исә Чура батырга багышланган дастан версияләреннән һәм тарихи легендалардан башка мөмкин түгел,

чөнки бүгенгә билгеле булган рус чыганакларының безне кызыксындырган проблема буенча информацион мөмкинлекләре бик чикле.

Алдарак без Чура Нарыковның үлүе турында хәбәр иткән ике рус чыганагына – «Патриарх (Никон) елъязмасына» һәм «Казанская история» («Казанский летописец») исеме астында билгеле булган «тарихи повесть» жанрына кагылган, 1564–1565-нче елларда язылган, әсәргә – игътибар иткән идек инде. Хәзер исә алардагы мәгълүматка әйләнеп кайтып, элегрәк читтәрәк калган мәсьәләләргә дә тукталу кирәк.

Әйтик, аларны тикшергәндә ясалган беренче нәтиҗә – Чура Нарыковның үлеменең 1546-нчы елның июль ае урталарына (бусы безнең фараз иде, ул алга таба бераз төзәтелергә тиеш) туры килүе һәм аның Казан ханлыгы тәхетенә кире кайткан Сафа-Гәрәй тарафыннан үтерелүе турында иде. Бу информациянең «Патриарх (Никон) елъязмасына» килеп керүе, андагы хәбәрдән күренгәнчә, 1547-нче елның 20 сентябренә карый һәм ул хәбәр Мәскәү Бөек князьлегенә Казан ханлыганнан эмиграцияга киткән бер төркем (76 кеше) татарлар тарафыннан алып килenә. Ягъни, хәбәрнең елъязма битләренә эләгүе белән реаль вакыйга арасында инде бераз вакыт үткән булган. Әмма, хәбәрне җиткерүчеләр арасында Чура Нарыковның энеләре дә булуын истә тотсак, аның Сафа-Гәрәй хан карары белән үтерелүенә (күргәнебезчә, ул вакытта башка затлы татарлар да җәзалана) шөбһә калмый, чөнки аларның мәскәүлеләрне бу мәсьәлә буенча алдаулары өчен бернинди объектив сәбәп тә күренми.

Шулай булса да, «Казанская история» әсәрендә беркадәр уйландыра торган башка бер информация бар. Нәрсә күз алдында тотыла соң бу очракта? Ә менә нәрсә истә тотыла. Әйтелгән чыганактан күренгәнчә, Шаһали качып киткәндә (исегезгә төшерик, аңа нәкъ шул чакта Чура Нарыков ярдәм итә), аның боерыгы буенча зур бәйрәм (җыен булса кирәк) вакытында исереп, йоклап яткан «казанлыларның» 20 аксөяге («большие вельможи») үтерелә, ә 20 шундый ук дәрәҗәле аксөякне ул үзе белән бәйләп – богаулап алып китә [Казанская история: 1954. С. 81]. Иртәгесен хан сараена килгән татарлар анда үлеп ятучыларны күргәч, ханның качып киткәнлеген аңлап алып, Шаһали артыннан куа чыгалар, аны тота алмагач, үзара каршылыкка килеп, бер-берсе белән сугышалар һәм ахыр чиктә килеп чыккан хәлдә Чура Нарыковны гаепли башлыйлар, әмма, аның батырлыгын һәм акылын танучылар да Казанда әле җитәрлек була [Казанская история: 1954. С. 82]. Шушы вакыйгалар барганда, бу чыганак буенча, ул Шаһали ханнан соң 10 көн үткәч, үзенең биләмәсендәге авылларына ялга китәм дигән булып (җәй көннәре бит!), Мәскәү ягына зур төркем белән кача һәм алдан сөйләшенгәнчә, билгеләнгән урында Шаһалине көтә башлый. Менә шул вакытта Чура Нарыковның качканлыгын аңлап алган аны куа чыккан казанлылар

бу бәкнең лагерена барып җитәләр. «Казанская история» алга таба сөйли: «...казанцы ...догнавше (Чураны – Д.И.). Он же, обострожася в месте крепце, чаяхся отбити от них; и бившеся с ними долго. И убиша храброго своего воеводу Чюру Нарыковича с сыном его, и со всеми отроки его...» [Казанская история: 1954. С. 82]. Игътибар итегез, тасвирланган эпизодта Сафа-Гәрәй турында бер сүз дә юк, әмма казанлылар гаскәренең аз санлы булмаганлыгы ачык. Әгәр дә «Казанская история» авторы бу дәвердә Казан ханлыгында яшәгән булса, ни өчен ул Чура Нарыковның үлеме турында сөйләгәндә Сафа-Гәрәй турында бер сүз дә әйтми? Гомумән, Сафа-Гәрәй Чура батырның гаскәре белән сугышта катнашканмы соң?

Бирелгән сорауларга җавап бирү җиңел түгел. Әгәр дә «Патриарх (Никон) елъязмасына» мөрәҗәгать итсәк, 1546-нчы елның 13 июнендә Казанда тәхеткә китерелгән Шаһали анда бер ай гына утырган булгач, аның качып китүе, инде әйтелгәнчә, июль аеның урталарына туры киләчәк [ПСРЛ. Т. 13: 1965. С. 148] һәм ул качканда казанлылар инде Сафа-Гәрәйне «Кама елгасы буена» кайтарган булганнар [Шунда ук]. Әйткәнебезчә, «Казанская история» буенча, Чура батыр Шаһалидән 10 көн соңга калып юлга чыга. Аңлашыла ки, ул 10 көн эчендә Сафа-Гәрәй Казанга кереп урнашырга тиеш булган – тәхет бит буш, ә «казанлылар» исә бу ханны үзләре кире тәхеткә чакырганнар. Димәк, вакыйганың гомуми агышын истә тотсак, Чура Нарыков һәм аның тарафдарлары Шаһалине тәхеткә китергән өчен кире әйләнеп кайткан хан каршында җавап бирергә тиеш булып чыгалар. Шунлыктан, «Казанская история» әсәрендәге бу безне кызыксындырган затлы татарның үлеменә багышланган эпизодны, игътибарга лаеклы аерым детальләре булса да, тулы түгел дип санарга туры килә, һәрхәлдә, анда тасвирланган вакыйгаларда Сафа-Гәрәйнең бер роле дә булмауы шөбһәле.

Чынлыкта менә шул тулы булмаган информациягә өстәмә, татарларда сакланган кайбер тарихи легендалар эчендә бар. Әйтик, Карауҗа авылы белән бәйле югарыда карап үтелгән шәҗәрәле тарихта «Чура би» турында мондый юллар бар: «...Чура бине Казан ханына хыянәте өчен (игътибар! – Д.И.) авызына эретелгән көмеш (алтын) салып үтерәләр. «Менә сиңа җитмәгән иде байлык, ал!» – дип. Чура би Мәскәү патшасына серләрне саткан була. Аның кабере Зур Карауҗа авылының яңа зиратында» (карагыз: [Әхмәтҗанов: 1995. 34 б.; Татар халык иҗаты: 1987. 160 б.]). Күренә ки, монда исеме аталмаган «Казан ханы» турыдан-туры булмаса да Чура бинең үлеменә сәбәпче булып тора. Ахрысы, «Казанская история» әсәрендәге вакыйгаларда Сафа-Гәрәй катнашкан булса кирәк. «Патриарх (Никон) елъязмасындагы» Чура Нарыковның үлеме турындагы эпизодта да игътибарга лаек бер деталь бар: аның белән бер үк вакытта «Казанда» хан (ягъни, Сафа-Гәрәй) Баубек һәм Кадыш исемле «князьләр-

не» генә түгел, ә «күп кенә башкаларны да» («иныхъ многихъ») үтерә («побилъ») [ПСРЛ. Т.13: 1965. С.149]. Ә бу исә «Казанская история» әсәрендәге бер урынга туры килә, чөнки качып киткән Чура Нарыков белән аның үз кешеләре (1500 сугышчы) генә түгел, ә башка затлы татарлар да искә алына: «...и присталых к нему – со всем богатством князеи, з женами и з детми» [Казанская история: 1954. С.82]. Димәк, Казаннан читкә китеп баручылар арасында Чура батырдан тыш башка аксөякләр дә булган һәм алар «Казанская история» артыннан барсак, Казанда түгел, ә аннан читтә, аларны Сафа-Гәрәй җитәкчелегендәге гаскәр куып җитеп, сугышкан вакытта үтерелгәннәр булса кирәк.

Шулай итеп, Чура батыр улы белән бергә 1546-нчы елның июлендә (ахрысы, аның урталарында түгел, ә бераз соңрак, айның егерменче көннәрендә) Казаннан читтә, бәлки, үзенең резиденциясе булган Караужа авылы тирәләрендә, хан гаскәре белән бәрелеш вакытында һәлак була. Реаль тарихи вакыйга менә шулай барган.

Ә нәрсә сөйли соң бу турыда Чура батырга багышланган дастаннар? Аларда дастан героеның үлеме эпизоды бөтенләй башкача сурәтләнә (югарыда карагыз). Ул турыда инде сөйләнгәнлектән, безгә хәзер Чура батырның үлүенә багышланаган төрле версияле дастанның кайбер нюансларына гына тукталып китү кирәк.

Идел-Урал буе татарларына хас «Чура батыр» дастанында аның герое рус гаскәрләре һәм аларның эчендә булган үз улы белән сугышта үлә (төгәлрәге, шул сугыш вакытында суга бата). Ягъни, монда Чура батыр героик рәвештә Казанны саклап мәрхүм була. Кырым татарларында язып алынган «Чорабатыр» дастанында да аның герое «Казан ханының сараена» кайткач, анда «Сары ханыма» өйләнә, тегесе бераздан аннан аерыла һәм дошманнар ягына чыга, аннан туган бала үсеп житкәч, ул Чура батыр белән сугышта катнаша һәм алар икесе бергә алышкан вакытта суга батып үләләр [Къырымтатар: 1991. 72б.]. Бу дошман гаскәренең кемлеге, аның этник йөзе бу очракта дастанда ачык күренми, әмма әсәрнең ахырында әйтелә: «Чорабатыр сувгъга баткъан сонъ Къазанны рус чары ала», – дип [Къырымтатар: 1991. 72б.; Образцы. Ч.VII: 1896. С.132]. Димәк, бу очракта да Чура батыр рус гаскәрләре һәм үз улы белән сугышта үлә дип уйлый алабыз. Добруджа (Буджак) татарларыннан язып алынган дастанда Чураның турыдан-туры кем белән сугышып үлгәне әйтелми, ләкин ул Казанга китеп барганда аны «казаклардан», димәк, беренче чиратта, кырым татарларының һәм нугайларның православ динле дошманнарыннан, саклау өчен барганлыгы әйтелә [Чура Батыр: 1993. 54б.], аннан соң бик зур яуның Казан каласының астына дары салып, аны шартлатуы турында сөйләнә дә, ялгыз калып дошман белән кылычка-кылыч килеп аңа каршы торган батырның бу гаскәргә әсирлеккә

эләкмәс өчен текә ярдан аты белән Иделгә сикерүе тасвирлана. [Шунда ук: 60 б.]. Күренә ки, монда да Чура батырның рус яуы белән сугышта үлүе турында бара бит сүз. Нугайларның «Шора баьтир» дастаныныда да әйтелә: «...Казан уьстине яв келди. Бу согыста Шора баьтир йигитлерше согысып, Карагер аты ман Эдил сувына батып оьледи», – дип [Ногай халк: 1969. 79 б.]. Бу версия Добруджа (Буджак) татарлары версиясе белән тулаем туры килә, шулай булгач, монда да Чура батыр «егетләрчә» сугышып үлгән. Дошман, ул турыда дастанада ачык әйтелмәсә дә, рус яуы булып чыга.

Ә менә казахларда таралган «Шора» дастанында эш башкачарак тора: Казан ханы кызын хатынлыкка алгач, Чура үзенең дусты Колыншак белән калмыкларга каршы сугыша һәм бер бәрелештән соң алар үзара сөйләшеп утырганда Чураның әрвахы турында сүз чыгып ул аждаһа (айдаһар) елан кыяфәтендә килеп чыгып аңа Колыншак (Колынчак) батыр кылычы белән кизәнгәч, ул юк булды һәм шул ук вакытта Чураны җир йотты, ул шулай югалды, – дип әйтелә бу дастанда [Батырлар жыры: 1989. 368–369 бб.]. Димәк, казахларда Чура батырның дошман белән сугышулары турында әйтелсә дә, ул дошманнар заманында казахларга зур зыян китергән калмыклар белән бәйләнелә, ә дастан героеның үлеменә героик төсмер бирелми. Әмма, монда да бер уйландыра торган мифологик «эз» бар төсле – озак яшәгән елан – ә мифологик аждаһа елан шундый җан иясе була да инде ул – кайбер борынгы ышанулар буенча, хатын-кыз затына әйләнә алган (татарларда – юха еланга). Шуңа күрә дә казахларда сакланган бу Чура батыр белән бәйләнгән мифологик образ аның хатын-кыз аркылы үлгәнлегенә ишарә түгел микән, дигән уй килә башка. Дөрес, бу бер фараз гына, моны исбат итеп булмый, шуның өстенә казахлардагы дастан вариантларында Чураның улы турында бер сүз дә юк. Әмма, барыбер әйтелгән фикергә урын бар төсле.

Шулай итеп, Чура батырга багышланган дастаннарның күбесендә аларның төп герое дошманнар (беренче чиратта, руслар) белән бик нык Ватан өчен көрәшеп, трагик рәвештә һәлак була. Нәкъ менә шушы бәяләү аркылы без урта гасыр татарларының Казан ханлыгын руслар тарафыннан яулап алулары алдыннан яшәп килгән этник аңнарына реконструкция ясый алабыз: безнең ерак бабаларыбыз татарлар арасындагы үзара каршылыкларны күрергә, аларны таныргa теләмәгәннәр, хәтта Чура Нарыковның үлеменә дә дастанда бөтенләй тарихи вакыйгаларга туры килмәгән, әмма ул вакытның төп рухын чагылдырган, төсмер биргәннәр һәм ул дәвер өчен мондый карашлар, кайбер документаль чыганаклардан күренгәнчә, чынлап та хас булган. Мәсәлән, Казан ханлыгының соңгы бөек сәййеде булган Кол-Шәрифнең (Шәриф Хаҗитарханиның) «Зафәрнамәи вилаяте Казан» исеме астында билгеле булган 1550-нче елда язылган һәм төрек солтанына юллаган хатында мондый сүзләр бар:

Шәрифи, китмә бу йирдән, газа өмидегәр булса,
Бу көндин соң дигәйләр кем, будыр сахиб Казан шәһре
[Кол Шәриф: 1997. 80 б.].

Бу, кәферләргә каршылык күрсәтергә кирәк, дигән сүзләрне раслап, Кол-Шәриф, руслар 1552-нче елны Казанны алганда, үзенең яраннарын җитәкләп, ахыргача яулап алучылар белән сугыша, мәдрәсә түбәсендә булган соңгы алышуда үтерелә, аның гәүдәсе шуннан җиргә килеп төшә (Казанда мәетен соңыннан князь Андрей Курбский күрә).

Югарыда әйтелгән карашлар хаттә «Казанская история» эченә дә үтеп кергән, чөнки Чура Нарыков турында ул әсәрдә мондый юллар бар: «... Инии же почиташе Чюру за храбрость его и за высокоумие его во всем граде» [Казанская история: 1954. С. 82]. Шуны әйткәннән соң, бу әсәрнең авторы, Чура батырның ни өчен үлгәнлеген бик яхшы аңлап, өстәп куя: «...И несть болши сея любви ничтоже, аще кто за друга (димәк, Шаһали өчен – Д. И.) душу свою положит или за господина» [Шунда ук].

Әмма, халык чынлыкта Чура Нарыковның ничек үлгәнен белгән – ул турыда алда китергән Карауҗа авылы белән бәйле легендар тарих бик ачык сөйли. Димәк, аргын кабиләсе бәге Чура б. Нарыкны дастанда геройлаштыру XVI-нчы йөз урталарындагы татар җәмгыятенең төп психологик хәләтенә туры китерелеп тудырылган. Ә бу исә данлы тарихка ия булган татарларның соңгы героик образларын тудырулары иде. Шул заманнардан соң татарларда үзәгендә мондый «батырлар», ягъни, карачы бәкләр нәселеннән булган, кабиләләр белән бәйле хәрби җитәкчеләргә багышланган башка дастаннар, инде бүтән тумаган, чөнки заманалар да үзгәргән, ханлыклар юкка чыккач андагы исән калган аксөякләр дә «йомышлылар» рәтенә кереп, элекке дошманнарына хезмәт итә башлаганнар. Шуңа күрә дә татарларда (казахларда һәм нугайларда эш башкачарак торган) алдагы дәвердә урта гасыр өчен хас «батырлыкларга» урын калмаган.

Инде «Чура батыр» дастаны эченә салынган киләчәк буыннарны «кисәтү» мәсьәләсенә дә килеп җиттек. Чынлыкта, мондый «кисәтү» бу дастанның кайбер вариантларында гына бар һәм ул, безнең фикер буенча, Идел-Урал буйларындагы тарихи чынбарлык белән нык бәйле. Язмабызның алдагы өлешендә күрсәтелгәнчә, Чура батырның үлеме аның башка милләт (рус) хатыныннан туган улы аркылы булган, – дип сөйләнә «Чура батыр» дастанында. Ләкин, Идел-Урал буе татарларыннан тыш яшәгән дастанның башка милли версияләрендә бу сюжет юк. Кырым татарларында гына исеме әйтелмәгән «Казан ханының» кызы Сары ханым (ул «Сарыкани» буларак Идел-Урал буе татарлары вариантларында Шаһали кызы булып та йөри [Татар халык иҗаты: 1984. 115 б.]), инде әйтелгәнчә, Чурага иргә чыгып, аннан соң аннан аерылып, дошман ягына күчә һәм

аның үсеп җиткән улы дошманнар арасында үсеп, бер «батыр» буларак, әтисе белән сугыша [Къырымтатар: 1991. 72 б.]. Ахрысы, бу очракны да без Шаһалинең руслар белән союзда булганлыгын чагылдыру дип кабул итәргә тиешбез. Ләкин башка очракларда Чура батырның үз хатыны (Сылубикә, Алтын) я Кырымда кала [Татар халык иҗаты: 1984. 118 б; Чура Батыр: 1993. 51 б.; Ногай халк: 1969. 74 б.], яисә бу батыр Казанга барып, анда Әделшә исемле ханның Ханжан атлы кызын хатынлыкка алуны планлаштыра гына [Батырлар жыры. Т. 5: 1989. 352 б.]. Ничек кенә булмасын, беренче чиратта без Идел-Урал буе һәм беркадәр Кырым ханлыгының варислары арасында таралган Чура батырның үлемен рус хатыныннан, яки руслар белән бәйле татар ханы кызыннан туган, атасына дошманга әйләнгән оглан аркылы күрүне алга чыгарырга тиешбез.

Чынлыкта бу сюжет Казан ханлыгы егылгач килеп туган актуаль хәлләргә татар җәмгыяте ягынннан барлыкка килгән бер реакция булса кирәк, чөнки нәкъ шул дәвердә затлы татарлар күпләп руслар ягына чыгалар, аларга әсирлеккә төшәләр һәм тиз арада чукындырылып (беренче чиратта христианлаштыру сәясәте карачы бәкләргә һәм Чыңгызыйларга карата алып барыла [Исхаков: 1998. С. 233–234]), рус хатыннарына өйләнделәләр, димәк, гаиләгә чит күзәтүчеләр һәм башка дин тоткан кяферләр кертелә. Тикшерелә торган дастан шул турыда кисәтә дә – катнаш гаиләдә туган бала Ватанның сагында торган батыр атасының башына җитеп, илне яклаучысыз калдыра ала, дигән фикер үткәрелә «Чура батыр» эпосында. Бу – безнең урта гасырда яшәгән бабаларыбыздан киләчәк буыннарга җибәрелгән бик әһәмиятле, хәзерге дәвергә кадәр килеп җиткән, хәбәр [Paksoy: 1986]). Аның турында татарларга һичкенә дә онытырга ярамый икәнлеге XXI-нче гасыр биеклегеннән бигрәк тә яхшы күренә.

**«Чура батыр» дастанының ачыкланмый калган яклары.**

Сезнең алдыгызда яткан язма өстендә эшләгәндә күпме генә тырышсак та, тикшерелгән дастанның барлык тарихи серләрен дә ачып бетереп булмады. Беренче чиратта моны, билгеле, ышанычлы чыганаклар җитәрлек булмау белән аңлатырга кирәк. Шуңа күрә дә без язмабызның соңгы өлешендә «Чура батыр» эпосындагы кайбер әлегә томан астында калган тарихка кагылышлы мәсьәләләрне күрсәтеп китәргә булдык. Бәлки алар турында башка тикшерүчеләр дә уйланырлар һәм фәнни эзләнүләре вакытында ул сорауларга да җаваплар табарга тырышырлар, дигән ышаныч белән яздык без хезмәтебезнең соңгы өлешен.

1. Чура батырның атасы Нарык (Нәрик, Нәррән) батырның шәҗәрәсен тикшерү эшен дәвам итәргә кирәк булачак, чөнки XV-нче гасыр башында яшәгән Кара-хуҗа бәк белән Нарык арасында ким дигәндә 3–4 буын булырга тиеш, алар исә фәкать тик нугай һәм Добруджа (Буджак) татарла-

рының дастаннарында гына сакланган: Чура ← Ир-Нарык (Чура би) ← Ир-Түләк ← Байгазы ← Астын (Арслан).

Нугайларның «Шора баьтир» дастанының бер урынында Нарикның атасының исеме «Эсебий» дип тә бирелә [Ногай халк: 1969. 68 б.]. Бәлки ул «Гайса/Иса» бий дигән исемдер. Ләкин Казан арты авылларында сакланган шәҗәрәләр башка төрлерәк: Чура батыр ← Чура би (Нарик) ← Карауҗа ← Кара би. Аңлашыла булса кирәк, икенче шәҗәрәнең Карауҗадан Чура бигә (Нарыкка) кадәрге XV-нче йөзгә караган өлешендә буыннар җитешми. Алар беренче шәҗәрәдә бар, ләкин ул шәҗәрә әлегә Кара-хуҗа бәк белән тоташмый. Шуңа күрә дә соңгы шәҗәрәдә саналган шәхесләр турында документаль чыганаклар эзләү таләп ителә. Бу Чураның атасы Нарык батырның үзенә дә кагыла, аның турында да тарихи чыганаклар булырга тиеш.

Мондый тарихи чыганаклар табылып, югарыда китерелгән нугай версиясе дип аталырга хаклы шәҗәрәнең дөреслеге расланса, Чура Нарыковның нәселе турындагы информация тагы да байрак булачак.

2. Чура батырга багышланган барлык дастан версияләрендә дә аның атасының һәм үзенең дошманы итеп «Акташлы» (Акъташлы) Али (Гали) бәй атала. Үз вакытында бу шәхес турында Чокан Вәлиханов бер Чорага багышланган казах «поэмасыннан», ягъни, дастаннан чыгып, аны «Урал» (Җаек елгасы булса кирәк) һәм «Сарайчык» тирәләрендә яшәгән нугайларның «актачи бүлеме» башында торган «ыру башлыгы» буларак күрсәткән иде. Шулай ук, аның фикере буенча, Али бийның исеме Кырым ханы Саадат-Гәрәйнең хиҗри белән 930-нчы елга (1524-нче ел) караган ярлык астында булып, ул «конюший» (хан атлары өчен җаваплы) дәрәҗәсенә ия булган ([Вәлиханов. Т. 1: 1984. С. 109]. Ярлыкны карагыз: [Тарханные: 1851. С. 22]). Бәлки, бу фикер белән килешергә кирәктер, ни дисәң дә Али (Гали) бәк Чураның атасы Нарык (Нарәң) батырдан аның Карагир атлы «сөйгән атын» алып киткәч башлана бит конфликт [Татар халык иҗаты: 1984. 113 б.; Къырымтатар: 1991. 63 б.; Чура Батыр: 1993. 37 б.; Ногай халк: 1969. 67 б.]. Әмма, бу затлы татар турында өстәмә мәгълүмат кирәк әле. Аның бер өлеше рус телендә сакланган казахларда язып алынган «Шура-Батыр» дастанында бар: анда Али бий «Ак калада» хөкем итә һәм 10 мең «нугае» булган Тимер хан угълы Кара ханга хезмәт итеп, аның бие була һәм 40 меңлек «айракты» дип исемләнгән төркем башында тора [Сборник материалов. Т. IV: 1895. С. 8]. Бу кабилә исеме түгел микән? Шулай ук, «Ак-кала» атамасы «Ак таш/Акташ/Акътачи» исеменең варианты дип карала аламы? Кайда урнашкан була соң бу «кала»? Бирелгән сорауларга әле җаваплар табасы бар. Шулай да, «айракты» атамасы хәзерге көнчыгыш Татарстан (Ык буйлары) һәм төньяк-көнбатыш Башкортостан белән Пермь

төбәгенең көньягы җирләрендә билгеле булган «иректе» ыруының исеме белән охшаш. Ә бу төркем исә Көнбатыш Себер (Миасс елгасы һәм Тобол-Иртыш буйларыннан) якларыннан күчеп килгән табын (кара-табын) кабиләсе белән бәйле булган [Исхаков: 1993]. Ләкин Ык тирәләрендә урнашкан «иректе» төркеменең саны әллә ни зур булмаган, ә Али бийның кул астында 4 төмән күләмендәге зур масса гаскәри күренә. Шуның өстенә онытмыйк – «иректе» термины төрки «ирәк», ягъни, «ныгытма, крепость» сүзеннән ясалган, димәк ул төшенчәнең «ныгытмада хезмәт итүчеләр» дигән мәгънәсе дә булырга мөмкин һәм ул очракта бу термин кабилә-ыру атамасы булмый. Ә менә «Ак ташлы/Ак-кала» дигән урынны, ахрысы, Кырымда яисә аннан якын җирдә эзләргә кирәк, чөнки «Чорабатыр» дастанында (кырым татарлары версиясе) «Ак ташлы Али бий» явыз ният белән «Кокушле Кок Тама» дигән урынга килә [Образцы. Ч. VII: 1896. С. 170]. Димәк, бу ике урын бер-берсеннән бик ерак урнашмаган булганнар һәм ул төбәк Кырым ханлыгына караган җирләрдә булырга тиеш. Ничек кенә булмасын, бу мәсьәләләргә алга таба ачыклык кертергә кирәк булачак.

3. Дастаннарның кайбер казахларда сакланган версияләрендә Нарикны «хан» дип, аның улы Чура (Шора)ны «солтан» дип атау күзәтелә, ә ул Казанга киткәндә анда «хан боламын», дип бара. Сорау туа: ни өчен Нарыкка һәм Чура батырга мондый титуллар бирелә, алар бит Алтын Урданың сәяси варисларында фәкать тик Чыңгызыйларга гына бирелгәннәр? Чынлап та, монда чишелмәгән проблема бар – тарихи чыганаклардан Чура Нарыковның «князь» (бәк, бий, бәй) дәрәҗәсе ачык күренә, аның нәселендә күренгән башка шәхесләр дә, шәҗәрә башында торган Кара-хуҗа үзе дә, «бәк» титулын йөрткәннәр. Шуңа да карамастан, безгә казахларда язып алынган дастан версиләрендәге күрсәтелгән бәяләүләрне анализдан төшереп калдырырга ярамый, чөнки Казан ханлыгында Арча бәкләре булган көнчыгыш кыпчаклар (кимаклар) арасыннан чыккан албыр (олбыр) кабиләсе лидеры Бачман солтан нәселе вәкилләре шәҗәрәләрендә дә «хан» титулы очрый [Исхаков: 2010. С. 101–104, 206]. Безнең фикеребезчә, китерелгән фактлар игътибарга лаек. Кайбер мәгълүматлар буенча (ул турыда тулырак карагыз: [Исхаков: 2018]) бу очракларда без карачы бәкләр кабиләләренең борыңгы (монголларга кадәр булган) тарихлары белән бәйле күренешне күзәтәбез (мәсәлән, XII–XIII-нче йөз башларында Хәрәземшахлар дәүләтендә 10 меңлек кабилә гаскәрләре башында торган хәрби юлбашчыларның «хан» титуллары булган). Күренә ки, бу мәсьәлә дә тикшерүне сорый.

4. Тагы бер шундый проблема Чура батырның анасы ягы кабиләсе белән бәйле. Инде әйтелгәнчә, аның атамасының төрле вариантлары бар: тама/тана, төмән/тамйан. Беренче карашка, бу кабилә-ыруның аргын кабиләсенә фратриаль (туганлык мөнәсәбәтендә торган) каршы торучы ха-

тын ягы буларак ата ягына турыдан-туры мөнәсәбәте юк кебек. Ләкин бу мәсьәлә без уйлаганга караганда катлаулырак булса кирәк, чөнки «Шура-Батыр» дастанында бер кызыклы мәгълүмат саклanган. Дастан буенча, «40 юрта биләүче тамалылар» Нарикның (Нарикбайның) «сансыз көтүләрен көткәннәр» һәм аның «ышанычлы хезмәтчеләре» булганнар [Сбрник материалов. Т. IV: 1895. С. 1]. Шулай ук, Али бий Чурадан (Шорадан) «Син тамалы түгелме?», – дип сорагач, ул җавабында әйтә: «Мин тамалылар баласы дип әйтмәгез, ә Аллаһ (Тәңре) улы дип атагыз», – дип [Шунда ук: 44 б.]. Вакыт-вакыт дастанның казах версияләрендә тамалылар (кайбер очракта – «үзбәкләр») Чура батырның үз «халкы» булып күренсәләр дә (мәсәлән, эпоста мондый юллар бар: «...в Казани ... бесчисленное множество таминцев во главе с твоим (Чураның – Д. И.) дядей Исым бием» [Сборник материалов. Т. IV: 1895. С. 49]), югарыда китерелгән юлларда аларның статуслары түбәнрәк икәнлеге чагыла. Шунлыктан, казахларның «Тана» дастанында Нәрикның атасы Тана «Ак түрә дигән хан», «Астана халкының ханы», буларак билгеләнсә дә [Батырлар жыры: 1989. 289, 291, 297, 300, 302 бб.], бу Чура Нарыковның анасы ягы кабиләсенең статусы аргыннар статусыннан түбән булган дип уйларга урын бар. Шулай да, кемнәр булганнар соң бу тамалылар? Безнең элегрәк үткәрелгән тикшерүләребез буенча, тумат (тума+күпчелек монгол форманты – ыт/ут/ат) төркеме Саян-Алтай зонасында яшәп, 1207–1218-нче еллар арасында Жучи тарафыннан буйсындырыла һәм соңыннан аның биләмәсенә кереп, монголларның 1230-нчы елгы походларында Шибан кул астындагы зур хәрби отряд составында Кырымны яулап алуда катнаша, аннан соң шактый вакыт шул тирәдә яши [История и культура: 2015. С. 125; Исхаков: 2009 б. С. 278; Исхаков 2009 в. С. 25–26]. Соңгы очракта бу төркемнең исеме «төмән» («Тамань» атамасын шуннан дип уйлыйбыз) буларак бирелә (төгәл формасы – тәмйән ← тамә булган булса кирәк). Әгәр дә бу төркем соңыннан да Кырым тирәләрендә калган булса, бәлки ул XIV-нче йөз ахырларында Туктамыш хан белән килгән аргын кабиләсенә буйсындырылгандыр. Әмма, бу бер гипотеза гына һәм мәсьәлә алга таба да өйрәнелергә тиеш.

5. Ахыргача аңлашылып бетмәгән соңгы мәсьәлә Чура бәккә багышланган дастанның таралыш географиясенә кагыла. Әйтик, бу тарихи шәхес турындагы эпик әсәрнең кырым, алар белән бәйле буджак һәм казан (ягъни Идел-Урал буе) татарлары арасында билгеле булуы аңлашыла – дастан героена әйләнгән Чура Нарыковның Кырым һәм Казан ханлыкларына, шулай ук, Касыйм ханлыгына да (бәлки, аның хөкемдары булган Шаһали хан белән дус булуы аркылы), турыдан-туры мөнәсәбәте булган, шулай икән, урта гасыр татарларының нәкъ шушы төркемнәренең тарихи хәтерләрендә

бу «батырның» образы саклануы табигый. Ә менә ни өчен Чурага багышланган дастаннар нугайлар, казахлар һәм хәтта каракалпаклар арасында да яшәгән? Бу сорауга җавап табуы авыррак. Билгеле, әйтелгән очракта эпик әсәрнең күрше халыкларга (алар арасында башкортларны да күрсәтеп була), тулаем алганда, татарлар йогынтысы аркылы үтеп кергәнлеген фаразларга мөмкин. Шул исәптән, алар эченә Чура бәкнең шәхси (аргыннар) һәм анасы белән бәйле (тама/тамйан) кабиләләренең «сеңүе» нәтиҗәсе дип тә карарга мөмкин ул күренешне. Гомүмиерәк алганда, Идел-Урал буе татарлары белән бик нык этник һәм сәяси элемтәдә булган нугайларның, төгәлрәге, нугай татарларының, шушы халыкларның формалашуында катнашулары белән аңлатырга кирәктер аны. Юкка гына казахларда сакланган Чура (Шора) батыр турындагы дастан версияләрендә ул затлы аксөякнең үз халкы «нугай» дип аталмыйдыр. Әмма, әлеге мәсьәләне алга таба да тикшерү таләп ителә, беренче чиратта, бу «батыр» турындагы дастаннарның санап кителгән халыклар эчендә билгеле булган нөхсәләренең кайсы ыру-кабилә вәкилләре арасында язып алынганлыгын махсус өйрәнү кирәк. Ул вакытта язмабызның үзәгендә торган реаль тарихи шәхес булган конкрет аксөяк татарга багышланган дастанның кемнең тарихи мирасы икәнлеге төгәлрәк ачылачак, дип уйлыйбыз.

Шулай итеп, әле алдагы буын галимнәре өчен дә «Чура батыр» дастанын ныклап анализлау кирәк булачак. Аңа тотынганчы фольклорчыларыбыз каршында башта эпик әсәрнең барлык милли вариантларын да туплап, басып чыгару бурычы тора. Беренче чиратта бу эшне татар галимнәре башкарырга тиешләр, чөнки сүз, ни генә әйтсәң дә, төрки-татарның рухи мирасы турында бара.

## Әдәбият

### *1. Чыганаклар.*


1. Әхмәтҗанов М. И. Татар шәҗәрәләре (Беренче китап). Казан: Татар. кит.нәшр., 1995. – 128 б.
2. Батырлар жыры. Бесінші том. Қырымның іырыі батыры (Мұрын жыраудан жазылған мұралар). Алматы: «Жазушы», 1989. – 384 б.
3. Дәфтәре Чыңгыз намә // Мирастан биш сәхифә: XVII–XIX гасырлар әдәби-тариха ядкярләре/ [Транскр. эш., хәзерге татар әдәби тел.күчерүче, иск. һәм сүзл. төзүче, кереш мәкаләләр авт. С. Гыйләҗетдинов]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 38–96 бб.
4. Идегәй. Татар халык дастаны. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 254 б.
5. Казанская история. Под-ка текста, вступ.ст. и прим. Г.Н.Моисеевой. Под ред. чл.-корр. АНСССР В.П. Адриановой-Перетц. М.-Л.:Изд-во АНСССР, 1954. – 191 с.

6. Кол Шәриф. И күңел, бу дөньядыр... Газәлләр, кыйсса. Казан: Татар. кит.нәшр., 1997. – 94 б.
7. Къырымтатар халкъ агъыз яратыджылыгъы. Хрестоматия. Тертип этиджи Дж. Бекиров. – Ташкент: «Ўқитувчи», 1991. – 248 б.
8. Малиновский А. Историческое и дипломатическое собрание дел, происходивших между российскими великими князьями и бывшими в Крыме татарскими царями с 1462 по 1533 год. // Записки Одесского ОИД. Т. 5. Одесса, 1863. – С. 178–419.
9. Ногай халк йырлары. М.: Наука. Гл. ред. Вост. лит-ры, 1969. – 215 с.
10. Образцы народной литературы северных тюркских племен. Ч. VII. Наречия Крымского полуострова. Собр. В.В. Радловым. СПб., 1896. – 935 с.
11. ПСРЛ. Т. 13. Патриаршая или Никоновская летопись. М.: Наука, 1965. – 532 с.
12. Сборник материалов для статистики Сыр-Дарьинской области. Т. IV. Ташкент, 1895. – 240 с.
13. Тарханные ярлыки Тохтамыша, Тимур-Кутлука и Саадетъ-Гирея. С введением, переписью и примечаниями изданные И. Березиным. Казань: Типография ун-та, 1851. – 56 с.
14. Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар кит. нәшр., 1984. – 383 б.
15. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 367 б.
16. Чура Батыр. Татар халык дастаны. Казан. Татар кит. нәшр., 1993. – 63 б.
17. Bozcigit. Dobruca Tatar Masalları. Birinci kitap / Toplagan, kaytabaştananlatkan hem azirlegenler: N. Mahmut, E. Mahmut. – Bucureşti: Kriterion Kitap Üyi, 1988. –258 s. (электронный ресурс: http://qirimtatar-bg.blogspot.ru/2012/09/cora-batr-destan.html. Керү датасы: 11.01.2019.).

***2. Тикшерүләр.***

18. Валиханов Ч.Ч. [Заметки при чтении книги] проф. И.Н. Березина «Тарханные ярлыки» // Валиханов Ч.Ч. Собрание сочинений в пяти томах. Т. 1. Алма-Ата: Гл. ред. Казахской сов.энциклопедии, 1984. – С. 104–114.
19. Инальчик Х. Хан и племенная аристократия: Крымское ханство под правлением Сахиб Гирея // Панорама-Форум. 1995. № 5. – С. 73–94.
20. История и культура татар Западной Сибири. Монография. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – 728 с. Исхаков Д. Тарихи туганлык, этник берлек (Көнбатыш Себер һәм

Идел-Урал буе татарлары тарихыннан) // Татарстан. 1993. №2. – 39–48 бб.
21. Исхаков Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV–XVII вв.). Научное издание. – Казань: Мастер Лайн, 1988. – 276 с.
22. Исхаков Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV–XVII вв.). Казань: Изд-во «Мастер-Лайн», 1998. – 276 с.
23. Исхаков Д.М. Тюрко-татарские государства XV–XVI вв. – Казань: Тат. кн. изд-во, 2009-а. – 142 с.
24. Исхаков Д.М. Комментарий к одному месту из «Таварих-и гузида-Нусрат-наме» // Национальная история татар: теоретико-методологическое введение. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2009-б. – С. 274–278.
25. Исхаков Д.М. О клановом составе первоначального удела Шибана // Золотоордынское наследие. Материалы Международной научной конференции «Политическая и социально-экономическая история Золотой Орды (XIII–XV вв.). 17 марта 2009 г. Сб. ст. Вып. 1. Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2009-в. – С. 24–34.
26. Исхаков Д.М. Арские князья и нукратские татары (Историко-этнографические сведения, генеалогии, клановая принадлежность, место в социально-политической структуре Казанского ханства и Русского государства). – Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2010. – 224 с.
27. Исхаков Д.М. История рода Яушевых в средневековый период и кимакская проблема. Казань–Воронеж: ООО «Фаворит», 2018. – 116 с.
28. Орлов А.С. Казахский героический эпос. М.-Л.: Изд-во АНСССР, 1945. – 148 с.
29. Смирнов В.Д. Крымское ханство под верховенством оттоманской Порты до начала XVIII века. Т. I. М.: Изд. дом «Рубежи XXI», 2005. – 541 с.
30. Сыроечковский В.Е. Мухаммад-Герай и его вассалы // Ученые зап. Московского ун-та. Вып. 61. История. Т. 2. 1940. – С. 3–71.
31. Inalcik H. The khan and the Tribal Aristocracy: The Crimean Khanate under Sahib Giray I // Harvard Ukranian studies. Vol. III–IV. Part I. 1979. – PP. 445–466.
32. Manz Beatrice F. The clans of Crimean Khanate. 1466–1532 // Harvard Ukranian studies. 1987. Vol. 2–3. – PP. 282–309.
33. Paksoy H.B. Chora Batir: A Tatar Admonition to Future Generations // Studies in Comparative Communism. 1986. Vol. 19. Nos. 3–4. – PP. 253–265.

*Р. Ф. Гатауллин*
*С. Ш. Аслаева*

# ОСНОВНЫЕ КОНТУРЫ ИНСТИТУЦИОНАЛЬНОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ БАШКОРТОСТАН В 1990–2017 гг.[1]

***Аннотация:*** *В статье рассматриваются особенности институционального развития Республики Башкортостан в постсоветское время как отражение расстановки сил различных стейкхолдеров, действующих на ее территории. Показана роль субъективного фактора в этом процессе.*

***Ключевые слова:*** *институциональное развитие, политические реформы, элита, устойчивость*

Институциональное развитие есть общественно-политический процесс, который в Республике Башкортостан не только является органической частью ситуации, сложившейся в Российской Федерации, но и имеет свои особенности, связанные федеративным устройством страны. Однако, эти особенности не имеют судьбоносный характер, а проблемы, возникающие в сфере общественно-политической системы, в целом являются общими как для России, так и для республики.

До начала политической реформы, инициированной руководством КПСС в конце 80-х гг. XX в., Башкирская АССР (БАССР) являлась составной частью унитарной государственной системы. Несмотря на конституционно закрепленные статус и полномочия, республиканские органы власти не были самостоятельными. Представительные органы власти Башкирии, как и других республик СССР, в условиях закрытой системы реально не влияли на процесс принятия решений, вырабатываемых на партийном уровне [Институциональные основы развития Республики Башкортостан: 2014. С. 160].

В конце 1980-х гг. в регионах СССР и РСФСР формировалось и набирало силу антикоммунистическое движение, в Башкирии же вплоть до 1990 г. позиция обкома КПСС оставалась довольно устойчивой. Новый этап формирования политического режима, трансформации системы органов власти в регионе, связаны с избранием Верховного Совета БАССР XIII созыва (1990–1995). Выборы показали слабость республиканских общественно-политических и национальных объединений, находившихся тогда на стадии становления и не способных составить конкуренцию предста-

1 Данное исследование выполнено в рамках госзадания ИСЭИ УФИЦ РАН по теме «Нивелирование пространственной поляризации разноуровневых территориальных систем в условиях формирования технологического прорыва» (№ госрегистрации АААА-А17-117021310209-5).

вителям партийной, хозяйственной и административной номенклатуры, получившим в результате выборов демократическую легитимацию.

Выборы на пост председателя Верховного Совета БАССР состоялись на 1-й сессии, начавшейся 4 апреля 1990 г. На эту должность претендовали 8 народных депутатов. Программные заявления кандидатов почти не различались по содержанию. Практически все они говорили о расширении самостоятельности республики, необходимости решения экологических и социально-экономических проблем. Более заметно был выражен тезис о самостоятельности республики у М.Г. Рахимова – он обещал добиваться как экономического, так и политического суверенитета, предложил двухпалатную структуру парламента (Съезд – Верховный Совет), единое налогообложение. М.Г. Рахимов позиционировал себя как крупного хозяйственника, имеющего ресурсы и знающего пути решения проблем республики. Подчеркивая важность повышения качества здравоохранения и поддержки села, расширения компетенции республиканских и местных органов власти, М.Г. Рахимов отмечал: «Ускорение решения этих вопросов возможно при увеличении бюджетных ассигнований на здравоохранение и при ежегодном выделении валютных средств промышленных предприятий на приобретение новейшей аппаратуры… Без помощи промышленных предприятий мы это не сделаем… Надо поощрять расширение внешних экономических связей, используя… результаты на удовлетворение интересов всех слоев населения. Пока мы должны решать эти проблемы за счет валютных отчислений» [Стенографический отчет: 1990. С. 30].

В отличие от других кандидатов на пост председателя Верховного Совета БАССР, в основном функционеров КПСС, М.Г. Рахимов имел опыт политической деятельности не только внутри республики – в 1989 г. он был избран народным депутатом СССР. Уже в этой роли он попытался выступить в качестве примирителя разных интересов, избегая крайних позиций.

В условиях федерализации его фигура стала точкой опоры для местной элиты в борьбе с центром за контроль над региональными ресурсами.

Первый этап утверждения власти М.Г. Рахимова и Верховного Совета был связан с провозглашением суверенитета республики. Посетивший республику Б. Ельцин произнес свою знаменитую фразу о том, что Башкирия может взять столько власти, сколько она «проглотит». К концу лета в республиканской печати был опубликован ряд проектов Декларации о государственном суверенитете Башкортостана (среди них официальными можно считать проекты, подготовленные Президиумом Верховного Совета и Совмином). Главной проблемой, вокруг которой развернулась дискуссия, стал вопрос о месте республики в составе СССР и РСФСР. В отличие от проекта Президиума, в котором Башкирия провозглашалась только

субъектом СССР, в правительственном варианте республика, повысив свой статус до союзной, все-таки оставалась в составе РСФСР. Это отражало ориентиры руководства правительства, поскольку оно находилось в сфере влияния исполнительной власти РСФСР. Пытаясь успокоить оппонентов, М.Г. Рахимов заявил, что провозглашение суверенитета не означает одностороннего разрыва отношений Башкирии с Россией и СССР, что Декларация утверждает равноправие национальностей, подчеркнул необходимость подписания союзного договора. Для данного этапа деятельности Рахимова в должности руководителя характерна определенная гибкость, граничащая с беспринципностью, но эти черты в дальнейшем способствовали укреплению его личной власти.

В соответствии с поправками 1991 г., в ст. 102, 103 Конституции БАССР Председатель Верховного Совета приобрел статус высшего должностного лица республики, осуществляющего представительство в отношениях с органами СССР, РСФСР, включая международный уровень, и получил право издавать указы и распоряжения, обязательные на всей территории республики. Председатель Верховного Совета мог вносить предложения по изменению и преобразованию структуры и персонального состава правительства, других органов исполнительной власти и о назначаемых ими должностных лицах в Верховный Совет, а между сессиями – в Президиум, то есть все назначения теперь должны были согласовываться с председателем Верховного Совета. Кроме того, председатель Верховного Совета республики мог вносить предложения, касающиеся персонального состава Комитета конституционного надзора. Поправки в ст. 111, 112 закрепили подотчетность Совмина Президиуму Верховного Совета.

19 августа 1991 г. группа консервативно настроенных деятелей из руководства ЦК КПСС предприняла попытку отстранения президента СССР М. Горбачёва от власти и смены проводимого им курса на «перестройку». После провала августовского путча в Москве, М.Г. Рахимов был в числе глав республик, подписавших обращение о приверженности принципу «единой и неделимой России». Из анализа ситуации, сложившейся после августовского путча, можно сделать вывод, что политическая система республики имела возможность альтернативного развития.

25 декабря 1991 г. был созван 6-й (внеочередной) Всебашкирский съезд, провозгласивший создание Башкирского народного конгресса, что мотивировалось образованием «независимого демократического государства Башкортостан». В резолюции съезда признавался неприемлемым для республики проект новой Конституции России, направленный на «ликвидацию существующих урезанных форм государственности нерусских народов». Непосредственно после этого, 28 марта 1992 г., сформировалось обще-

ственно-политическое объединение «Русь», который наряду с уже существующем татарским общественным центром, вскоре станет наиболее последовательной оппозиционной правящему режиму, группировкой.

Радикальная экономическая реформа, инициированная федеральным центром, встретила сопротивление в республике, значительную долю экономики которой занимал аграрный сектор. Стратегия «мягкого вхождения в рынок», которую тогда активно продвигал депутат Р.Ф. Гатауллин, легла на благоприятную почву интересов местного директората.

Подписав Федеративный договор о разграничении предметов ведения и полномочий между федеральными органами государственной власти Российской Федерации и органами власти суверенных республик в составе Российской Федерации, местное руководство закрепило свою автономию от центра. Был введен институт местной администрации, Президиум Верховного Совета закрепил за собой право назначать глав администраций.

К 1993 г. в руках правящей группы, возглавляемой М.Г. Рахимовым, были практически все рычаги власти. М.Г. Рахимов одержал победу на президентских выборах. Его поддержали чиновники всех уровней и башкирские национальные силы.

Политико-правовые конфликты между республиканской и федеральной властями, их столкновения в ходе избирательной кампании в Госдуму РФ в 1999 г., показали слабость стратегии руководства республики в новых условиях.

Федеральное Собрание РФ в июне 1999 г. приняло закон «О принципах и порядке разграничения предметов ведения и полномочий между органами государственной власти Российской Федерации и органами государственной власти субъектов Российской Федерации». Это был один из первых серьезных шагов федерального центра по ограничению региональной власти, и он вызвал негативную реакцию руководства Башкирии.

31 декабря 1999 г. подал в отставку президент России Б. Ельцин. Региональные лидеры и основатели движения «Отечество Вся Россия» – В. Яковлев, М. Шаймиев и М. Рахимов, поспешили заявить о своей полной поддержке на предстоящих 26 марта 2000 г. президентских выборах кандидатуры исполняющего обязанности президента РФ В.В. Путина. 5 февраля 2000 г. в Уфе состоялась учредительная конференция республиканского политического общественного движения «Единство». Руководство республики окончательно перешло под знамена «Единства» после выборов. В числе учредителей «Единства» оказалась и часть башкирской оппозиции во главе Р.Ф. Гатауллином (Партия справедливости и порядка РБ) в составе объединения «Рефах». Путин одержал уверенную победу, набрав в среднем по республике более 60 % голосов.

Руководство республики откликнулось на требование исполняющего обязанности президента РФ В.В.Путина привести местные законы в соответствие с федеральными еще до подписания главой государства указов по укреплению вертикали власти.

7 декабря 2003 г. состоялись выборы президента Республики Башкортостан. В результате победителем во втором туре был объявлен М.Г.Рахимов. Выборы показали существование межнациональных противоречий, когда избиратели каждой из основных этнических групп (башкиры, татары и русские) голосовали за представителя своего народа.

15 июля 2010 г. президент России Д.А.Медведев принял отставку президента Башкирии М.Г.Рахимова и назначил заместителя председателя правления ОАО «РусГидро» Р.З.Хамитова исполняющим обязанности президента республики. 19 июля 2010 г. Госсобрание – Курултай Республики Башкортостан утвердило Р.З.Хамитова в должности главы республики. В Википедии в статье «Рустэм Закиевич Хамитов», содержится информация о трудовых достижениях нового президента [URL: http://ru.wikipedia.org]. Среди руководителей российских регионов по степени влияния, согласно рейтингу, он занимает призовые места.

В 2011–2012 гг. повысились показатели инвестиционной привлекательности региона. Среди событий 2010–2013 гг. можно отметить открытую конфронтацию Р.З.Хамитова с бывшим президентом. Смена власти в Башкирии в 2010 г. по объективным причинам усложнила общественно-политическую ситуацию в регионе. Республика стала менее суверенной, РБ потеряла многие крупные предприятия. При этом был реализован инвестиционный проект «Кроношпан – Башкортостан». Это предприятие является одним из крупнейших участников мирового рынка глубокой переработки древесины, специализируясь на производстве древесных плит, ламинатной продукции и лесозаготовки. Ежегодно заводом «Кроношпан» будет вырубаться по 4 млн. м$^3$ древесины, тогда как республикой до этого вырубалось 3,3 млн. м$^3$, т.е. будет массовая вырубка деревьев, возникнет острый дефицит лесных ресурсов. Есть опасения, что новое производство, прежде всего, приведет к истощению запасов хвойной древесины. Местные жители выступили резко против строительства данного завода [Башкортостан путь в будущее: 2017. С. 84].

Наряду с болезненным процессом смены местной политической элиты произошло резкое усиление религиозного и национального факторов, возникли новые конфликтные моменты в сфере межнациональных отношений, было отменено обязательное преподавание башкирского языка в школах. Общественно-политическая ситуация в Республике Башкортостан в настоящий момент характеризуется устойчивой нестабильностью.

Многие общественные деятели и политики республики, связывавшие со сменой первого лица надежды на изменение ситуации, выражают недовольство и несогласие с существующим положением вещей.

Сегодняшняя ситуация такова – наша республика, как и страна в целом, вступила в полосу экономического кризиса, который во многом вызван действиями группы развитых стран, чья экономика и определяет тренд общемирового развития.

Республика Башкортостан имеет низкие темпы развития инноваций. В 2011–2013 гг. число созданных передовых технологий сократилось с 8 до 5. В 2012–2013 гг. принципиально новых технологий в РБ не было создано вовсе. Относительно низкий уровень институционального развития Республики Башкортостан отражается в финансовых результатах предприятий [Гатауллин 2017. № 98. С. 596–600]. Республика по величине сальдированного финансового результата в последние годы уступает Республики Татарстан и Самарской области. Последние годы в Республике Башкортостан, как и в России в целом, наблюдался устойчивый рост среднедушевых денежных доходов. Показатель среднемесячной заработной платы в 2014 г. по Республике Башкортостан немногим выше, чем в среднем по ПФО (7-е место), но ниже среднероссийского показателя.

В то же время все чаще звучали оценки, что трудно признать Р. З. Хамитова лидером, который стал мотором в социально-экономическом развитии республики. Более того, все очевиднее отсутствие каких-либо принципиальных шагов в модернизации республики в направлении, способном обеспечить устойчивость ее развития.

## Литература:

Башкортостан: путь в будущее: монография / под ред. д-ра экон. наук, проф. Р.Ф. Гатауллина; Уфимский научный центр РАН; Восточная экономико-юридическая гуманитарная академия (Академия ВЭГУ). Уфа, 2017. 84 с.

Гатауллин Р.Ф. Инновационный потенциал Республики Башкортостан: оценка и эффективность использования // Journal of Yeni Türkiye. 2017. № 98.

Институциональные основы развития Республики Башкортостан: монография / под общ. ред. чл.-кор. РАН, советника РАН, д. экон. наук, проф. Х.Н. Гизатуллина и д. экон. наук, проф. В.К. Нусратуллина; Уфимский научный центр РАН; Восточная экономико-юридическая гуманитарная академия (Академия ВЭГУ). Уфа, 2014. 160 с.

Стенографический отчет Верховного Совета Башкирской АССР XII созыва. Первая сессия Верховного Совета. Уфа, 1990. С. 30.

Хамитов Рустэм Закиевич // Википедия: свободная энциклопедия. URL: http://ru.wikipedia.org (дата обращения: 01.02.2018).

*Марсель Бакиров*

## БОЛГАРГА ТОТАШКАН ТАМЫРЛАРЫБЫЗ

*(Ахыры. Башын карагыз: № 3, 2019).*

Хәзергә киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган икенче бер кызыклы мисал. Англия сәяхәтчесе Антоний Дженкинсонның язуына караганда, Иван Грозный оештырган тантаналы кабул итү мәҗлесендә ул алтын кубоклар һәм кечкенә көмеш мичкәләр арасына аеруча кыйммәтле экспонат рәвешендә куелган «берничә манаралы, өске өлешендә сазаган башлары ясалган алтын әйбер»гә игътибар итә [Английские путешественники: 1938. С. 87–88]. Палата уртасындагы махсус өстәл-күперчек өстенә урнаштырылган әлеге антиквар әйбер дә, безнең уебызча, Казанны алганда руслар кулына төшкән трофей байлыгы. Ник дигәндә, әлеге кабул итү мәҗлесендә Казан ягыннан Сөембикәнең әсирлектәге улы Үтәмешгәрәй дә катнаша һәм ул да асылда Мәскәүнең Казанны җиңүен күрсәтү-демонстрацияләү өчен җанлы экспонат итеп Иван Грозный янына утыртылган була. Явыз Иван үзе исә күргәзмә экспонатлар фонында башына кигән «татар стилендәге таҗ»да көязләнә [Шунда ук. С. 88]. Хәзерге вакытта Кораллар палатасында саклаучы һәм «Казан бүреге» дип аталучы әлеге таҗның да трофей экспонат булуы шиксез. Татар галимнәренең фикеренчә, асыл ташлар белән бизәлгән һәм саф алтыннан эшләнгән әлеге таҗ-бүрек Казан ханнарыныкы булган.

Әгәр без татар фольклорында, дөресрәге – «Дәфтәре Чынгыз-намә» җыентыгында (XVII йөз), борынгы чыганакка нигезләнеп теркәлгән тагын бер үзенчәлекле елан булуына тукталмасак, елан-сазаган турындагы җирле архаик мәгълүматларыбыз тулы булмас иде. Бу хакта җыентыкның икенче бүлегендә болай диелә: «Бараҗ халкының әүвәл замандагы борынгы төп йорты ошбу Зәй тамагында булыр иде (Зәй – Каманың сул кушылдыгы. – М. Б.). Алыплар заманы иде. Бер Бараҗ дигән аждаһа елан килде. Ул шәһәрнең халкына көч-зыян кыла башлады. Чыгып аждаһа белән сугыштылар, җиңә алмадылар. Ахыры үзләре шәһәрен салып качтылар. Болгар шәһәре якынына барып Бүләр суының өстенә йорт салдылар. Ул шәһәрләрен һәм Бүләр (Биләр) дип атадылар. Ул сәбәптән халыкны Бараҗ халкы диер иделәр. Оранннары Бараҗ иде» [Татар халык иҗаты: 1987. 31–32, 297 бб.; Усманов: 1972. С. 113].

Аерым галимнәр (мәсәлән, Әмир Нәҗип) тарафыннан әкият, чеп-чи фантастика итеп кенә каралаган әлеге риваятьнең дә, безнеңчә, югарыда саналган легендар фактларныкы кебек үк, реаль җирлеге булырга тиеш. Кемнәр соң алар Зәй буенда пәйда булган елан исемен алган бараҗ халкы? XII–XV йөзләргә караучы фарсы чыганакларында Бараҗ Нух углы Яфәснең төрле

төрки кабиләләргә нигез салучы унбер улының берсе итеп бирелә, ягъни эпоним сыйфатында телгә алына [Татар халык иҗаты: 1987. 293–294 бб.].

Әмма, безнең карашыбызча, бараҗлыларның башта яшәгән җирлеген Зәй буе белән генә бәйләп калдыру җитми. «Дәфтәре Чыңгыз-намә» җыентыгындагы Зәйдә пәйда булган Бараҗ еланы турындагы легенданы Мәхмүд Кашгари, әл-Мәрвәзи, Гардизи мәгълүматлары белән бәйләгәндә, безнеңчә, бараҗ халкын кимак-кыпчаклар берләшмәсендәге елан кабиләсе белән мөнәсәбәттә карарга нигез бар[1]. Кашгари сүзлегендә мондый кызыклы мәгълүмат теркәлеп калган: «Бука – большая змея. В пословице говорится: «У змеи семь голов». Иногда этим словом называют героев, подобно тому, как называли одного из видных людей, ябаку Бука Будраж – с ним сражался Арслан-тегин – завоеватель с 40 тыс. мусульман, а неверных было 700 тыс.» [Кошгари: 1963. Т. 3. 247 б.]. Тарихчы С. Ахинжанов Бука Будраж җитәкчелек иткән әлеге халык җиде кабиләдән торучы кимаклар һәм кыпчаклар берләшмәсе булган дип исәпли һәм «у змеи семь голов», дигән әйтем еланга табынучы шул кабиләләр союзына карата кулланылган, ди [Ахинжанов: 1980. С. 50–51; Ахинжанов: 1989. С. 184–185; Бартольд: 1970. Т. II. С. 46].

Тарихи чыганаклардан аңлашылганча, Кашгари үзенең язмасында әлеге берләшмә халкының Көнчыгыш Төркестан һәм Җидесу төбәгендәге Караханилар дәүләте хөкемдары Арслан-хан Сөләйман ибн Йосыф гаскәрләре белән бәрелешүе турында сүз алып бара. Еланга табынучы мәҗүси кай-кимакларның һәм сазаганны изгеләштерүче кыпчакларның X йөз уртасыннан ук ислам кабул иткән караханилар (карлуклар) белән оппозициядә булулары, Җидесуның төньяк-көнчыгыш регионында һәм Иртышның югары өлешендә кышлаулары, ә җәйләрен аерым кыпчак-кимак ыруларының көтүлекләре белән Болгар дәүләте чикләренә, шул исәптән Каманың / Ак иделнең түбән агымына кадәр барып җитүләре тарихчыларга билгеле [Ахинжанов: 1980. С. 50–51; Ахинжанов: 1989. С. 184–185; Бартольд: 1970. Т. II. С. 46]. Мәхмүд Кашгари сүзлеге аша шулай ук Арслан-ханның кимак-кыпчаклар белән бәрелеше турында эпик әсәр өзекләре дә килеп җиткән. Аерым строфаларда караханиларга каршы яу белән килгән яки үзара союздаш булган кабиләләрнең исемнәре дә атап күрсәтелә. Сан ягыннан күп булсалар да, әлеге сугыш аларның җиңелүе белән тәмамлана.

Будрач/җ йәмә кудурды,
Алпагутын агырды,
Сүсин йана кадырды,
Кәлгәли-мәт иркишүр.

Басмыл сүсил камылты,
Барча кәлиб йумытты,
Арслан таба әмитти,
Коркуб башы тәзгинүр.

1 Редакцион искәрмә. Бу турыда журналыбызда инде язылган иде (Карагыз:2018. №2. 25–28 бб.)

Әртиш сувы йәмәки,
Сытгаб тутар биләги,
Күрмәт анын йүрәги,
Кәлгәлимәт иркишүр.
*Тәрҗемәсе:*
Будраҗ янә ашкынды,
Батырларын данлады,
Гаскәрен янә борды,
Килергә җыенадыр.

Иртыш суы йәмәкләре,
Сызганылган беләкләре,
Ялкынлыдыр йөрәкләре,
Килергә җыена(лар)дыр.

Качан көрсә аны түрк
Будун анга айдачы:
«Муңар тәгир улуглук»,
Мунда нару кәслинүр

Басмил гаскәре бирелде,
Барчасы да җыйналды,
Арсланга юнәлделәр,
Куркып башлар әйләнәдер.

Күргәннән соң [шунда] аны,
Әйтер төрек халкы аңа:
«Моңа олуглык насыйп булды»,
Шуннан арысы тәмамдыр.

*[Стеблева: 1971. С. 129–130, 253].*

Без килгән нәтиҗәгә караганда, XI йөзнең башында һәм урталарында, мөгаен, нәкъ менә Кашгари язган һәм шулай ук башка чыганакларда чагылган бәрелешләр һәм күчешләр аркасындадыр ахрысы, кимак-кыпчакларның бер өлеше «Дәште кыпчак» һәм Җидесу биләмәләреннән Каманың сул (көньяк) кушылдыгы булган Зәй буйларына да басып кергән булырга тиеш. «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәрендә легендар формада тасвирланган Бараҗ еланы, минем фикеремчә, менә шул читтән кергән елан халкын гәүдәләндерә. Һәм әлеге елан атамасы шактый дәрәҗәдә Бука Будраҗ исеме белән дә тәңгәл килә. Соңыннан инде «бараҗ» җиңүчеләрнең исеме-эпонимы буларак җирле халыкның да исеменә һәм оранына әверелә[2] [Татар халык иҗаты: 1987. 32 б.]. (Оран/уран – сугышчан кычкыру-чакыру авазы, кабиләнең үзенчәлекле пароле).

Моның чыннан да шулай булуына, ягъни Бараҗның Болгар җиренә үтеп кергән елан халкын (ягъни, кимак-кыпчакларны) белдергәнлегенә ышану өчен, тарихи чыганаклардан төрле дәлилләр китерергә мөмкин. Шундыйлардан Риза Фәхретдинов архивында саклангaн һәм тарихчы Миркасыйм Госманов тарафыннан тикшерелгән бараҗ ыруының (кабиләсенең) шәҗәрәсе аеруча игътибарга лаек [Усманов: 1972. С. 174–178]. Анда – бараҗлыларның (белүебезчә, Бараҗ еланы турындагы риваятьтә алар «алыплар заманында», ягъни Болгар чорында Биләр шәһәренә нигез салучылар итеп күрсәтелә) Инсан-бәк шәхесе белән бәйле шәҗәрәсендә – Җадаш-бәктән башланган 20 буын конкрет кеше исемнәрендә (антропонимнарда) санап күрсәтелә. Егерме буын ул һәр

2 Редакция искәрмәсе. Бу унайдан журналыбызда басылган Р. С. Сәетовның «Бүләр(Бараҗ) шәҗәрәсе» дип аталган мәкаләсенә дә игътибар итәргә кирәк (Карагыз: 2018. № 4. 99–118 бб.)

буынга уртача 25-әр ел куеп исәпләгәндә 500 ел дигән сүз, һәм әлеге санны «Дәфтәре Чыңгыз-намә»нең якынча язылу чорыннан – 1650 (±25) елдан чигергәндә 1150 еллар тирәсенә туры килүче ел исәбе килеп чыга. Әгәр инде бараҗлыларның Бүләр / Биләр буенда ныклап төпләнүләренә дә берничә буын гомере китәргә тиешлеген исәпкә алганда, соңгы сан тагын да борынгырак чорга чигәчәк, ягъни бараҗ халкының Зәй буеннан күченеп китүе XI йөзнең башына яки уртасына туры киләчәк. Бу дата гаҗәеп дәрәҗәдә караханилар идарәчесе Арслан-хан Сөләйман ибн Йосыф гаскәрләренең Мәхмүд Кашгарида күрсәтелгән Бука Будраҗ белән сугышуы һәм, минем фикеремчә, елан яугирләренең, җиңелгәч, өлешчә булса да, Зәй буена үтеп керүләре вакытына туры килә. Менә Кашгари сүзлегендәге ул урын: «Всевышний обратил их в бегство в тот день, когда с ним сразился Арслан-тегин» [Кошгари: 1963. Т. 3. 247 б.].

Ике арадагы әлеге сугыш-бәрелешнең датасын шактый дөрес итеп казакъ тарихчысы С. М. Ахинжанов исәпләп чыгарган: «Согласно Кашгарскому, народ змей двинулся в поход при Арслан-тегине, т. е. где-то в промежутке между 1032–1057/58 гг., временем правления Арслан-хана». «Точная дата выплывает при сопоставлении информации Махмуда Кашгарского с данными Абу-ль-Фараджа. В послании несторианского митрополита Самарнада католиксу, отправленном в 1046 г., говорится о появлении в Караханидском государстве неведомого до этого многочисленного кочевого народа. Всадников было якобы 700000 под командованием семи царей» [Ахинжанов: 1989. С. 184–185; Ахинжанов: 1980. С. 53].

Димәк, Җидесу төбәгенә үтеп кергән елан кабиләләре (кимак- кыпчаклар) белән караханилар арасындагы сугыш үз чиратында Болгар җиренә бараҗлыларның (елан кабиләсенең) чынлап та бәреп керүенә китергән булып чыга түгелме?! Бараҗның Болгарга җитү вакыты белән бараҗ шәҗәрәсе хронологиясенең үзара ярашуы да, шулай ук әлеге уртак датаның Җидесу җирендә елан кабиләләренең караханилар белән орышу вакыты белән тәңгәл килүе дә әнә шундый зарури нәтиҗәгә китереп чыгара. Менә шуңа күрә дә 20 буынлы (!) шәҗәрәләре сакланган бараҗлыларны, шәҗәрәгә бәйле легендада Аксак Тимернең дә телгә алынуына карап кына (безнеңчә, бу кычкырып торган анахронизм – даталар, вакыйгалар буталышы!), Алтын Урда дәверенә чигермичә, Болгар дәүләте чоры белән бәйләп карау чын дөреслеккә туры килә дип исәплибез.

Безнең нәтиҗәне куәтли торган охшаш, хәтта турыдан-туры тәңгәл килүче башка төрле дәлилләр дә юк түгел. Мәсәлән, «Ви-пасанк» дигән әрмән эпосында да Мидиянең еланга табынучы җирле халкы алмаш этноним белән «*мар*» дип исемләнә (*мар* – халык этимологиясе буенча һәм фарсыча «елан»), патшалары исә Аждахак дип атала һәм иң характерлысы – әлеге

эпос Тигран II-нең мидиялеләргә каршы сугышына мөнәсәбәтле тарихи вакыйгаларны гәүдәләндерә [Мифы народов мира: 1987. Т.I. С.50]. Яки менә турыдан-туры кыпчаклар һәм алар белән бер федерациядә булган кимаклар белән бәйләнешле саллы мисал. Сыр-дәрьяның түбән агымы буенда яшәүче җирле халыктан язып алынган риваятьтә, XI йөздә Урта Азиядәге угызлар дәүләтен тар-мар иткән кыпчаклар һәм кай-кимаклар шулай ук еланга тиңләнә һәм Сыр-дәрья тамагындагы Джанкент (Янкент/Янгикент=Яңакент) шәһәре еланнар явыннан һәлак булды, – дип күрсәтелә [Ахинжанов: 1989. С.188–189]. Кимаклар кабиләсе «имәк» / «йемәк» атамасының алтайча һәм «кай» сүзенең монголча мәгънәләре дә «елан» дигәнгә туры килә һәм бу исем белән аталучы халыкның тамгасы да «елан» була.

Италия сәяхәтчесе Марко Полоның юлъязмаларында теркәлгән мәгълүмат буенча (XIII йөз), безгә кыпчакларның *Натигай* исемле мәҗүси алласы булганлыгы да билгеле [Алексеев: 1941. С.35]. Себер татарларында әлеге исем «нацагай» рәвешендә сакланган, күктән елан шикелле бөгәрләнеп яки чатлы-ботлы булып төшкән яшенне белдерә [Валеев: 1980. С.199]. Казан татарлары телендәге «*нажҗагай*» (варианты – «*аҗҗаган*») сүзе дә шул ук тамырдан, игеннәр өлгергән вакытта төннәрен офыкта уйный торган яшенне, белүебезчә, шулай диләр. Бу сүзләрнең һәм шуларга бәйләнешле ышануларның нигезе дә төрки бабаларыбыз изгеләштергән елан-сазаганга барып тоташа. Чөнки әлеге канатлы һәм чуклы яки балык койрыклы илаһи зат күк һәм яшенне, явым-төшем һәм сулыкларны бергә бәйли торган образ итеп тә күз алдына китерелгән. Борынгыдан калган сынамышларны искә төшерик: а) Мәхмүд Кашгарида: «Ләү елы килсә, явым-төшем һәм уңыш күп буладыр, чөнки ул суда яши» [Кошгари: 1963. Т.1.330б.]; б) Халыкта: «Салават күперенең (күк еланының) ике башы да суга төшсә, яңгыр булыр».

Ләкин кыпчак-кимакларның Болгар җиренә монголлар явына кадәр үк үтеп керүен исбатларга ярдәм итә торган иң ышанычлы күрсәткеч, әлбәттә, тел. Менә монда инде безгә Болгар чорына бәйләнешле тел катламын нечкәләп һәм чагыштырып тикшергән Р.Г.Әхмәтҗанов, Ф.С.Хәкимҗанов һәм Д.Г.Мөхәммәтшин кебек күренекле тел белгечләренең хезмәтләре җитди таяныч була ала. Үзләренең тикшеренүләрендә алар барысы да Болгар дәүләтенең үзәк шәһәрләре һәм көньяк, көньяк-көнбатыш биләмәләре монголлар килгәнче үк инде кыпчаклашкан булганнар дигән уртак нәтиҗәгә киләләр. Менә әлеге галимнәрнең хезмәтләреннән аерым өзекләр:

а) Р.Г.Әхмәтҗанов: «Племена, говорящие на языках кыпчакского (небулгарского) типа, были уже в составе булгарских племен, пришедших в Среднее Поволжье из Приазовья». «Вышеприведенный комплекс западнокыпчакских, куманских слов, распространенных в Среднем Поволжье уже в мусульманской Булгарии, говорит о том, что кыпчакоязычные пред-

ки татар жили в древней Булгарии и оказали огромное влияние на культуру местного населения». Шулай ук, «Возможно даже, что центры Булгарского государства – города Булгар, Сувар и Биляр – к XII в. уже оказались кыпчакизированными». Тагы бер өстәмә: «В основной, в заволжско-закамской части Булгарии, к началу XIII в. кыпчакское население доминировало... Монгольское завоевание привело к еще большему усилению кыпчакского элемента в Среднем Поволжье» [Ахметьянов: 1978. С. 220, 239–240].

б) Ф.С. Хәкимҗанов, Д.Г. Мөхәммәтшин: «Проникновение западных кипчаков в Волжскую Булгарию [происходило] с начала XI в. (отдельные небольшие группы, видимо, были еще раньше в составе булгарского союза племен). [Они] которые занимались ремеслами, торговлей, земледелием и нанимались в армию. В летописях, например, имеется такой факт: во время похода русских князей на Великий город (то есть на Биляр) в 1183 г. уже на булгарских землях к ним присоединились «Емяковы половцы» во главе с булгарским князем. ***Это были йемеки, одно из тюркских племен, входившее ранее в кимако-кипчакскую федерацию на севере Центральной Азии***» (аерып язу безнеке – М.Б.). «Считается, что к XII в. сформировался обобщенный тип речи более высокого порядка – булгарское наддиалектное койне общетюркского характера... Его устная форма сложилась при подавляющем преимуществе кипчакских элементов, и она была созвучна с деловым языком Золотой Орды» [Мухаметшин, Хакимзянов: 1987. С. 91–93].

Димәк, телчеләрнең мондый нәтиҗәләре легенда-риваятьтәге Бараҗ еланының кимак-кыпчакларны гәүдәләндерүе турындагы безнең карашны тагын да нигезлерәк, ышанычлырак итә. Безнең караш исә, үз чиратында, телчеләрнең нәтиҗәләрен куәтли. Дөрес, әлеге галимнәрнең концепциясендә без килешми торган эклектизм элементлары, нигезсез фаразлар да юк түгел. Мәсәлән, Р.Г. Әхмәтҗановның «татар этносының нигезе» Болгар дәүләте чорында ук барлыкка килгән дип раславы һәм Алтын Урда чорына бәйләнешле «монгол-татар нигезе»н санга сукмавы, татар халкының барлыкка килүендә әлеге ике катламның да бердәй роль уйнавын танымавы. Ләкин әлеге галимнәрнең карашлары болгар теле белән кыпчак-татар теле арасында тигезлек билгесе куймаулары, иске татар телен болгар теленең (ягъни «r – телнең», чагыштырыгыз: хер – кыз, җүр – йөз, тухыр – тугыз, отур – утыз) турыдан-туры дәвамы итеп карамаулары белән көчле. (Игътибар итегез – «болгарчы» галимнәр һәм, гомумән, «болгарчылар» моның нәкъ киресен исбатларга һәм татар телен дә, татарларны да турыдан-туры болгарлардан чыгарырга тырышалар!). Һәм өстәп әйтергә кирәк: алда исемләнгән галимнәрнең Болгар дәүләтендә, болгар этнос-кавеменнән тыш, кимак-кыпчаклар һәм өлешчә угызлар да булганлыгын танулары һәм иске татар теленең чишмә башын шул

телләргә үк илтеп тоташтырулары, һичшиксез, халкыбыз һәм телебез тарихына иң дөрес якын килү булып санала ала. Менә шушы принципиаль аерманы аңламыйча, кайбер яңа буын галимнәренең Болгар дәүләте чорын халкыбызның тернәкләнү-этногенез этабыннан чыгарып ташларга маташулары бер чиктән икенче чиккә ташлану булып тора.

Тагын бер җитди өстәмә. Телчеләрдән академик Н.А.Баскаков белән Г.М.Гарипов татарларның килеп чыгышында кимак-кыпчаклар берләшмәсенә керүче йемәкләр аеруча зур роль уйнаган дип исәплиләр [Гарипов: 1972. №1. С.48–49]. Р.Г.Әхмәтҗановның ачыклавынча, фарсы телле чыганакларда «йемәк» һәм «татар» вакыт-вакыт бер-берсен алмаштырып килгәннәр һәм, аларның телләре, кардәш телләр буларак, көнбатыш кыпчак теленә бик якын торганнар [Ахметьянов: 1978. С.21, 239]. Моңа гаҗәпләнергә кирәкми, кыпчаклашкан кимак кабиләләре (баштагы исемнәре – кай, каи) заманында «татар» исемен йөртүче халыктан чыккан булганнар. Кимаклар шулай ук себер татарларының да төп нигезен тәшкил иткәннәр. Күренекле телче Әмир Нәҗипнең бер үзенчәлекле тикшеренүе дә шушы ук рәткә килеп ялгана. Ул 1312-нче елда Әсир әд-Дин Әбү-Хайан исемле гарәп кешесе тарафыннан Мисырда төзелгән сүзлектә, «кыпчак»ныкы һәм «угыз»ныкы дигән язулардан тыш, бериш сүзләр янында «болгар», «татар», «токсуба», «уйгыр» дигән билгеләмәләр булуына игътибар итә. Шунда ук «токсуба – кыпчак татарларының кабиләләре» («племена из кыпчакских татар») дигән үзенчәлекле гыйбарә булуын да күрсәтә. Галимнең чыгарган нәтиҗәсе кызыклы: «Это объяснение в свою очередь позволяет предполагать, что издавна в Дешти-кыпчак жили какие-то племена, которые называли себя татарами. Если так, то прибывшие в Египет во время правления султана Бейбарса (1259–1277) татарские эмиры (имена которых явно татарские – Кучкар Муган, Тангри-берди, Алабай) являлись коренными жителями кыпчакских степей. ***Следовательно, племена, носившие название татар, жили в Дешти-кыпчаке и до прихода монголов на эту территорию***» [Наджип: 1975. Ч.I. С.45–46] (аерып язу безнеке – М.Б.). Бу инде, димәк, югарыдагы мәгълүматлар монгол-«татарлар»га кадәр үк Болгар җиренә кыпчак-кимак (кимак / йемәк) кабиләләре составында татар исемен йөртүче кавем-этносның да үтеп керү ихтималына юл калдыра дигән сүз. Ләкин «татар» атамасының җыелма этноним буларак кыпчаклашкан болгарларга, шулай ук Идел-Кама буена кат-кат килеп төпләнгән кыпчак-кимакларга һәм алар белән кушылган башка кавемнәргә карата да кулланыла башлавы, һичшиксез, монгол-«татарлар»дан соңгырак чорга туры килгән һәм гомумхалык исеме буларак акрынлап урнашкан. Һәм әйтергә кирәк: ерак бабаларында болгар каны да катнашканлыгын таныган

аерым шәхесләр вакыт-вакыт архаик атама буларак «болгар» этнонимын да тәңгәл рәвештә кулланып килгәннәр.

Без сүзебезне, дөресрәге Болгар чорына бәйләнешле дәлилләребезне, Алабугадан башлаган идек. Ахырда тагын бер кат шул төбәккә мөрәҗәгать итик һәм бу юлы Алабуга шәһәренең атамасына тукталыйк. Минем карашымча, әлеге атама да борынгы ышанулар һәм мифологик легендалар дөньясына алып бара. «Алабуга» сүзен гадәттә русча «окунь» дигән мәгънә белдерүче балык исеме белән бәйләп карыйлар, йә булмаса, җитдирәк фикер йөрткәндә, бу сүзне үгез мәгънәсен белдерүче сүзгә кайтарып калдыралар: димәк, Алабуга атамасы «*ала үгез*» дигәнне белдерә булып чыга. Ләкин, минем карашымча, тәкъдим ителә торган әлеге мәгънәләрнең берсе дә ышандырырлык түгел, чөнки алар тарихи һәм географик реалийлар белән ярашмыйлар. Хәтта сүз барган балыкның башы үгез башына охшаган һәм шуңа «алабуга» (*ала үгез*) дип аталган тәкъдирдә дә ни өчен әлеге атаманың шәһәр исеме булып китүе аңлашылмый.

Минем фикеремчә, Алабуга – борынгы ике төрки сүздән ясалган катлаулы-кушма исем. Аның «*ала*» дигән беренче өлеше элек Үзәк һәм Урта Азиядә, Кавказда яшәгән һун-болгар бабаларыбызның телендә үк булган һәм соңрак чордагы төрки халыкларда сакланган. Ачыклап әйткәндә, Ашина ыруының беренче башлап чыккан төбәгенең исеме – Алашань [Гумилев: 1972. С.75]: әлеге атаманы төзүдә катнашкан һун-төрки сүзе «*ала*» да, кытай сүзе «*шань*» да тау мәгънәсен белдерә. Кыпчак семьялыгына керүче үзбәкләрдә, казакъларда һәм кыргызларда «*ала*» лексемасының борынгы мәгънәсе шулай ук «*тау*», «*калкулык*» [Жанүзак: 2007. 283б.]. Кытай оронимы Тяньшаньның төрки атамалары *Ала+таг*, *Ала+тоо*, *Ала+тау* шушы ук сүз катнашында ясалган; димәк, әлеге кушма исемнәрнең һәр ике яртысы да тау төшенчәсенә туры килә булып чыга. Аерым сүзләрнең баштагы эчтәлеге тоныклангач яисә онытылгач, аларга шул ук мәгънәле башка сүзләрнең катлы-катлы булып ялгануы борынгы топономик атамалар өчен гадәти күренеш. Алтай тавы, Памир системасына керүче Алай сырты, Төркия җирендәге Алаҗадаг, Алаҗаһөйүк исемле тау тезмәләре, Әрмәнстан территориясендәге әрмәнчә Араган, төрекчә Алагеоз дип йөртелә торган тау-калкулык исемнәре дә шул ук тамырдаш атамалар исемлеген дәвам итә. Моннан тыш, төрекмәннәрдә өсте тигез калкулыкны белдерүче «ала+н», тауны белдерүче «ала+нг» сүзләре бар. Һәм, әлбәттә, Алтай телләренә керүче тунгус-маньчжурларда калкулыкның – «ала», монголларда тауның «ола» дип йөртелүе дә, һичшиксез, шушы ук рәткә, уртак тамырга килеп тоташа. Ләкин бу очракта иң әһәмиятлесе шунда: безне кызыксындырган Алабуга атамасы составында да, ягъни аның «ала» өлешендә, минем ышануымча, гасырлар тирәнлегеннән килүче шул ук сүз-тамыр һәм «тау» мәгънәсе ята.

Билгеле, «ала» сүзенең «пегий» дигән борынгы мәгънәсе дә юк түгел, «Алабуга» сүзенең «окунь» балыгын белдерүче вариантында ул нәкъ шул мәгънәдә килгән дә. Әйтергә кирәк: Пермь һәм Чиләбе өлкәләрендәге Алабуга дип йөртелүче күлләр дә үз атамаларын, һичшиксез, суларында шул исемдәге балык булуына карап алынган булырга тиеш. Ә менә сулыкның түгел, ә Кама буендагы шәһәрнең балык исеме белән аталуы аек акылга сыймый. Шуңа күрә дә без «Алабуга»ны кушма исем итеп карыйбыз да һәм географик атамаларның мотлак рәвештә тарихи чынбарлык белән ярашырга тиешлегеннән чыгып, әлеге сүзнең икенче яртысын да җирле фактлар белән бәйләү – иң дөрес юл дип исәплибез.

Ачыклап әйткәндә, Алабуга сүзенең икенче яртысы – буга / бука өлеше, алда XI йөз галиме Мәхмүд Кашгаридан китерелгән өзектә күрсәтелгәнчә, «зур елан» дигән мәгънәгә туры килә. Бука сүзе заманында Арал диңгезе буенда, Дон елгасының түбәнге өлешендә һәм Төньяк Кавказда яшәгән болгар һәм кыпчак кабиләләре аша Көнбатыш Дагыстандагы аерым халыкларга да бераз үзгәргән формада үтеп кергән. Мәсәлән, аварларга якын торучы тиндаль/тиндин телендә «*бека*» – елан, ахвак телендә *бека* – елан, бежтин телендә «*бекела*» – елан, чеченнарда «*бӧха*» – шулай ук елан. Монда без борынгы чор өчен гадәти күренеш булган к һәм г (к=г) авазлары чиратлашуы белән очрашабыз. Чагыштырыгыз: баку/багу, арку/аргу – тау үзәне, йатак/йатаг, бу көн/бүген, аулак өй/аулагый. Әлеге күренеш болгар чорындагы кабер ташы язмалары өчен дә хас: йекет/егет, токыр/токыз/тугыз, битик/битиг – язма, бәлүк/белегъ – билге. Болардан инде без тикшерә торган «буга» сүзенең «бука» белән аваздаш булуы, аның фонетик вариантын тәшкил итә алуы турында нәтиҗә чыгару кыен түгел. Телче тюркологлар хәтта әлеге охшаш яки тамырдаш сүзләрнең килеп чыгышын бергә бәйләп карыйлар һәм гомумалтай телләрендә «буга» лексемасы үгезне генә түгел, ә кыргый яки ерткыч җанварны да белдерү өчен кулланылган дигән караштa торалар [Севортян: 1978. С.230–232, 237.]. Болгар, Казан җирлегендә дә үгез белән елан-сазаган образларын бергә бәйләгән мифологик легенда булганлыгы мәгълүм. Без монда Казан салыначак урында яшәгән ике башлы аждаһаның бер башы үгезнеке, ә икенчесе еланныкы дип сөйләнелгән легенданы күздә тотабыз [Халиков: 1976. С.9].

Монда урынлы сорау туарга мөмкин: зур еланны белдерүче сүз Мәхмүд Кашгарида вӱкӓ/бүкә рәвешендә бирелгән бит, ә Алабуга исемендәге – «буга» калын әйтелешле – мондый күчеш-үзгәрешне ничек аңларга? Безнең карашыбызча, бүкә халык телендә, һичшиксез, бука/буга рәвешендә дә йөргән булырга тиеш. Татар телендә һәм аның көнбатыш диалектында балаларны куркыту өчен кулланылган әлеге архаик сүзнең *букәй/буки* һәм *букай/мукай* вариантларында сакланып калуы шуны раслап тора. Шушы

ук сүз *бука*, *мокай* һәм *мохай* рәвешендә, ягъни калын әйтелештә рус, алтай һәм якут телләрендә дә сакланган. Бу дәлилләр, димәк, «ала» тамырына әлеге лексема нәкъ менә бука/буга формасында ялганган дип карарга ышанычлы нигез була ала. Аннары бу очракта төрки телләргә хас сингармонизм күренешен дә исәптән чыгарырга ярамый. Мәсәлән, без «Алла бирсә» димибез, ә баштагы калын әйтелешле сүзгә ияреп «Алла бирса» дип сөйлибез. Кыскасы, бука/буга сүзенең калын әйтелештә дә булганлыгы яки була алуын раслау өчен дәлилләр җитәрлек дип уйлыйм.

Шулай итеп, без Алабуга атамасы ике өлештән, ягъни борынгы ике төрки сүздән тора дигән нәтиҗәгә киләбез. Аларның беренчесе, *ала* сүзе – «*тау*», икенчесе, буга сүзе исә «*елан*» («*зур елан*») дигән мәгънәләргә туры килә, димәк, икесе бергә «*Тау-елан*» яки «*Елан-тау*» дигән мәгънәне белдерә булып чыга. (Сүз тәртибе үзгәрә-алмашына торган гыйбарәләргә мөрәҗәгать итегез: Тимер-хан – Хан-тимер, Таң сылу – сылу таң, көн озын – озын көн, язамын – мин язам). Бу, әлбәттә, шактый борынгы, архаик гыйбарә, мәгънәсе буенча ул соңгы дәверләрдә кулланыла торган «Елан-тау» (Елан тавы) атамасына туры килә. Димәк, «Алабуга» сүзенең без тәкъдим итә торган мәгънәсе-этимологиясе тулысынча тарихи һәм географик реалийлар белән үзара ярашып тора, ягъни ул «Шайтан каласы»нда яшәгән елан-сазаган турындагы легендага да, шулай ук әлеге каланың шактый текә тау өстенә урнашкан булуына да һәм, әлбәттә, еланны изгеләштергән болгар һәм кимак-кыпчакларның уртак мифологик карашларына да тәңгәл килә.

Инде төп нәтиҗәне ясыйк. Сөйләгәннәрдән күренгәнчә, тарихи фольклорыбыз һәм тел фактлары безне турыдан-туры яки урау юллар белән Болгар җирлегенә илтеп чыгара. Бу, һичшиксез, халык хәтеренең, тарихи аңның Болгар дәүләте тарихына һәм культурасына тоташуы белән бәйле. Алай гына да түгел, безнең этногенетик тамырларыбыз һәм этник аңыбыз, кендегебез өлешчә булса да шунда береккән. Чөнки Болгарның көньяк һәм көнчыгыш биләмәләренә үтеп кергән кимак-кыпчаклар һәм алар кыпчаклаштырган болгарлар татар этносының һәм иске татар теленең тернәкләнә башлавы өчен иң борынгы җирлек булганнар. Бу инде, димәк, Идел-Кама буенда яшәгән бабаларыбызның иң тәүге буыннарының тарихы һәм дәүләтчелегебезнең ул җирлектәге этабы Болгар дәүләте чорына туры килгән дигән сүз.

**Әдәбият**


1. Алексеев М.П. Сибирь в известиях западно-европейских путешественников и писателей. Иркутск: ОГИЗ, 1941.
2. Английские путешественники в Московском государстве в XVI веке. Л., 1938.

3. Ахинжанов С. М. Из истории движения кочевых племен евразийских степей в первой половине XI в. // Археологические исследования древнего и средневекового Казахстана. Алма-Ата: Изд. «Наука» Каз. ССР, 1980.
4. Ахинжанов С. М. Кипчаки в истории средневекового Казахстана. Алма-Ата: «Наука» Казах. ССР, 1989.
5. Ахметьянов Р. Г. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. – М.: Наука, 1978.
6. Бартольд В. В. Сочинения. М.: Наука, 1970. – Т. II.
7. Валеев Ф. Г. Западно-Сибирские татары. Казань: Тат. книжн. изд., 1980.
8. Гарипов Т. М. Махмуд Кошгари и кыпчакские языки Урало-Поволжья // Советская Тюркология. Баку, 1972. – № 1.
9. Гумилев Н. Г. Этническая история Тибета в I тыс. н. э. в связи с историей сопределенных стран // Центральная Азия и Тибет. Новосибирск: Наука, 1972.
10. Жанүзак Т. Казак ономастикасы. Алматы: Дайк-Пресс, 2007.
11. Заринский Платон. Сборник исторических и археологических исследований о Казанском крае. Казань, 1880.
12. Кошгари Мәхмүд. Дивану лүготит түрк. Тошкент: Узбек. ССР ФА нашр. 1963. Т. 3.
13. Мифы народов мира. Энциклопедия. М.: Советская энциклопедия, 1987. Т. 2.
14. Наджип Э. Н. Тюркоязычный памятник XIV в. «Гулистан» Сейфа Сараи и его язык. Алма-Ата: Изд. «Наука» Каз. ССР, 1975. Ч. I.
15. Севортян Э. В. Этимологический словарь тюркских языков. М.: Наука, 1978.
16. Стеблева И. В. Развитие тюркских поэтических форм в XI веке. М. Наука, 1971.
17. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Төзүчесе С. М. Гыйләҗетдинов. Казан: Тат. кит. нәшр., 1987.
18. Усманов М. А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. Казань: Изд. КГУ, 1972.
19. Халиков А. Х. О времени, месте возникновения и названии города Казани // Из истории культуры и быта татарского народа и его предков. Казань: Тат. гос. изд., 1976.

**Төбәк тарихы буенча фәнни мәкаләләр**

**Научные публикации по краеведению**

***Н.Г.Гариф***

# КАЗАН ХАНЛЫГЫ ЧОРЫНА КАРАГАН ЭПИГРАФИК ТАШЛАРНЫ БАРЛАУ, ИСӘПКӘ АЛУ ҺӘМ АЛАРГА СТАТИСТИК АНАЛИЗ

***Аннотация:*** *Статья посвящена исследованию эпиграфических памятников Казанского ханства.*

*Нами проанализированы все, известные до сих пор, надгробные памятники. Для их комплексного изучения необходимо привлечение и других категорий источников – письменных, фольклорных, этнографических, топонимических.*

*Полученные материалы могут быть использованы при изучении проблемы этногенеза и этнической истории народов, а также для уточнения границ Казанского ханства. Материалы и результаты работ планируется представить к обсуждению на конференциях, опубликовать в научной и популярной литературе.*

***Ключевые слова:*** *надгробные памятники, феодально-вассальные отношения, города, населенные пункты.*

Казан ханлыгы чорына караган документлар күп сакланмаган. Шул сәбәпле ханлыкның тарихи, мәдәни һәм матди культурасын ачыклау, икътисадый һәм хуҗалык тормышын өйрәнү, төбәкнең тарихи географиясен барлауда археология, эпиграфика һәм нумизматика материаллары кыйммәтле чыганак булып тора.

Идел буеның атаклы археологы А.П.Смирнов: «*Кабер өсте язулары Алтын Урданың барлык өлкәләреннән бары тик Болгар җирендә генә таралган*», – дип яза. Бу эпитафияләрнең нәкъ менә тарихи Болгар җирләрендә таралуын тикшерүче галимнәр ислам дине, мәдәнияте һәм мәгарифе үтеп керүе белән аңлаталар. Әлеге үзенчәлек, Болгар, Алтын Урданың дәвамчысы Казан ханлыгына да хас. Шул сәбәпле ташъязма чыганакларны өйрәнү ханлык чоры тарихын ачыклауда мөһим роль уйный.

XIX гасырда Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорлары тарихын өйрәнү юлында археологик тикшеренү эшләре башланып китә. 1877-нче елда Казан университеты каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте (ОАИЭ) төзелә. Җәмгыять эшчәнлегендә И.А.Износков, С.М.Шпилевский, К.И.Невоструев, Н.А.Толмачев кебек тарихчылар актив катнашалар. Алар Казан ханлыгының төрле төбәкләрендә урнашкан тарихи урыннарны, әлеге җирлектәге эпиграфик һәйкәлләрне барлау һәм өйрәнүгә күп хезмәт куялар.

Аталган җәмгыять эшчәнлегенә, туып килүче милли тарих мәктәбенә фәнни юнәлеш бирүчеләр буларак саналырга хаклы, татар тарихчылары Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, К.Насыйри, Г.Әхмәров, Р.Фәхретдин һ.б. кушылып китә.

Татар халкы үткәнен өйрәнүче тарихчылар өчен совет чорының башлангыч вакыты – 1920–1930-нчы еллар арасында яңа мөмкинчелекләр туа. М.Г.Худяков, Һ.М.Атласи, Г.А.Гобәйдуллин һ.б. тарихчылар, Казан ханлыгының үткәнен өйрәнеп, аның дәүләт төзелешен, иҗтимагый-сәяси һәм икътисадый тарихын ачыклауны үзмаксат итеп куялар. Әлеге эшчәнлеккә ханлык чорыннан ук сакланып калган кабер ташларындагы язулар да ачыклык кертү сәбәпле, аларны өйрәнү эшчәнлегенә дә ихтыяҗ туа.

Әмма яңарыш чоры озак дәвам итми. Сталинизм чорында – 1930-нчы еллардан алып 1950-нче елларның уртасына чаклы, Казан ханлыгы тарихын өйрәнү партия күзлегеннән чыгып, мәгълүм бер кысаларга куып кертелә. Шуңа да карамастан, ул чор тарихчылары Н.И.Воробьев, Н.Ф.Калинин, Х.Г.Гыймади, Ф.Ш.Мөхәммәдьяров, текстолог Г.М.Рәхим, эпиграфист Һ.В.Йосыпов һ.б. тарафыннан Казан ханлыгы чорына караган күп кенә археологик, эпиграфик һәм башка язма мәгълүматлар туплана һәм фәнни әйләнешкә кертелә.

Совет чорында эпиграфик чыганакларны барлау, өйрәнү дәвам итә. Болгар, Алтын Урда, ханлык чорларына караган зират-каберлекләрнең каберташ язмалары А.Х.Халиков, Р.Г.Фәхретдинов. Ф.С.Хәкимҗанов, Җ.Г.Мөхәммәтшин, М.И.Әхмәтҗанов һ.б. тарихчылар, текстологлар тарафыннан өйрәнелгән.

Соңгы елларда кабер ташларын өйрәнү эшчәнлегендә Н.И.Исмәгыйлев (Нәккаш), Р.Ф.Мәрдәнов, И.Г.Һадиев, И.А.Мөстәкыймов кебек мәгълүм тарихчылар хезмәт кертте.

Шуңа да карамастан, Казан ханлыгы дәверенә караган кабер ташлары әле һаман да табыла һәм өйрәнелә тора. Мисал өчен, 1957-нче елда XVI гасырның беренче яртысына караган 150 эпиграфик һәйкәл билгеле булган. Әлеге һәйкәлләр 50 дән артык торак урыннары янында урнашкан [Юсупов: 1960]. Бүгенге көндә XVI гасырның беренче яртысына караган

һәйкәлләрнең саны, 90-га якын торак биләмәсе тирәсендә – 260-ка җитә *(Татарстан җирлегендә урнашканнары гына исәпкә алынды)*. Бу очракта ханлык җирләренең бер өлеше *(Татарстан Республикасыннан тыш)* булган урыннарда эпиграфик һәйкәлләрнең соңгы елларда актив рәвештә өйрәнелмәвен дә билгеләп узарга кирәк. Мәсәлән, 1955-нче елларда Чуваш Республикасы җирлегендә урнашкан 22 торак урында мөселман кабер ташлары билгеле булган. Аларның таралыш чиге Сура елгасына чаклы җиткән [Воробьев, Львова, Романова, Симонова: 1956. С. 38–39.].

Казан ханлыгының татар халкы күпләп яшәгән үзәк җирләрендә бүгенге көнгә 290 кабер ташы билгеле (*тулаем алганда 296 таш. Фәнни яктан өйрәнелгәннәре генә исәпкә алынды*). Әлеге язулы кабер ташлары 93 авыл биләмәсендә урнашкан (*Биектау районының 21 авылында 77 таш; Арча, 16–60 Әтнә, 8–52; Яшел Үзән, 13–26; Питрәч, 8–17; Саба, 7–10; Балык бистәсе, 4–8; Теләче, 4–9; Кайбыч, 2–6; Балтач, 2–3; Югары Ослан, 2–3; Тәтеш 2–2; Апас, 1–1; Лаеш, 1–1; Мамадыш, 1–1; Алексеевск, 1–1*; Казан шәһәре биләмәсендә – 11 (*1 таш 1996 елда Благовещение соборында, 5-се 2004-нче елда кремль биләмәсендә, 1-се Бауман урамының Дәүләт музее (метро) тирәсендә, ике кабер ташының кисәкләре ханнар зираты урынын археологик тикшерү вакытында*) кабер ташы табылды.

Эпиграфик һәйкәлләр Казан шәһәре тирәсендәге 16 районның биләмәсендә урнашкан.




1-нче рәсем. Һәйкәлләрнең Казаннан читтә урнашуы һәм хисабы.

А – Казан; Б – Шаһгали авылы; С – Алат; Д – Хан гаскәре урнашкан төбәк; Е – Арча; F – Мишә-Тамак шәһәрлеге (Эзмә җирлеге); G – Чаллы шәһәрлеге; Н – Казан ханлыгы үзәк җирләренең төньяк чиге.

Кабер ташларының урнашу географиясе дә игътибарга лаек. Мәсәлән: ханлык чорына һәм аның үзәктәге җирләренә караган ике кабер ташы Ка-

заннан төньякка таба 120 чакрым ераклыкта урнашкан (*Балтач районы, Смәил авылы*). Казаннан иң көнчыгыш тарафка таба урнашкан таш – 115 (*Мамадыш районы, Бөрсет-Сукачы авылы*), иң көньякта тарафтагысы – 130 чакрым ераклыкта табылган (*Тәтеш районы Мантово авылы*). Иң көнбатыштагы ханлык чорына караган кабер ташы Казаннан 160 чакрым ераклыкта, Чуваш Республикасының, Ядрин районы, Чебак авылында урнашкан.

Язма чыганаклар буенча Казан ханлыгының үзәк җирләрендә генә дә 700 торак урыны булуы мәгълүм (*бу исемлеккә юкка чыгарылган, язу-теркәү кенәгәләрендә «тустошь» буларак билгеләнгән һәм археологик һәйкәл буларак искә алынган авыллар керми*). Казан шәһәреннән 25–30 чакрым ераклыкта урнашкан бүгенге көндәге татар авылларның зур өлеше ханлык чорындагы авыллар урыны белән тәңгәл килә. Шул сәбәпле, эпиграфик һәйкәлләрнең әлеге татар авыллары белән янәшә табылуы да игътибарга лаек.

Мисал өчен, бүгенге Лаеш районы җирлегендә ханлык чорында 93 татар авылы булган (*1992-нче елда исә район биләмәсендә урнашкан 70 авылның бары 8 генә татар авылы* [Галлямов: 1997. С.63–82]). Шул ук вакытта Лаеш районында бары бер генә язма кабер ташы табылуы билгеле (*Элекке Япанчы авылы биләмәсе*). Билгеле ки, аның сәбәбе Казан ханлыгы яулап алынганнан соң татар халкының бу төбәктән тулаем куылуы һәм бушап калган җирләргә урыс халкын һәм яңа чукындырылган башка халыкларны күчереп утыртылуында. Килгән халык тарафыннан кабер ташлары юкка чыгарылган һәм хуҗалык эшчәнлегендә кулланылган.

Югарыда билгеләп узылганча, татар халкы шәһәрләр тирәсеннән 30, зур елгалардан 15–20 чакрым ераклыкка куылган, ә аларның торак урыннары юкка чыгарылган яисә яулап алучылар тарафыннан үзләштерелгән (*урыс колонизациясе ханлыкның үзәк җирләрендә урнашкан 206 авыл һәм 60-лап бушап калган авылларны үз эченә алган.* [Измайлов: 2003]). Әлеге очрак эпиграфик һәйкәлләрнең таралышы һәм сакланышына да йогынты ясаган. Мәсәлән: Биектау районы биләмәсендәге кабер ташлары Казан шәһәреннән 15–25, Яшел Үзәндәгеләре – 30, Питрәч районындагылары – 45, Лаеш районындагысы – 50 чакрым ераклыкта гына сакланып калган.

Казан шәһәрендә зур күләмдә археологик тикшерү эшләре уздырылуына чаклы 1814-нче елда төзелеш эшләре вакытында табылган 1 кабер ташының сакланып калганлыгы гына билгеле иде (*хәзерге Кремль урамы, Дәүләт музее биләмәсендә табыла* [Мәрҗани: 1989; Фукс: 1817]). 1530-нчы ел белән билгеләнгән әлеге кабер ташын, татарлар губернатордан рөхсәт алып, Мәрҗәни мәчете стенасына урнаштырулары сәбәпле генә ул бүгенге көнгәчә яхшы сакланган.

Графиктан күренгәнчә (1-нче рәсем) Мәскәү колониаль сәясәте нәтиҗәсендә татарларның Казан шәһәре тирәсеннән куылуы эпиграфик һәйкәлләрнең саклаңыш дәрәҗәсендә дә билгеләнә. Килмешәк халык һәм шәһәр тирәсендә урнашкан чиркәү-монастырь җирбиләмәләре хуҗалары ислам динен чагылдырган кабер ташларына тискәре караштa булган. Риваятьләр, язып калдырган истәлекләр буенча кабер ташлары чиркәүләр, таш биналар төзелешендә һәм башка төр хуҗалык эшчәнлегендә кулланыла (*Мәсәлән, 1996-нчы елда, Благовещение соборы стенасында мөселман кабер ташы табыла* [Нәккаш: 1997. 14б.]).

Эпиграфик һәйкәлләрне өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләре белән хронологик тәртиптә танышканда кабер ташлары саны кимүе, бер өлешенең эзсез юкка да чыгуы, XX гасырда да күзәтелә. Тарихи һәйкәлләр табигать тарафыннан тыш җирле халык тарафыннан да юкка чыгарылган. Элекке чорларда халыкның төрле хорафатларга бирелүе, динилегенә бәйле гарәп язулы ташларга ихтирам белән каравы, кабер ташларының сакланышын гасырлар буена тәэмин иткән. Үзган гасырдагы гайре үзгәрешләр – дингә каршы көрәш һәм җирне уртак милек итеп, көчләп күмәкләштерү борынгы зиратлар һәм алардагы кабер ташларының сакланышына тискәре йогынты ясый (*1999-нчы елда Балык бистәсе районы, Чураш авылы янындагы кырдан табылган ташларның берсе 1530-нчы елга карый. Борынгы зират революциягә чаклы халык тарафыннан сакланган* [Гариф: 2006. 175б.]).

Казан ханлыгы чоры эпиграфик һәйкәлләре үзәктән читтәге төбәкләрдә дә сакланган. Казаннан 330 чакрым ераклыкта, төньяк тарафта урнашкан төбәк, бүгенге көндә Киров өлкәсе Слободск районы Нократ (Кариле-Карино) авылы буларак билгеле. Кариле авылында югары катлам ияләренә куелган 3 кабер ташы яхшы дәрәҗәдә сакланган.

Ханлык чорына караган эпиграфик һәйкәлләр бүгенге Чуваш Республикасы биләмәсендә дә бар. Гарәп язулы ташлар урнашкан борынгы зиратлар (*сирәк кенә рун язулы ташлар да очрый*) Чебоксар районының Яуш, Моргауш районының Ирхкасы, Цивиль районының Тойсин авыллары зиратларында урнашкан. Әмма язулы ташларның төп өлеше Чуваш иленең көнчыгыш, һәм көньяк тарафтагы биләмәләрендә сакланып калган. (*Козлов, Урмар, Янтык Ялчык, Батыр районнарында* [Иванов, Николаев, Димитриев: 2000]). Санап үтелгән районнардагы ташларның зур өлеше безнең тикшеренүләргә керми калдылар.

Безнең тарафтан исәпләнгән 296 кабер ташының 90-нан артыгында 80–100 % ташның куелу вакыты, таш куелган шәхеснең исеме, дәрәҗәсе, ташны куючы һәм башка төр мәгълумат сакланып калган. 18 ташта (20 %) җирләнүченең «кяфер кулындин», «Мәскәү», яисә «урыс явы килгәндә»

шәһит китүләре турында искә алынган. Сакланып калган эпиграфик һәйкәлләрнең күплеге һәм эшләнеш дәрәҗәсе буенча дәүләтнең тыныч яшәеш чорындагы икътисади үсеше һәм сугышлардан соң туган авырлыклар да чагылыш таба (2-нче рәсем).




Рис. 2. Еллар хисабына бәйле куелган кабер ташларының саны.
***А–В*** – Иван III тарафыннан 1467, 1469, 1478, 1482, 1484, 1485 һәм 1487 нче елларда оештырылган сугышлар. ***В–С*** – 1508–1523 еллар арасындагы тыныч тормыш; ***С–Д*** – 1523–1530 нче еллардагы Казанга каршы оештырылган сугышлар; ***Д–Е*** – 1530–1547 нче еллар арасындагы тыныч тормыш; ***Е–F*** – 1540 еллардан соң Казанга каршы оештырылган сугышлар.

Язмалардан күренгәнчә, әлеге эпиграфик һәйкәлләр күп очракта югары катлам әһелләренә: дәүләт хезмәтендәге җитәкчеләргә, гаскәр башлыкларына, абруйлы дини руханиларга, эре җир биләүчеләргә һәм аларның гаилә әһелләренә куелган.

Дәүләт хезмәтендә булган югары катлам кешеләре Казанда яшәсәләр дә, аларның хан ярлыгы белән беркетелгән, хан тарафыннан бүләк ителгән җир биләмәләре, авыллары булган. Еш кына җәй көне алар шул авылларында, үз җирләрендә ял иткәннәр, монда аларның утарлары, җәйге йортлары булган, хезмәтчеләре торган. Вафат булган очракта да аларны күбесенчә үз утарларында җирләгәннәр. Акрынлап бер урынга гаиләнең шактый әһелләре тупланып, гаилә каберлекләре дә барлыкка килгән. Бер үк урында бер үк типтагы кабер ташларының куелуы шул хакта сөйли. Шундый ук ташлар җирле идарәчеләрнең югары катлам кешеләренә дә

куелган. Кабер ташлы зиратлар күп очракта зур мәйдан биләми. Шул сәбәпле гади игенчеләр, терлекчеләрнең зиратлары аерым җирдә урнашулары турында да фикер йөртергә мөмкин. Бай, мәһабәт каберташлар янында гади, кечкенә ташлар очрамый. Әлеге фикер таш язмаларга анализ ясаганнан соң да ныгый.

Казан ханлыгының төп байлыгы – җир. Ханлыктагы җирләр, дәүләтнең иминлеген тәэмин итү чарасы буларак, хан тарафыннан үзенең якыннары, дәүләт идарәсендә урын биләгән төрле дәрәҗәдәге бәк-морзалар, хәрби оглан-казаклар, дини вакыф биләмәләре, җирле бәкләр һәм башка сыйнфый баскычта торучылар арасында бүленгән. Казан ханлыгының матди яктан яшәеше җир бүленеше һәм салым җыю системасы аша тәэмин ителгән. Ханлык җирләре салым җыю өлкәләре – даругаларга һәм вассал олысларга бүленгән. Даругалар үз чиратында хәрби берәмлекләр: йөзләр һәм уннардан торган. Олыслар – ханлыктагы феодал вассал биләмәләр. Олыс җирләренә ия булу хокукы нәселдән-нәселгә күчү принципына нигезләнгән. Феодал вассаллык мөнәсәбәтләренә тархан (*сөергал*) ярлыклары аша кануни төс бирелгән. Югары катлам кешеләре тархан (*сөергал*) биләмәләрен нәселдән-нәселгә тапшыру өчен тырышкан. Феодал вассаллыкның нигезендә хәрби хезмәт, ясак җыю һәм башка төр салымнар аша түләү системасы яткан. Хан, дәүләт тарафыннан җирдә эшләүче һәм шул җирдән ясак түләүче халыкка иминлек тудырган, аларның хокукларын яклаган.

Дәүләттәге феодал вассаллык мөнәсәбәтләре җир бүленешенә, дәүләткә хезмәт, дини һәм милли тормыш иминлегенә бәйле урнашкан. Казан ханлыгында җир, төп байлык буларак, җир биләүченең социаль һәм сәяси дәрәҗәсен (урынын) билгеләгән. Югары катлам вәкилләре үз биләмәләрендә тулы хакимлеккә ия булу хокукын алганнар [Гариф: 2010. 128 б.].

Югарыда билгеләп узылган Казан ханлыгындагы сыйнфый бүленеш һәм ханлыкның яшәеш системасы эпиграфик һәйкәлләр буенча да ачыклана. Кабер ташлары язмаларындагы дәүләт идарәсе, хәрби, дини һәм җирле феодалларның исем-шәрефләре, иерархик катламда тоткан урыннары һәм аларның кул астында булган биләмәләре чагылыш таба. Эпиграфик һәйкәлләрне өйрәнеп, аларга анализ ясап ханлык чорында үзәк белән төбәкләр арасында урнашкан хокукый мөнәсәбәтләрне ачыклау мөмкинчелеге дә туа.

### Татар эпиграфик кабер ташларыннан түбәндәге мәгълүматларны алырга була:

1. Таралу географиясенә бәйле халыкның урнашуы;
2. Феодалларның титул-дәрәҗәләренә бәйле хакимият төзелеше;
3. Сәяси-сыйнфый һәм дини катламнарның бүленеше;

4. Ташларның урнашуына бәйле торак урыннары, олы юллар яисә сугыш кырлары турында мәгълүмат;
5. Традицион язу үрнәге, башлам текстлары, бизәк – орнаментлары, геометрик күләм һәм форма үзенчәлекләренә бәйле шул чорда сәнгать үсеше;
6. Ташлардагы еллар исәбе һәм исемнәрнең үзенчәлегенә бәйле мәгълүмат аша җирлектәге халыкның яшәеш чорын һәм төрле үзгәрешләрне ачыклау.
7. Таралу географиясенә бәйле халыкның урнашуы;
8. Феодалларның титул-дәрәҗәләренә бәйле хакимият төзелеше;
9. Сәяси-сыйнфый һәм дини катламнарның бүленеше;
10. Ташларның урнашуына бәйле торак урыннары, олы юллар яисә сугыш кырлары турында мәгълүмат;
11. Ташлардагы еллар исәбе һәм исемнәрнең үзенчәлегенә бәйле мәгълүмат аша җирлектәге халыкның яшәеш чорын һәм төрле үзгәрешләрне ачыклау.

## Казан ханлыгы чоры ташларына уелган аятьләр һәм гыйбәрәләрдән мисаллар.

1. Аллаһыдан башка илаһи зат юк.
2. Аллаһының әмереннән качып булмый.
3. Ул [Аллаһы Тәгалә] үлемсез, ә башка һәрбер тереклек иясе үләчәк.
4. Дөнья бер сәгатьлек, аны гыйбадәт белән үткәр.
5. Бары тик җиңелү белмәс кодрәт иясе, Олуг Аллаһ кына мәңге калачак (*55 – Рахмән сүрәсе, 27 аять*).
6. Җир йөзендәге җанлыларның барысы да юкка чыгачак (*55 – Рахмән сүрәсе, 26 аять*).
7. Аллаһу Тәгалә әйтте: «Һәрбер җан иясе үлем ачысын татыр. Аннан барыгыз да Безгә (Аллаһка) әйләнеп кайтырсыз». (*29 – Ганкәбүт* (*Үрмәкүч*) *сүрәсе, 57 аять*).
8. Аллаһу Тәгалә әйтте: «Һәм белми җан иясе кайсы җирдә үләсен». (*29 – Ганкәбүт (Үрмәкүч) сүрәсе, 34 аять*).
9. Дөнья – үләксәдер, аның артыннан куучы эттер. Варианты: Бу дөнья үләксәдер, аны этләр эзләп йөрер.
10. Күрәмен дөньяны вәйран (җимерек) булган хәлдә, берни дә мәңгелек түгел – Аллаһының моңа карары юк.
11. Бу дөньядагы барлык авырлыкларга сабыр кеше дә вакытыннан алдан үлмәс.
12. Үлем сине үз вакыты киләчәген искәретеп торыр, ә каберең кылган гамәлләреңнең сандыгы булыр.

13. Үлем өчен бәхет килде... Ә бездән шатлык кош кебек очып китте..., аны эзләүчеләр инде табалмас.

## Әдәбият


1. Воробьев Н.И., Львова А.Н., Романова Н.П., Симонова А.Р. Чуваши, Ч. 1, Чебоксары, 1956.
2. Галлямов Р.Ф. Селения Лаишевской стороны в XVI–в начале XVII вв. // История Лаишевского края, 1997.
3. Гариф Н.Г. Казан ханлыгы чоры ташъязмалары. Казань, ТФА: Тарих Институты басмаханәсе, 2010. 128 б.
4. Гариф Н.Г. Казан ханлыгы. (Оешу тарихы, идарә системасы, админстратив бүленеше һәм феодал вассаллык мөнәсәбәтләре.). Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2006. 175 б.
5. Иванов В.П., Николаев В.В., Димитриев В.Д. Чуваши: этническая история и традиционная культура. Москва, 2000.
6. Измайлов И.Л. Татарский народ после 1552 года: потери и приобретения. // Материалы научно-практической конференции. Казань, 2003.
7. Карл Фукс. Краткая история города Казани. Казань, 1817.
8. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбәр фи әхфәли Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр.) / Ш. Мәрҗани; тәрҗемә итүче һәм төзүче Ә.Н. Хәйруллин. Казан: ТКН, 1989.
9. Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйл. Христиан чиркәвендә мөселман ядкәрләре// Мәдәни Җомга. 1997. № 18.
10. Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1960. 165 с.: ил. и прил.

*Ф.А. Байрамова*

## ВКЛАД М.Г. ХУДЯКОВА В ИСТОРИЮ ТАТАРСТАНА[1]

Известного ученого Михаила Георгиевича Худякова многое связывает с татарами – родился он в 1894 г. в г. Малмыже, где половина населения были татарами; с 1906 по 1924 гг. жил, учился и работал в Казани; да и после переезда в Ленинград часто возвращался в Казань. И самое главное, его основные исторические труды написаны о татарах – начиная с древнейших времен, кончая новой эпохой. Худяков создал своеобразную летопись истории татарского народа. Творческое наследие ученого насчитывает около 60 работ, посвященных актуальным проблемам истории, этнографии и культуры татар. Несомненно, что одной из причин, повлиявших на формирование интереса к проблемам национальной истории, стало тесное знакомство с культурой татар, проживавших в г. Малмыже Вятской губернии и учеба в Казани – центре татарской цивилизации. Очевидно, свое воздействие оказало и знакомство с видными татарскими учеными и общественными деятелями, такими как Газиз Губайдуллин, Саид Вахитов, Хади Атласи, Гаяз Максудов, Гаяз Исхаки и др. Нельзя не учитывать и фактор большой заинтересованности национально ориентированной власти Татарстана в начале 1920-х гг. в углубленном изучении проблем историко-культурного наследия.

В первые годы Советской власти центральные и местные органы Народного комиссариата просвещения и Народного комиссариата по делам национальностей уделяли большое внимание проблемам развития национальной культуры и науки. Комиссариат по делам мусульман Наркомнаца включил в круг своих главнейших функций также вопросы культуры и науки национальных регионов. В 1918 г. и в Казани была организована Научная коллегия при отделе просвещения Комиссариата по делам мусульман Наркомнаца. После образования ТАССР преемником Научной коллегии стал Научный отдел, созданный при Наркомпросе республики [НА РТ. Ф.Р. 36–82. Оп. 1. Д. 5. Л. 40.]. Перед отделом была поставлена задача организации всей научной деятельности республики для планомерного изучения края, его естественных богатств, социальных, исторических и этнографических особенностей. Заведующим отделом был назначен Б.Н. Чернышевский, ученым секретарем – Е.И. Чернышев. Заведующим подотделом историко-филологических наук, археологии и этнографии стал М.Г. Худяков. Все сотрудники Научного отдела были утверждены с 15 октября 1920 г. За год своей работы отдел сумел разработать план изуче-

1 Статья подготовлена в связи с 125-летием ученого.

ния истории и культуры татарского народа, внес существенный вклад в развитие науки в Татарстане, реализовал первые шаги по налаживанию научно-исследовательской деятельности в области татароведения.

Надо отметить, что Михаил Худяков в те годы был молодым, начинающим ученым. Несмотря на это, ему доверили очень важную идеологическую отрасль – курировать направление гуманитарных наук, в том числе и историко-филологическое направление. Среди намеченных Худяковым исследовательских тем выделим следующие: «История татарской литературы» (выполнено), «Библиографический указатель по истории татар» (выполнено), «История хазар» (выполнено), «Этнография тюрко-татарских народностей», «История татарской культуры», «Этнология татаро-башкир» и т. д. Надо отметить, что кроме блестящего знания иностранных языков, Михаил Худяков знал и языки коренных народов Поволжья, в том числе татарский и старотатарскую письменность (арабский).

Как известно, до этого Худяков в 1918 г. окончил Казанский государственный университет, успел проработать учителем истории и заведующим историческим отделом Губернского музея. Худяков с увлечением занимался разбором коллекций археологических и этнографических предметов, поступающих в Центральный музей. Приток экспонатов был в этот период весьма значительным. Несмотря на тяжелые бытовые условия, именно в начале 1920-х гг. М. Г. Худяков активно участвует в подготовке экспозиций, организаций выставок, ведет научно-исследовательскую работу. Здесь он проявляет себя блестящим знатоком музейного дела, которое он изучает до тонкостей, по-своему видит его будущее. Ученый становится одним из членов музейной комиссии при Научном Центре, членом Комиссии по сохранению исторических памятников, является автором раздела, посвященного Булгару в Путеводителе (1920), поднимает проблему музеев в казанских школах. [Центральный музей ТАССР. Ф.Р. 2021]. Можно с уверенностью сказать, что Михаил Георгиевич Худяков является основоположником музейного дела в Казани, да и в ТАССР в целом. В фонде Центрального музея ТАССР [Р. 2021] хранятся делопроизводственные материалы, раскрывающие деятельность М. Г. Худякова в качестве хранителя историко-археологического отдела, заведующего историческим отделом музея. Ценную информацию о научно-исследовательской, экспозиционной, собирательской работе М. Г. Худякова содержат составленные им о работе отдела за 1919–1923 гг. отчеты.

Совмещая работу в музее с преподавательской деятельностью, в 1919–1922 гг. М. Г. Худяков являлся преподавателем кафедры археологии Северо-Восточного археологического и этнографического инсти-

тута. Худяков читал в Институте, а затем и в Академии общий курс по археологии Поволжья и Приуралья, а также специальные – «Археологию бронзового века Волжско-Камского края» и «Историю археологии». Кроме того, в 1921 г. он являлся заведующим учебной частью Академии [Кузьминых: 2004. С. 36; РА ИИМК РАН. Ф. 2. Оп. 1. Д. 716. Л. 136]. Следует отметить, что именно М.Г. Худяков, совместно с Б.Н. Бречкевичем, Г.Ш. Шарафом, А. Максудовым и М.В. Бречкевичем стали инициаторами преобразования Института в Академию. Новым ректором был назначен Н.Н. Фирсов, однако М.Г. Худякову так и не удалось стать профессором по кафедре археологии. В конце 1921 г. на эту должность по представлению Н.Ф. Катанова и С.П. Шестакова был избран В.Ф. Смолин, к нему перешли и курсы, ранее читавшиеся М.Г. Худяковым. Можно сказать, что дореволюционная школа археологии, старая университетская профессура победила неопытного, молодого ученого. Как известно, Михаил Худяков был настроен резко к старой университетской профессуре. Причина нарождающегося конфликта была прежде всего идеологического свойства, Худяков обвинял дореволюционных русских этнографов в проведении миссионерской деятельности среди порабощенных народов Российской империи.

В 1923 г. М.Г. Худяков становится одним из создателей «Общества Татароведения», которое сыграло важную роль в изучении истории, этнографии и культуры народов Поволжья. Отметим, что на первом же заседании Общества был заслушан доклад М.Г. Худякова, ознакомившего присутствовавших с основными выводами своего труда по истории Казанского ханства. Доклад этот вызвал оживленный обмен мнениями, где были затронуты некоторые спорные вопросы татарской истории. В целом, первое заседание стало удачным началом широко развернувшейся в дальнейшем деятельности Общества, сумевшего за короткий срок внести свой вклад в изучение малоисследованных тюркских культур России [Фаттахова: 2000. С. 142–143; Бороздин: 1924. Кн. 1 (6). С. 67–72].

Молодой ученый Михаил Худяков работал секретарем «Общества Татароведения», он составлял археологическую карту ТАССР. В эти годы М. Худяков выступает в «Обществе Татароведения» с двумя событийными в исторической жизни города, докладами. Тема первого – «Борьба Казани с Москвой» (1923, 25 июля), второго – «Деревянное зодчество Казанских татар» (1924, 13 сентября). В эти годы М.Г. Худяков издает самые ценные для татарской исторической науки труды. Отдельными книгами выходят «Мусульманская культура в Среднем Поволжье» (1922) и «Очерки по истории Казанского ханства» (1923). Кроме этого на страни-

цах казанских газет и журналов он печатает десятки работ, посвященных истории татарского народа.

Становление Худякова как историка пришлось на период, когда образование ТАССР и некоторые временные послабления во внутренней политике возродили надежды на создание на основе советской Конституции национального государства, которое в какой-то мере компенсировало бы многовековое прозябание татар в рамках колониального региона. Правительство Кашафа Мухтарова, пришедшее на смену выдворенному из республики Саид-Галиеву, пыталось организовать своеобразный татарский «ренессанс». Среди наиболее заметных дел, которые успело осуществить это правительство, были: ликвидация последствий голода, возвращение татарских деревень на берега Волги в окрестности Казани, существенное повышение статуса татарского языка как государственного, постройки первой послереволюционной мечети на берегу Кабана и многое другое. Велась также активная подготовка к празднованию 1000-летия ислама на Волге. Именно в контексте этих событий надо оценивать выход в 1923 г. книги М. Г. Худякова «Очерки по истории Казанского ханства» и брошюры, посвященной исламской культуре в Поволжье, получивших высокую оценку в прессе [Султанбеков: 2002. № 1/2. С. 108].

Таким образом, становится очевидным, что в первой половине 1920-х гг. в казанский период творчества М. Г. Худякова активно разворачивается научно-организационная и исследовательская деятельность по изучению истории и культуры поволжских народов, прежде всего, татарского. М. Г. Худяков стал одним из наиболее активных ученых, разрабатывавших актуальные проблемы татароведения, поддерживавших тесные отношения с нарождающейся новой национальной интеллигенцией, татарскими историками. Именно в этот период, по мнению современных исследователей, М. Г. Худяков создает целую серию работ, посвященных истории и культуре татарского народа и истории Казани, опубликованных в периодических изданиях. От небольших статей и работ, посвященных отдельным аспектам истории, он переходит к созданию широкой исторической панорамы региона.

Вершиной научных исследований М. Г. Худякова стали «Очерки по истории Казанского ханства». Опубликованная в первые годы советской власти, когда старое имперское идеологическое давление на науку было еще ощутимо, но идеи марксизма уже внедрялись в историческую науку, она представляла собой попытку создания новой концептуальной модели изучения этого средневекового татарского государства, стала этапной в плане преодоления имперских традиций русской историографии в отно-

шении к татарскому народу и другим народам Поволжья. Можно сказать, что это было первое действительно подробное и цельное изложение истории Казанского ханства. Эта «чрезвычайно смелая по концепции работа, отличающаяся свойственной для ученого многоплановостью затронутых вопросов, еще не нашла достойной историографической оценки», – пишут современные ученые [Гришкина, Худяков: 2004. С. 16].

Эта книга соответствовала духу своего времени, так как тогда шел процесс восстановления татарской культуры и духовности. История Казанского ханства виделась одним из самых важных этапов в жизни татар, когда в российской гуманитарной науке уже начали господствовать интернационалистические, антиимперские подходы к прошлому своей страны. М.Г. Худяков, в отличие от прежних представителей традиционных антитатарских концепций, попытался написать объективную и взвешенную историю Казанского ханства. Хотя сам Худяков отмечал, что эта книга написана лишь для привлечения внимания знатоков и специалистов на данный предмет, она остается до сих пор во многом непревзойденной. Следует признать, что до настоящего времени не было опубликовано ни одной крупной и комплексной монографии по истории Казанского ханства такого же масштаба.

В фонде Народного комиссариата просвещения ТАССР отложился протокол президиума Коллегии Татнаркомпроса от 19 октября 1922 г. о выдаче Худякову премии в размере 20000 руб. за его работу «История Казанского ханства». Коллегия Татнаркомпроса постановила запросить от Академического Центра отзыв на работу М.Г. Худякова, поручив это сделать Г.Г. Максудову и А.С. Сайфи [НА РТ. Ф.Р. 3682. Оп. 1. Д. 283. Л. 92].

М.Г. Худяков первым в российской историографии постарался полно и объективно охарактеризовать историю Казанского ханства, что входило в противоречие с традиционными оценками татарской государственности. Он постарался объяснить читателям, что татары являются цивилизованной нацией с богатой и древней историей, а Казанское ханство выступало в качестве независимого государства с высоким экономическим, военным, культурным и духовным уровнем развития.

«Русских историков история Казанского ханства интересовала лишь как материал для изучения продвижения русского племени на восток, – пишет М.Г. Худяков. – При этом надо отметить, что они преимущественно уделяли внимание последнему моменту борьбы – завоевания края, в особенности – победоносной осаде Казани, но оставили почти без внимания те постепенные стадии, которые проходил процесс поглощения одного государства другим». [Худяков: 1990. С. 11].

Безусловно, «Очерки по истории Казанского ханства» – главный труд М. Г. Худякова, книга его жизни. Выйдя в 1923 г. в Казани тиражом всего 1000 экз., эта книга в последующие 70 лет не имела переиздания после расстрела Михаила Худякова в 1936 г. как «врага народа». Только после перестройки, в 1990-е гг., книга «Очерки по истории Казанского ханства» М. Г. Худякова была переиздана в Казани и Москве, а его честное имя вновь вернулось народу.

Михаил Георгиевич Худяков, как представитель Народного комиссариата по делам национальностей, уделял большое внимание и проблемам других народов, проживавших в ТАССР. Деятельность М. Худякова по сохранению исторического культурного наследия в Татарской республике можно отследить по самым разнообразным документам, сохранившимся в архивохранилищах Казани. Так, 23 октября 1919 г., он обращается в Казанский подотдел по делам музеев и охране памятников искусства и старины с просьбой прислать в Свияжск своего представителя для присутствия при акте вскрытия и освидетельствования раки с мощами Святителя Гермогена, «дабы иметь возможность предотвратить повреждение реликвий, имеющих не только религиозное, но и историческое значение» [НА РТ. Ф.Р. 271. Оп. 1. Д. 48. Л. 113; Шарангина: 2004. С. 408–409].

До 1920 г. он выполнял разовые поручения Музейного подотдела, но с августа того же года, когда во главе отдела стал Б. Ф. Адлер, М. Г. Худяков становится активным участником работы по сохранению памятников истории и культуры Музейной комиссии при Академическом Центре Наркомпроса ТАССР. В 1924 г. он исполнял обязанности секретаря комиссии. В этом качестве Худяков выполнял не только административные функции, ему был также поручен ответственный участок деятельности – охрана археологических памятников.

Так, большую заботу проявил М. Г. Худяков по спасению объектов Казанского женского Богородицкого монастыря: под охрану был взяты парадные комнаты и вестибюль игуменских покоев со всей обстановкой, имеющей художественную и историческую ценность. М. Г. Худяков поднимал также вопрос о принятии на учет памятников прикладного искусства Казанского женского монастыря и о необходимости устройства для их хранения специального музея. На заседании Музейной комиссии в декабре 1924 г. он выступил с сообщением о состоявшейся передаче копии знамени, бывшего при русском войске во время взятия Казани в 1552 г., из Спасской часовни в Центральный музей республики [НА РТ. Ф.Р. 3682. Оп. 1. Д. 710. Л. 71–75].

Следует отметить, что помимо активной работы М. Г. Худякова в деятельности научных обществ и организаций, при его непосредственном

участии в 1923 г. была предпринята попытка создания исследовательского института по татароведению для руководства «охраной и исследованием татарской старины». В начале 1923 г. Всероссийская научная Ассоциация востоковедения предложила создать в Казани Комиссию по изучению татарской культуры. В мае того же года предполагалось проведение совещания «по вопросам изучения татарской культуры» [Абдрашитова: 1975. Вып. 150. Сб. 77. С. 101–102]. В марте 1923 г. решение о создании Института было принято на совещании при Академцентре [НА РТ. Ф Р. 3682. Оп. 1. Д. 488. Л. 6].

Институт должен был стать специальным научно-исследовательским учреждением для археологического исследования Татарстана, также охраны археологических памятников республики путем создания археологических заповедников. Первоочередной задачей института было создание археологической карты республики. Для организации института была выбрана организационная комиссия в составе Г. Максудова, Г. Губайдуллина. Г. Шарафа, А. Рахима, Н.И. Воробьева, М.Г. Худякова, Н.И. Фирсова. О дальнейшей судьбе этого учреждения сведений нет.

Особо необходимо выделить постановку вопроса о составлении археологической карты предполагаемых заповедных мест республики. Все расходы принимал на себя Академцентр. Отрадным видится тот факт, что эта карта по заданию Общества татароведения была составлена М.Г. Худяковым. К сожалению, она осталась неизданной и поиски ее текста остаются до сих пор безрезультатными [Деятельность общества татароведения: 1925. № 1–2. С. 57–58]. Им же для НОТ был подготовлен план археологических работ в районе Казанского кремля, также не осуществленных из-за недостатка средств [Фаттахова: 2000. С. 146].

В творческом наследии М.Г. Худякова существенное место занимают работы по вопросам археологии края. Значительный вклад внесен им в археологическое изучение региона, систематизацию и обобщение полученных материалов, разработку теоретико-методологических принципов развития археологической науки, осмысление места и роли археологии в системе гуманитарных знаний. Несмотря на ярко выраженный классовый подход к рассмотрению важнейших проблем развития науки, основанной на принципах марксистской методологии, критическое отношение к наследию русской дореволюционной археологии, М.Г. Худяков смог одним из первых ученых-археологов изложить цельный взгляд на историю российской археологии, обобщить теоритические и методологические основы этой науки [Мельникова: 2004. С. 133.]. Опираясь на эти исторические данные, твердо можно сказать, что Михаил

Георгиевич Худяков являлся одним из основоположников археологической школы ТАССР.

Иными словами, к середине 1920-х гг. общественная и научная деятельность М. Г. Худякова приобретает масштабный и разноплановый характер. Однако, разгром правительства К. Мухтарова, репрессии против М. Султан-Галиева и его соратников, общая удушающая атмосфера набирающего силу тоталитарного режима не оставляли места и для творческого простора тем ученым, которые ставили своей целью духовное и культурное возрождение татарского народа. Идеологические конфликты Худякова со старой профессурой Казани тоже дали о себе знать.

В итоге, в феврале 1925 г. М. Г. Худяков переезжает в Ленинград, устраивается научным сотрудником Публичной библиотеки. В 1926–1929 гг. он учится и заканчивает аспирантуру Государственной Академии Истории Материальной Культуры (ГАИМК). М. Г. Худяков, в качестве аспиранта, участвует в археологических экспедициях и продолжает поддерживать связь с Татарстаном. В 1929 г. Худяков получает разрешение проводить раскопки в Волжско-Камском регионе, в Елабужском кантоне Татарской республики и самой Казани. С декабря 1929 г. по февраль 1933 г. М. Г. Худяков являлся ученым сотрудником Института по изучению народов СССР при АН СССР (ИПИН). Одновременно, с марта 1931 г. М. Г. Худяков – научный сотрудник 1 разряда ГАИМК по сектору Доклассового общества, с 1933 г. – по сектору Феодального общества.

В середине 1930-х г. имя Михаила Георгиевича Худякова стоит в одном ряду с известными востоковедами и тюркологами страны, его приглашают в Москву читать лекции, он начинает писать учебники, готовит большие рукописные работы к печати. Он также часто бывает в Казани не только с научными экспедициями, но и лекциями и докладами на тему татарской истории и культуры. Большую ценность для понимания воззрений М. Г. Худякова на развитие комплексных исторических исследований в Поволжском регионе представляет доклад, с которым он выступил на расширенном заседании дирекции Татарского научно-исследовательского экономического института 23 июля 1930 г. Ученый был приглашен на открытие Института в качестве представителя Ленинградского Института по изучению народов СССР.

Доклад М. Г. Худякова по существу представляет собой развернутую программу деятельности этого Института. Так, Худяков поставил вопрос о необходимости организации дела по переводу национальной литературы на русский язык. Он указал на тот факт, что никем не поднимается вопрос о ее переводе на русский язык, в то время как многие заняты переводом

русских писателей на национальные языки. В отношении языка Худяков говорит следующее: «На территории Татреспублики можно развернуть чрезвычайно интересную и актуальную работу, в частности, по изучению классовых языков. Здесь важно и интересно изучить роль татарского языка торговли. Мы встречаемся с таким явлением, когда вотяки, марийцы и русские говорят на татарском языке. С другой стороны, должна быть изучена классовая роль русского языка. Она является достаточно крупной и заслуживает специального изучения» [Доклад: 1930. С. 42–47].

В то же время ученый поставил задачу правильного отображения национальностей в русской художественной литературе. Он говорил: «Известно, насколько неправильное представление давали даже лучшие писатели о народах СССР. Например, в произведениях, посвященных народам Кавказа, получилось уродливое изображение кавказских народностей (…) Критически проработать эти вопросы было бы чрезвычайно полезно». Далее Михаил Худяков высказал пожелание относительно изучения антропологических особенностей народов и предложил совместную разработку с институтом по изучению народов (ИПИН) в Ленинграде. Худяков считал чрезвычайно важным исследование социальной заболеваемости в географических пунктах, где находятся места слияния больших рек, например, в Камском Устье и др., в связи с их социально-экономическим профилем. М.Г. Худяков призывает изучить воздействие больших индустриальных центров на окружающую среду и уже в те годы подчеркивает влияние экономики на быт. В результате эта проблема была включена в план ИПИН (Ленинград).

Худяков поставил также вопрос об изучении промыслов народов Среднего Поволжья, в первую очередь промыслов, связанных с химической обработкой дерева, главным образом по линии Марийской и Вятской областей и Чувашской республики. А по отношению к Татреспублике важным стало исследование промыслов, связанных с обработкой шерсти, «валяльным» производством, изготовление войлока и т. д. Он хорошо знал возможности Татарстана и способности татарского народа, его традиционные ремесла и предлагал делать ставку на них. Михаил Худяков был разносторонним человеком, но принципы гуманизма, изучение истории, религии и культуры местных народов он ставил на первое место. Его волновала наступающая гибель различных религиозных культов, религиозного быта. «Изучение отживающих форм важно с чисто научной точки зрения, поскольку они раскрывают перед нами древнейшие идеологические явления», – с такими словами выступал Худяков перед казанцами. И это в тридцатые годы, в атеистическом государстве, где религия была объявлена врагом прогресса и «опиумом для народа»!




Ученый доказывал и необходимость создания фундаментальных трудов по истории отдельных народностей края. Худяков говорил о малочисленности научной литературы, в особенности монографий: «Издание популярной литературы – больной вопрос. Если мы имеем кое-что для квалифицированного читателя, то популярной этнографической литературы мы не имеем совершенно и в издании ее очень нуждаемся». Приведя в пример наличие монографий по Татарской и Башкирской республикам, он поставил вопрос «о необходимости монографий и по финским народностям». Одновременно М.Г.Худяков выдвинул проблему разработки «общеволжской культуры» в целом с охватом элементов материальной и социальной культуры [Там же]. Следует указать, что выступление М.Г.Худякова получило высокую оценку в прениях по докладу, в частности – Николая Воробьева, Фатиха Мухамедьярова, Михаила Корбута и других ученых [Гарипова: 2004. С.449].

Как мы видим, и в Ленинграде Михаил Худяков жил проблемами Татарстана и татарского народа, он никогда не прерывал связи со своей духовной родиной – с Казанью… В Ленинграде он написал свои фундаментальные научные труды по истории татарского народа, такие как «Татарская Казань в рисунках XVI столетия», 1930; «Казань в XV–XVI столетиях. Писцовые книги города Казани. 1565–63 гг. и 1646 г.», 1932; «Археология в приволжских автономных областях и республиках за 15 лет», 1933; «Дореволюционная русская археология на службе эксплуататорских классов», 1933; «Древнее Поволжье (до V в. н.э.) и Средневековое Поволжье (после V в. н.э.)», 1936 г. и др. И в 1935 г. профессор

ГАИМК С.Н. Быковский с гордостью отмечал: «По своей совокупности научная деятельность М.Г. Худякова по истории доклассовых обществ Волго-Камья выдвигает его на первое место среди специалистов по археологии и отчасти по этнографии народов Волго-Камья в СССР» [РА ИИМК РАН. Ф. 2. Оп. 1. Д. 716. 45 л.].

Принимая во внимание научную деятельность, активность, высокую оценку работ М.Г. Худякова, Академия предлагает дать ученому степень доктора исторических наук. И в феврале 1936 г. подписывается протокол под номером 2131, в котором М.Г. Худякову присуждается степень доктора исторических наук без защиты диссертации. Однако радость от заслуженного успеха была заслонена набирающей ход компанией по поиску «врагов народа» в академических научных учреждениях. Под безжалостный каток политических репрессий попали ведущие ученые Академии наук, в том числе, и Михаил Георгиевич Худяков, которого арестовали 9 сентября 1936 г. Ведущие ученые страны С.Н. Быковский, Ф.В. Кипарисов, В.С. Адрианов, М.Г. Худяков были обвинены в организации «антисоветской троцкистко-зиновьевской организации…боевой террористической группы…». Уже 19 декабря 1936 г. состоялось заседание Военной коллегии Верховного Суда СССР, которое приговорило всех четверых по ст. 58–8 и 58–11 УК РСФСР к высшей мере наказания – расстрелу, с конфискацией имущества. В тот же день приговор был приведен в исполнение. 27 июня 1957 г. та же Военная коллегия Верховного Суда СССР реабилитировала всех четверых расстрелянных ученых…

Возвращение имени замечательного русского ученого – М.Г. Худякова, историка, этнографа, человека, внесшего неоценимый вклад в правдивое, непредвзятое освещение истории татар и Татарстана – популяризация его творческого наследия, должна стать справедливым шагом в признании выдающихся заслуг этого неутомимого исследователя истории и культуры народов Волжско-Камского края. В 2020 г. Татарстан будет праздновать 100-летний юбилей образования ТАССР. Как мы видим, в истоках становления гуманитарной науки в Татарстане, в особенности, в изучении истории татарского народа, археологии и этнографии стоял и Михаил Георгиевич Худяков. И его имя должно быть вписано в историю нового Татарстана золотыми буквами, как имя Русского летописца Татарской истории.

## Литература

1. Абдрашитова И.М. Из истории Научного Общества Татароведения (1923–1929 гг.) // Ученые записки Казанского педагогического ин-

ститута. Казань: КГПИ, 1975. Вып. 150. Вопросы историографии и источниковедения. – Сб. 77.
2. Байрамова Ф. А. Забытый сын народов Поволжья// Вечерняя Казань. 1990. –20 ноября.
3. Байрамова Ф. А. Михаил Худяков и история татарского народа. Казань, 2003.
4. Байрамова Ф. А. Михаил Худяков и историко-культурное наследие народов Среднего Поволжья. Казань, 2007.
5. Бороздин И. Н. К предстоящему съезду по изучению Волжско-Камского края // Жизнь национальностей. 1924. Кн. 1 (6).
6. Гарипова З. Г. К вопросу о творчестве Худякова Михаила Георгиевича // Проблемы истории Казани: современный взгляд. Казань, Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2004.
7. Гришкина М. В. М. Г. Худяков – историк Волго-Камского края // Материалы краеведческих чтений, посвященных 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М. Г. Худякова. Казань, 2004.
8. Деятельность общества татароведения (1923–1925 гг.) // ВНОТ. 1925. № 1–2.
9. Михаил Худяков. Казань, 2011.
10. Кузьминых С. В. Казанские годы в жизненным и творческом пути М. Г. Худякова // Материалы краеведческих чтений, посвященных 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М. Г. Худякова. Казань, 2004.
11. Кузьминых С. В., Старостин П. Н. Ленинградские годы в жизненном и творческом пути М. Г. Худякова // Санкт-Петербург и отечественная археология. Историографические очерки. СПб, 1995.
12. Мельникова О. М. М. Г. Худяков как историк науки // Материалы краеведческих чтений, посвященных 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М. Г. Худякова. Казань, 2004
13. Султанбеков Б. Ф. Расстрелян как террорист (По страницам следственного дела историка Михаила Худякова) // Гасырлар авазы=Эхо веков. 2002. № 1–2.
14. Усманов М. А. Главный труд Михаила Худякова // Татарстан. 1994. № 9–10.
15. Фаттахова Г. А. Деятельность Академического центра Татнаркомпроса в 1920-е г.: Дисс. на соиск. учен. степ. к.и.н. Казань, 2000.
16. Худяков М. Г. Очерки по истории Казанского ханства. Казань, 1923.

17. Худяков М.Г. 1000-летие мусульманской культуры в Поволжье // Вестник просвещения. 1922. № 1–2.
18. Худяков М. О необходимости переводов татарской литературы // Вестник просвещения. 1922. № 1/2.
19. Худяков М. Деревянное зодчество казанских татар // КМВ. 1924. № 1.
20. Худяков М. Татарское искусство // Вестник знания. 1926. № 2.
21. Худяков М. Татарская Казань в рисунках XVI столетия // Вестник научного общества татароведения. Казань, 1930. № 9/10.
22. Худяков М. Великодержавный шовинизм в русской этнографии (Образовательная б-ка ГИМК. № 11) // Этнография на службе у классового врага: сб. критич. ст. Л., 1932. С. 22 –100.
23. Худяков М. Казань в XV–XVI столетиях // Материалы по истории Татарской АССР. Писцовые книги города Казани 1565–1568 гг. и 1646 г. Л., 1932.
24. Худяков М. «Древнее Поволжье (до V в. н.э.)»; «Средневековое Поволжье (после V в. н.э.)». Д. 1696. 98 лл. Хранится в рукописном архиве ИИМК РАН в фонде ГАИМК (г. Ленинград). Ф. 2. Оп. 2. № 1696. 1936.
25. Худяков М. Доклад представителя Института по изучению народов СССР (ИПИН, Ленинград) на расширенном заседании дирекции Татарского научно-исследовательского экономического института 23 июля 1930. Казань, б.г.
26. Шарангина Н.А. Документы Национального архива РТ об историке, археологе, этнографе М.Г. Худякове // Материалы краеведческих чтений, посвященных 135-летию Общества естествоиспытателей при КГУ, 110-летию со дня рождения М.Г. Худякова. Казань, 2004.
27. Государственный архив Кировской области: Ф. 170 – Вятская ученая архивная комиссия.
28. Малмыжский краеведческий музей: Фонд М.Г. Худякова.
29. Национальный архив Республики Татарстан (НА РТ). Ф.Р. 225 – Восточная академия.
30. Национальный архив Республики Татарстан (НА РТ). Ф. 977 – Казанский университет.
31. Национальный музей РТ. Рукописный фонд
32. Отдел рукописей и редких книг Российской национальной библиотеки (Санкт-Петербург): Ф. 828. «М.Г. Худяков».
33. Рукописный архив Института истории материальной культуры РАН (Санкт-Петербург): Ф. 2. Государственная академия истории материальной культуры.

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

## ӘСТЕРХАН ТАТАРЛАРЫНДА ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ СӘНГАТЬ ТӨРЕ – ХУШАВАЗЛАР

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплекслы экспедиция материаллары арасында хушаваз текстлары шактый очрый. 2013-нче елда Институттан бер төркем галим һәм аспирантлар Әстерхан өлкәсе Идел буе районында татарлар яши торган *Киләче* (Килинчи), *Җәмәле* (Три Протока), *Ярлы Түбә* (Осыпный Бугор), *Кызан* (Татарская Башмаковка), *Мәйле Күл* (Яксатово), *Каргалык* (Карагали) һәм Нариман районындагы *Каңга* (Кучергановка) авылларында комплекслы фәнни экспедициядә булдылар. Әлеге экспедиция вакытында телче һәм фольклорчы галимнәр Әстерхан татарларында киң таралган хушавазларга зур игътибар бирделәр, үзләрен нугай татарлары дип атаучы информантлардан хушаваз текстларын яздырып алып һәм аларны беренчел эшкәртеп, кайберләрен фәнни җыентыкта бастырып чыгаруга да ирештеләр [Милли-мәдәни мирасыбыз: Әстерхан татарлары: 2017].

Әстерхан өлкәсе татар авылларында яшәүче халыктан 1998–2000-нче елларда Казан дәүләт консерваториясе тарафыннан оештырылган экспедиция вакытында да ноталары белән бик күп хушавазлар язып алынган. Әстерхан шәһәренә һәм Әстерхан өлкәсенең Идел буе, Нариман, Началов, Володар, Краснояр һәм Хәрәбәле районнары авылларына оештырылган экспедициядә барлыгы 16 авыл тикшерелгән. Болар – Хәрәбәле районында *Лапас*; Краснояр районында *Яшен-Суккан*, *Сәетләр* (Сеитовка), Растопуловка; Володар районында *Кундрау* (Тулугановка), Началов районында *Мойлегүл* (Яксатово); Идел буе районында *Киләче* (Килинчи), *Җәмәле* (Три Протока), *Кызан* (Татарская Башмаковка); Нариман районында *Сүләнкә* (Солянка), *Картузан* (Курченко), *Төлкетөбә* (Туркменка), *Яңа Аскәр* (Янго-Аскер), *Кәменни* (Линейное), *Иске* һәм *Яңа Кучерган* авыллары. Хушаваз һәм башка лирик җыр текстларын, ноталарын, аудиоязмаларын туплаган зур җыентык 2007 елда басылып та чыкты [Памятники татарского народного музыкально-поэтического творчества: 2007].

Әлеге һәм башка экспедицияләрдә Әстерхан татарларыннан язып алынган хушаваз текстлары, кәгазьгә төшерелгәннән соң, жанры билгеләнеп, фәнни әйләнешкә кертелә бара, «Милли-мәдәни хәзинәләребез. Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә Г. Ибраһимов исемендәге ТӘТИ тарафыннан чыгарылып килә торган коллектив монографиядә һ.б. фәнни һәм фәнни-популяр басмаларда апробация уза, текстларның

әле генә табылганнары моңа кадәр билгелеләре белән чагыштырылып, фольклор үрнәкләре буларак анализлана, хушавазның информанттан язып алынган текстлары исә төрле чыганакларда дөнья күреп, татар дөньясына кире кайтарыла.

Нәрсә соң ул хушаваз? Милли-музыкаль традициябезнең гаять бай эчтәлеккә ия кызыклы бу күренеше Идел буе татарларында онытылып бара, ә «хушаваз» төшенчәсе үзе кулланылудан бөтенләй үк төшеп калган дияргә мөмкин. Ә менә Әстерхан татарлары милли-мәдәни мирасында халык сәнгатенең бу төре әле дә актив.

«Хушаваз» сүзе «яхшы сүз», «күңелгә охшардай җыру», «яңгыравы тансык аваз» мәгънәләрендә XIV йөздә иҗат иткән төрки шагыйрь Котб иҗатында ук күзгә чалына, лиро-эпик фольклорга якынлыгы белән игътибарны җәлеп итә:

Шаһ андин сорды кем: «Ушбу хуш аваз

Ни аваз? Ача тип мәңа раз.

Бу хуш аваз белә җанымны алда...» [Источники: 1981. С. 130–131].

Моннан тыш Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр шигъриятендә [Мөхәммәдьяр. URL: http://kitap.net.ru/muhammadiar.php], татар халык дастаны «Таһир белән Зөһрә»дә [Таһир белән Зөһрә: 1984. 217 б.] һ.б. «хушаваз» гыйбарәсенә юлыгабыз. Болар барысы да хушавазларның Урта гасырларда үсеш алган, классик шигърияттә һәм халык иҗатының җыр жанрында популяр шигъри-музыкаль әсәр булуын дәлилли.

Татар халкының җыр мирасы – төсле бизәкләрдән тукылган моңлы, шигъри бер дөнья. Җырның хискә, мәгънәгә бай нәфис сүзләре һәм гамьгә, дәрткә бай тылсымлы музыкасы халкыбызның рухи бөтенлеген һәм тиңдәшсез талант иясе булуын раслый. Җыр хәзинәсендә чал тарих авазлары да, бүгенге көннәр аһәңе дә тирән булып уелган. Жанр үзенчәлеген шигъри хәзинә буларак тикшергәндә татар традицион җыр мирасын дүрт төркемгә бүлеп карыйлар: йола җырлары, уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик җырлар. Соңгы төркем үзе икегә бүлеп өйрәнелә: лирик озын җырлар, лирик кыска җырлар [Миңнуллин: 2003. 60–61 б.]. Хушавазлар исә – лирик озын җырлар төркемендә үзенчәлекле бер төрне тәшкил итә торган, фольклористикада әлегәчә махсус игътибардан читтә кала килгән иҗат.

Сүз сәнгате буларак хушавазлар – чичәннәр иҗаты белән бәйле жанр. Хушавазларны махсус көйгә салып җырлыйлар. Халык үзе аны җыр дип тә, хушаваз дип тә, хушаваз җыры, хушаваз белән җырлана торган җыр дип тә атый. Лирик һәм лиро-эпик характердагы әлеге әсәрләр – халык авыз иҗатының соңгы елларгача саклана килгән, телдә актив үрнәкләре.

Хушавазлар – җыр жанрының һәм этник музыкаль традицияләрнең үзенчәлеге, бу жанрга караган үрнәкләр татарларның бай һәм күптөрле

музыкаль фольклоры турында тулырак һәм җентекле күзаллау тудыра. Хушаваз жанрына музыкаль әсәр буларак игътибар юнәлтеп, Г.М. Макаров мондый фикер белдергән иде: «Бу төшенчәнең татар халкы традицион мәдәниятендә ике мәгънәдә кулланылуы билгеле. Беренчесендә ул Әстерхан төбәге татарларының шигъри-вокаль сәнгатендә жанр буларак мәгълүм; икенчесендә Урта гасыр шигъриятендә кулланылган махсус атама буларак билгеле» [Макаров: 2011. 17 б.]. Үзенең китабында галим «хушаваз» төшенчәсенең татар музыка белеменә М.Н. Нигъмәтҗанов хезмәтләре аша кергән булуы турында яза. «Хушавазлар, – ди ул, – автор язганча, бәетләр тематикасы кебек үк, шактый киң колачлы һәм гади көнкүрештә булганнардан алып, зур тарихи вакыйгаларны тасвирларга сәләтле. Кайбер хушавазларны башкару вакыты берничә сәгатькә сузылырга мөмкин» [Макаров: 2011. 17 б.].

Халык музыкасы белгечләренең татар халык иҗатында хушаваз жанрын танулары –кирәкле һәм мөһим гамәл. Әлеге хаклы фикергә [Макаров: 2011. 19–20 бб.] кушылып, шуны искәртик: фольклор текстлары буларак хушавазлар аз чагылган, тикшеренүчеләр тарафыннан хушаваз атамасы белән теркәлмәгән булса да, халыкта бу төшенчә үз функцияләрен үти һәм яши бирә. Хушавазларның халык иҗатында хосусиятен өйрәнү, барлыкка килгән сорауларга җавап эзләүне дәвам итү – фольклор белгечләре алдында торган актуаль мәсьәлә.

Халык шигыренә нигезләнгән мондый жанрның шактый тармаклы булып, архаик чорлардан ук фольклорда киң кулланылган булуы мәгълүм. Халык иҗатында бер үк авазны яисә сүзне кат-кат кабатлаган аллитерацион шигырьнең әллә ничә төре, һәр юлда иҗекләр саны төрле булып та, сүзләр саны тигез китерелгән сүз буын шигыре (слово-стопа), сан-иҗек, халык шигыренең такмаза шәкеленә нигезләнгәне һ.б.ны куллану тезмә текст булдыру чарасы булган һәм язмачылыкка күчкәнче гаять популяр саналган. Башкорт, казакъ, үзбәк, әзәрбәйҗан, кыргыз, төрекмән, кырым татарлары, якут, алтай, себер татарлары, хакас, шор һ.б. төрки халыклар, бурят, төрки булмаган кайбер башка халыкларда, мәҗлесләрдә оста җыручылар чыгыш ясый торган булган. Сүз осталары, халык шигыре стиленә таянып, бер сөйләгәнен кабат кабатламыйча, җыр башкарулары белән дан тотканнар [Жирмунский: 1958. С. 33].

Көньяк Себер һәм көньяк халыкларының күпчелегендә бу традиция әле бүгенге көндә дә югалмаган, әмма кайчандыр ритуал-мифологик контекстка ия мондый җырларның төрле шартлар йогынтысында идея-структур үзгәрешләрне бик нык кичергәнлеген дә онытырга ярамый. Бүгенге көнгә килеп җиткән хушавазларның да борынгылык белән тирән бәйләнеш тотулары шик уятмый. «Тере» фольклорның музыкаль башка-

рылу, чичән-импровизатор чыгышы һәм аның сүзләрен тыңлап торучы аудитория синтезыннан гыйбарәт тулы канлы мондый төре утрак тормышны үз иткәнгә кадәр күчмә тормыш шартларында озаграк яшәгән, җир эшкәртеп яшәүгә чагыштырмача соңрак килгән, шәһәр мәдәнияте һәм язма әдәбиятка ихтыяҗы да бераз соң формалашкан халыкларда һәм этник төркемнәрдә стабильрәк сакланган. Хушаваз иҗатының Әстерхан татарларында еш очравы – нугай, казакълар белән тыгыз аралашу тәэсире булырга мөмкин. Хушавазларны көйләп әйтү, гадәттә, думбырага кушылып башкарылган.

Татар халык иҗаты буенча милли фольклор томнарын төзегәндә халкыбызда моңа кадәр табылган хушаваз текстларын исәпкә алу – басмаларның академик дәрәҗәсен тәэмин итүдәге бер адым буларак кабул ителергә тиеш. Шушы вәзгыятьне исәпкә алып, бүгенге көндә төзелә торган «Татар халык иҗаты» 25 томлыгының «Халык җырлары» томнарына хушавазларны аерым бүлек итеп кертү планлаштырыла. Хушаваз җырларының зур күпчелеге Әстерхан татарларыннан язып алынган. Томнарга сайлап алынган материаллар Әстерхан ягында яшәүче татарларның *кариле* (*йорт*) һәм *карагаш* исемле төп төркемнәренең (борынгы кабиләләренең) традицион мәдәниятенә бәйле, шулай ук алар арасында таралган башка төркемнәргә дә хас хушаваз үрнәкләрен үз эченә ала. Әйтик, Әстерхан өлкәсе Хәрәбәле районы Лапас авылында Измайлов Айвадулла Ногман улыннан (1931 елгы) язып алынган «*Әй, китәбез утырып*» дигән исем белән мәгълүм хушаваз түбәндәгечә яңгырый:

Әй, китәбез утырып,
Авылның юлы түтәлдәй,
Сыркырай, сез, Кәримҗан,
Аяк-кулдан үтә ләй.
Җидесе дә җиңелдән,
Җилкәнем бавы сигездән,
Аман барып, сау кайтмак,
Таудай олы диңгездән.
Хайваным, туры атым,
Төскә[1] карап барадыр.
Шушы утырган күп халык,
Җырла, дип мине калдырды,
Җырла, дип миннәт[2] салган соң,
Әйтми тагы булмады.
Уртага төшеп җырласам,
Ярыладыр маңгаем,
Чыгармын кабат тагы,
Яшерен көлеп калмамын,
Шушындый җыен-мәйданда
Алдыңызда чыгармын.
Кадер белгән агалар
Хәл-әхвәлне сорады,
Сораган соң хәл җыйдым,
Әйтми тагы булмады;
Чакырту белән без килдек,
Күтәриек җыелып [Милли-мәдәни мирасыбыз: 2017. 275 – 277 бб.].

1 Төс – урман

2 Миннәт – рәхмәт, рөхсәт.

«Татар халык иҗаты. Җырлар» академик томнарының бүгенге көндә төзелеп бетү этабында тора торган томына материал туплау эшендә экспедицияләр вакытында һәм гомумән Әстерхан татарлары белән аралашып, алар авызыннан язып алынган яисә татарларның, шул исәптән, Әстерхан өлкәсе татарларының традицион музыкасына багышланган башка басмаларда [Азиатский: 1897; Машков: 1901; Нигъмәтҗанов: 1976; Нигмедзянов, 1982; Арсланов: 1992] очрый торган хушаваз үрнәкләре киң файдаланыла.

Хушавазларның иң зур күпчелеге Әстерхан татарларында сакланып калу, чыннан да, бик кызыклы. Билгеле булганча, Әстерхан өлкәсе татарлары Идел елгасының түбән агымында урнашкан Әстерхан шәһәрендә һәм аның тирә-ягындагы районнарда аерым авыллар булып көн итәләр. Әстерхан татарларының этник төзелеше бер төрле генә булмыйча, алар төрле төрки телле этник төркемнәр җыелмасын тәшкил итә. Ул җыелма Әстерхан шәһәре һәм Әстерхан өлкәсенең урта гасырлар заманыннан ук яшәүләрен дәвам иткән нугай татарлары, шулай ук Урта Идел, Кама, Урал төбәкләреннән күчеп утырган татарларның этник төркем вәкилләреннән тора. Нугай татарлары, үз чиратында, тел, территориаль, көнкүреш-хуҗалык үзенчәлекләре буенча аерылып торган берничә төркемгә бүленә: кариле нугайлары[3] һәм карагашлардан башка, татарларның кундырау, алабугат һ.б. төркемчекләренә аерыла. Моннан тыш Урта Иделдән күчкән татарлар мишәр һәм урта диалект вәкилләренә бүленәләр. Бу үзенчәлекләр аларның җыр-музыка иҗатларында чагылмый калмаган.

Әстерхан татарларының күп кырлы этник төзелмәле булулары аларның музыкаль-шигъри традицияләренең дә бер генә төрле түгел, күп компонентлы булуына китерә. Әстерхан өлкәсе территориясендә яшәүче һәр төрки-татар этник төркемнәрнең үзенә хас традицион жанр комплексы бар. Әмма алар аерым үсеш алмаган: өлкәдәге тарихи һәм этник процесслар күрше төркиләр белән мәдәни контактларга керү нәтиҗәсендә төрле музыкаль-шигъри катламнарның үзара тәэсир итешүләренә китергән. Әстерхан татарлары өчен бу процесс индивидуаль төсмер алган һәм аларның традицион җыр-көй һәм инструменталь жанр формаларына хас аерым үзенчәлекләр хасил булган. Алар иҗатында хушаваз белән җырлана торган лирик иҗатның аеруча популярлыгы да шуны раслый.

Әстерхан татарлары җырларында әдәби телдән морфологик һәм лексик характердагы тайпылышлар еш очрый. Кайбер хушавазларда җырны әйтүченең сүзләре табышмакны хәтерләтә, хушавазларда бүгенге көн укучысы өчен аңлашылмаслык урыннар да очрап куя. Хәтта сүз ни турында бара дигән сорауга һәрвакыт җавап табылмаска да мөмкин, әмма

3 Кариле (юрт) татарларының нугай булулары икеле(редакцион искәрмә).

җырчы хушавазны ахыргача башкарып чыга. Мондый текстлар әдәби әсәр закончалыкларына һәм нормаларына сыешып бетә алмый. Теле, фикер сөреше җәһәтеннән хушавазларның кайберләрен аңлауда кыенлык тууны жанрның борынгылыгы, татар теленең төрле этник төркемнәрендә тел байлыгының гаять күп төрлелеге һәм нугай теле тәэсире белән аңлатырга мөмкин. Әстерхан хушавазлары, төрки шигъри эпоска хас булганча, речетатив белән башкарыла, ә мондый төр этник музыканың әзерлексез аудитория өчен күп очракта җиңел аңлаешлы жанр булмавы табигый.

Әстерханда яшәүче милләттәшләребездән тыш, хушавазлар татарлар яши торган башка төбәкләрдә дә очрап куя. Төмән өлкәсе, Омск өлкәсендә яшәүче татарларда, Удмуртия республикасында, шулай ук Татарстан авылларында да җырны хушаваз белән башкаруга игътибар итәбез. Шунысы кызыклы: тикшерү-өйрәнү барышында төрле төбәкләрдә язып алынган хушавазларның вариантлылыгы ачыклана. Әйтик, «*Яттым я алла...*», «*Салават*», «*Үгет-нәсихәт*», «*Аятелкөрси*» «*Моңнар*», «*Вакыт җиткәч, чаралар юк*» кебек ядкарьләр Әстерхан татарларыннан язып алынган хушавазлар рухын хәтерләтә, аларның көе үзенчәлекле булырга мөмкин, әмма текст нигездә кабатлана, башка төбәктә язып алынган хушавазның вариантын тәшкил итә. Шунысы да бар: Татарстан авылларында башкарылган хушавазларның күбесе мөнәҗәт жанры белән җыр жанры чигендә тора торган иҗат, аларның тематикасы дин һәм әхлак тәрбиясе, шушы өлкәгә карый торган үгет-нәсихәт белән чикләнә, информант аны «хушаваз» дип башкармый, «мөнәҗәт» әйтәм дип тәкъдим итә. Әстерхан татарларында «*Әйт дисәгез, мин әйтәм*» кебек гыйбарәләрне казан татарлары тәэсирен кичергән төбәкләрдә «*Укы дисәгез, укырмын*» гыйбарәсе алыштыра. Бу – тел-авыз иҗатының язмага күчүе, язма фольклор формалашу белән бәйле күренеш. Хушавазны информант кәгазьгә теркәп куйган булырга да мөмкин.

Әстерхан татарлары башкаруында язып алынган хушавазларны әдәби сүз сәнгате буларак кына түгел, аның көе, башкарылу үзенчәлекләре белән бергә кабул итү һәм җыр сәнгатенең үзенчәлекле төре дип бәяләү мөһим. Күләме белән шактый озын хушавазлар бар. Әйтик, «*Җиңүләр булды бер талай...*», «*Һич бу бер ялган дөньяда...*», «*Авырлык төште ил-йортка*», «*Советка чыгарылган җыр*» кебек хушавазларда чичәннең хис-кичерешләре белдерелү, ягъни лирика белән белән беррәттән, эпиклыкка да урын табылган. Боларны тарихи җыр характерындагы хушавазлар дип тә билгеләргә мөмкин булыр иде, чыннан да, шактый күләмле тезмәләрдә чынбарлык вакыйгалары да телгә алынган, шул чор рухы чагылыш тапкан. Әйтик, «*Ай бер хикәят сөйлимен*» исемле хушавазны мисалга китерик:

Ай бер хикәят сөйлимен,
Хушавазга салып,
Бер хикәят сөйлимен,
Хушавазга салып.
Кырык бердә сугыш булды,
Халыкны җыеп алып.
Ниндидер гаҗәп бу бер эш,
Җөмһүрият хәйран калып.
Хәйран азаматлар,
Эчтәгеп канга манып,
Күп кыенлык аткардык,
Сугышта арып-талып.
Янган утка без кердек,
Дошманга каршы барып,
Снаряд, гранаттан,
Мылтыктан утлар ярып.
Озак йөреп сугышта,
Михнәт күргән үрмәләп,
Алда сөйләрмен, җәмәгать,
Тыңлагыз колак салып,
Алда сөйләрмен, җәмәгать,
Тыңлагыз колак салып.
Мондый сугыш күрмәдек,
Туып-үсеп анадан,
Мондый сугыш күрмәдек,
Туып-үсеп анадан.
Җирдәге гаскәрләргә
Яуды күктән кара кан,
Бу гамәлгә түзәрме
Бу дөньяда, сора, җан?
Килгән самолетлар да
Белмәссең, әллә кайдан,
Җирдән, күктән я судан
Ашыкты кичеп мәйдан.
Алда сөйләрмен, ага-дус,
Булды сугыш бу җайдан,
Алда сөйләрмен, ага-дус,
Булды сугыш бу җайдан.
Агабызның күңеле ябык,
Серен җыр белән әйтә алмый,
Агабызның күңеле ябык,
Серен җыр белән әйтә алмый.
Армашта[4] күп азамат
Үз иленә кайта алмый,
Кул-аяктан аерылып,
Ыңгырашып ята алмый,
Ни ашаган ашлары
Йөрәгенә бата алмый.
Көл булып янганнар да бар,
Исемен янә әйтә алмый,
Вафат булганнар да күп,
Илдән тәгам татый алмый.
Калганнары исән-аман кайтсын,
Бу гамәлгә чыдамый.
Әйтешеп бу агагыз,
Исенә төшсә ята алмас,
Теләш[5] дигән агагыз
Исенә төшсә ята алмас.
Туктатам (сөйләүне) сугыш хәлен,
Арнап[6] дусларга сәлам,
Туктатам сугыш хәлен,
Арнап дусларга сәлам.
Мин дә сезнең юлыгызда
Бүген дә күңел алам.
Тагы да кайтыр көн булыр,
Язылса Шәриф каләм[7];
Ай, бу көннәр башымда,
Хәсрәт утында янам.
Әйтергә сүз булыр иде,
Җитәр диеп җайланам.

---

4 Армаш – топонимик атама.

5 Теләш – хушаваз үйтүченең исеме.

6 Арнап – багышлап.

7 Шәриф кәлам – Коръән.

Кызыл телем җирексен[8],
Сөйләр диеп даянам[9].
Шатлыклы туйлар булсын,
Җир йөзе, бөтен галәм.

Ай, кыскача шуның белән
Күргәнем булды тәмам,
Кыскача шуның белән
Күргәнем булды тәмам [Милли-мәдәни мирасыбыз: 2017. 115–117 бб.].

Күргәнебезчә, биредә чичән, тарихи эпик фольклорга хас булганча, нейтраль позициядә калмый, җырда хушаваз башкаручының лирик кичерешләрен тасвирлау өстенлек ала. Тарихилыкка да дәгъва итә торган мондый хушавазларда текстны башкаручы теге я бу вакыйгага мөнәсәбәттә үз бәясен белдерә. «Белгәнемне сөйләдем», «Гыйбрәт алыгыз яхшыдан», «Төшенеп, колак салыгыз» кебек гыйбарәләр белән тыңлаучы аудиторияне үз фикеренә колак салырга, аныңча эшләргә өнди, теләкләр тели. Тагын бер хушаваз текстын мисалга китерү әлеге жанрның шигъри үзенчәлекләрен ачыграк күзалларга ярдәм итәр:

Әйт, дигән соң әйтермен,
Әйтерем – тыңларың булганда,
Асылдан туган тулпарым,
Чыгармын ярып кайдан да.
Бу җырларны искә алып,
Билгеле сүзләр калдырган;
Тыңлаучың – бу яшьләр, абайла,
Сезгә дә барып тимәсен
Атаңның әйткән сүзләре,
Ай, әйтмичә йөрмәсен.
Тимерченең гадәте –
Суктырып, тимер суздырган,
Иреләнеп, җырчылар
Бер-береннән уздырган.
Ай, җырламый да утырдың,
Җыр биштәрен калдырган.
Шундагы кызлар яулыгын
Ак битенә түшәде;
Гаепкә алма, тыңлаучы,
Атагыз җырлап күрсәтте.

Шул утырган агаең
Хан-солтан булырга лаек;
Кунак кына булсам да,
Кайбереңне сыныймын.
Кушып ла күңелемнән,
Шул бер-ике авыз җырлармын.
Бәрәкәт суы билдән дә,
Кичүен тапсаң, тездән дә.
Без сезләрдән котылдык,
Инде сүзләр сездән дә.
Әссәламүгаләйкүм,
Кальян тарткан картлар ла,
Кужатай белән Кундырау[10],
Башкалары тагын бар;
Әйтермен җырда булганын,
Барысын барлап утырам.
Ахтуба[11] суы буена
Чыгып ла үскән тирәк тә;
Әйтер сүзләр бар иде,
Бер кадәр белсәң кирәк тә.... [Памятники: 2007. С. 68–73].

8 Җирексен – ял итсен.

9 Даянам – өметләнәм.

10 Кужатай белән Кундырау – Әстерхан өлкәсендәге авыл исемнәре.

11 Ахтуба – Актүбә.

*«Ырусия – безнең ил...»*, *«Мин әйтсәм, кем тыңлар соң?»* кебек хушавазларда, мәсәлән, чичәннең колхозны мактавы, совет властена дан җырлавы кебек, бүгенге көн укучысы өчен артык төче тоелган яисә искергән карашларны гәүдәләндергән аһәңнәр дә яңгырый. Яисә «*Ай, уникенче апрель...*» дип башланып киткән алты куплетлы озын җыр совет чорында космоска чыккан космонавтларга багышлана, шушы вакыйгалардан илһамланып, аларны җырга салган чичән-җыручының иҗатыннан гыйбарәт. Хәлбуки, болары да – халкыбыз мирасы, үз чоры өчен характерлы идеологияне чагылдыра, бүгенге көндә актуаль түгел дигән сылтау белән Әстерхан татарларыннан язып алынган мондый әсәрләрне сәхифәдән сызып ату хаклы булмас иде. Күптән үткән вакыйгалардан алып, хушавазларда хәзерге көн вакыйгалары да чагылырга мөмкин. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышы, фаҗигале үлем һ.б. вакыйгалар турындагы хушавазлар бар. Әстерхан татарларыннан язып алынган хушавазларның тематикасы шактый киң, алар арасында халыкның килеп чыгышыннан алып, СССР төзелү һәм совет җәмгыяте үсеше, Бөек Ватан сугышы, беренче совет космонавтларының галәмгә очышы хакында бәян итә торганнарына кадәр очрый.

Татарларның традицион культурасында хушаваз һәм җыр, бигрәк тә мөнәҗәт дип башкарыла торган иҗат бер-берсенә якын яңгыраш алган – алар бер үк этник мохиттә, охшаш иҗтимагый-гамәли максатта еш кына бер үк башкаручының репертуарына керәләр. Хушавазны, гадәттә, олы яшьтәге ир-ат туган-тумачалар җыелганда яисә авылдагы бәйрәм тантаналарында тыңлаучылар өчен башкаралар. Музыка белгечләре хушаваз көйләренең музыкаль стиль нисбәтеннән аз аерылуларын, ягъни аерым-аерым хикәяләнә торган шигъри текстларның бер үк көйгә башкарылырга мөмкин булуын ассызыклыйлар [Памятники: 2007. С. 4]. Интонацион яктан хушавазларга декламацияләү, көйләмле иҗекләрнең (слогораспевларның) бик аз булуы, түбән төшмәле хәрәкәт, миноргa авышлы диатоник ладларга таяну (эолий, локрий, дорий, фригий һ.б.), иҗек-ритмлы изосиллабизм, тирада принцибындагы композицион шәкелләндерү күренешләре хас.

Әстерхан татарлары башкара торган хушавазлар җыр жанрында шигъри текстларның эчтәлеге, композицион төзелешенең үзенчәлекле булулары белән аерылып торалар. Хушавазларның сюжет эчтәлеге башкаручыларның үз тормышлары тәҗрибәләренә нигезләнә яисә ата-бабалар васыятьләре итеп, үгет-нәсихәт шәкелләрендә шигъри әйтелмәләр белән баетылып бирелә. Мәсәлән:

Ай, тыңлагыз, җәмәгать,
Сөйләсен ага белгәнен;

Чын күңелдән уйланып,
Бәян итеп күргәнен

Корылган җыен туй булса,
Сүз күңелгә терелгән;
Туй җыелган уртада,
Ачылып урын бирелгән.

Агалар сәлам биргәндә
Мин җыр белән керәмен,
Сүз кадерен белгәнгә
Җыр белән җавап бирәмен. [Милли-мәдәни мирасыбыз: 2017. 177б.].

Кагыйдә буларак, аларда берәр мәҗлеснең (гадәттә туй йоласы) ничек узуы хакында сүз алып барыла, җырчы-импровизатор башкаруында олыларның дидактик киңәшләре бирелә, үз этник төркеме, халкы һәм туганягы турында сөйләнелә. Хушавазларны хикәяләү фабуласыз була, тематик блоклар теземе барышында аларның һәркайсы үз эчендә сюжеты һәм мәгънә бәйләнеше булмаган хәлдә башкарыла, аларның сан ягы да чикләнелмәгән. Бу яклап хушавазлар һәрвакыт нинди дә булса бер сюжет белән бәян ителә һәм эзлекле бер темага багышлана торган җырлардан аерылып тора, ә эпос жанрына якыная төшәләр. Әстерхан татарлары эпик традициясендәге хушаваз термины казакъ милли культурасындагы жыр мәгънәсенә якын. Татар халык җыры кысаларында исә хушавазлар лирик җырларның үзенчәлекле бер төрен тәшкил итәләр.

Әсерхан татарларында хушавазлар башкаруның бүгенге көндә дә очравы – халкыбызның җыр жанрын һәм гомумән милли-мәдәни үзенчәлеклелеген баета торган күренеш. Җыручы башкаруындагы хушавазлар – халык мәдәниятенең кадерле ядкаре. Аларны сүз сәнгате, музыкаль башкарылышы, тематикасы, шулай ук тыңлаучыга тәэсире җәһәтеннән махсус өйрәнү һәм татарлар арасында таныту көн кадагындагы мәсьәлә булып кала.

**Әдәбият**


1. Азиатский музыкальный журнал, издаваемый И.Добровольским. Астрахань, 1816–1917гг. // Рыбаков С. Музыка и песни уральских мусульман с очерком их быта. СПб., 1897.
2. АрслановЛ.Ш. Язык карагашей-ногайцев Красноярского и Харабалинского районов Астраханской области (Грамматический очерк. Тексты и переводы. Словарь). Набережные Челны, 1992. 160с.
3. ЖирмунскийВ.М. Некоторые итоги изучения героического эпоса народов Средней Азии // Вопросы изучения эпоса народов СССР. М.: Изд-во АН СССР,1958.
4. Источники древнетюркской и татарской литературы. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1981. 248с.
5. МакаровГ.М. Дәрвишләрнең сөхбәтендә: бәетләр һәм мөнәҗәтләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 159б.

6. Машков В. А. Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края // Известия общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. Т. 12. Вып. 1. Казань, 1985; Т. 14. Вып. 3. Казань, 1897; Т. 17. Вып. 1. Казань, 1901.
7. Милли-мәдәни мирасыбыз: Әстерхан татарлары. Фәнни экспедицияләребез сәхифәсеннән. Казан: Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2017. 420 б.
8. Миңнуллин К. М. Һәр чорның үз җыры. Казан: Мәгариф, 2003. 400 с.
9. Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан. Нуры содур / URL: http://kitap.net.ru/muhammadiar.php (мөрәҗәгать ителде: 4.05.2019).
10. Нигмедзянов М. К Народные песни волжских татар. М.: Советский композитор, 1982. 135 с.
11. Нигъмәтҗанов М. Н. Татар халык җырлары. Казан: Татар. кит. нәшр, 1976. 216 б.
12. Памятники татарского народного музыкально-поэтического творчества. Вып. 1. Песни Астраханских татар. Әстерхан татарлары җырлары. Сост. и нот. транскр. Е. М. Смирновой и Н. Г. Гайнуллиной. Казань: Казанская консерватория, 2007. 550 с.
13. Таһир белән Зөһрә // Татар халык иҗаты. Дастаннар. Төз. Ф. В. Әхмәтова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

# Фәнни-популяр язмаларда төбәк тарихы

# Краеведение в научно-популярных публикациях

*С. А. Хусаинов*

## РАЗМЫШЛЕНИЯ НАД ЯРЛЫКОМ САХИП-ГИРЕЯ

***Аннотация:*** *В этой статье изложен опыт определения потомков обладателей ярлыка Казанского хана Сахип-Гирея. Автор приводит несколько интересных, недавно опубликованных архивных документов, привязывая их к персонам, указанным в данном ярлыке. Предпринято определение территориального расселения потомков обладателей ярлыка, выявляя их миграционный путь. Проведен анализ нескольких групп – претендентов на то, чтобы быть потомками обладателей ярлыка. Статья может являться началом для более глубокого анализа и исследования тарханного ярлыка Сахип-Гирея.*

***Ключевые слова:*** *тарханный ярлык, земельные споры, ясачные татары, Казанский и Уфимский уезды, Икские волости.*

Тарханный ярлык Сахип-Гирея, правившего в 1521–24 гг. в Казанском ханстве, уже проанализирован историками. Еще до обнаружения оригинала в 1880 гг. о его содержании было известно уфимскому городскому голове Д. С. Волкову. Сам же оригинал ярлыка был обнаружен в 1912 г. археографом С. Г. Вахидовым в д. Мамалаево (Сабинский район Татарстана).

Ярлык является подтвердительным и выдан 2 января 1523 г. семерым личностям («…Шейх-Ахмед сын Мухаммеда, и сын Шейх-Ахмеда Абдал, младший брат Сейид-Ахмеда Махмутек, его сын Муса, сын Сейида Якуб, его младший брат Буланс, его [же] младший брат Нур-Сейид…»), которым ранее был выдан подобный ханский тарханный ярлык прежними правителями об освобождении их от повинностей и оберегании их «земли и владения».

С. Г. Вахидов обнаруженный тарханный ярлык опубликовал в 1925 г. с переводом на русский язык. После этого ярлык изучали, корректировали, публиковали несколько историков. Наиболее полный перевод и анализ выполнил Ш. Ф. Мухамедьяров. Глубокое и всестороннее изучение с учетом обнаруженных в 1950–60-х гг. новых документов, касающихся

ярлыка, выполнил И.А.Мустакимов [Мөстәкыймов: 2003.]. В частности, предположение автора о прочтении имени одного из названных выше представителей как Буляк вместо прежнего Буланс, дает возможность изучения других исторических документов в контексте с ярлыком. Автор также обнаружил в 14-й строке ярлыка внесенную позднее другими чернилами запись и предложил его прочтение как «[по реке] Ик».

Ш.Ф.Мухамедьяровым было обнаружено и опубликовано в 1987г. спорное дело между татарами д.Мушуги Акешкой Доскеевым с товарищи и Ирektинскими башкирами Каракусюком Аканаевым на земли по р.Ик [Muhamedyarov, Vasary: 1987]. Как следует из опубликованного в статье Ш.Ф.Мухамедьярова и И.Вашари документа, ярлык Сахип-Гирея в подтверждение своих прав на спорные земельные владения представили «Уфимского уезда Казанские дороги деревни Мушуги ясашные татары Акешка Доскеев с товарищи». Но оказалось, что спор относительно земель по р.Ик с иректинскими башкирами начался ранее, в 1678г. Уфимским стольником и воеводой Венедиктом Хитровым выносились два противоположных решения. Право на земли оспаривались «чувашем» деревни Тураево Казанской дороги Уфимского уезда Чувашаком Тураевым с товарищи и представителем иректинцев Каракуска Аканаевым [РГАДА. Ф.1173. Оп.1. Ед.хр. 766. Л.2–3.]. Первое решение было вынесено в пользу тураевцев в результате сыска, но второе решение уже вынесено в пользу иректинцев по формальным признакам – «для того башкирскими вотчинами чюваше для ссор владеть не велено». Как видим, тут уже не согласившись с этим решением, в спор вступили Уфимского уезда Казанской дороги д.Мушуги ясашные татары Акешка (Аккош) Доскеев и его племянник (или сын? Акеш-Юкаш) Мурзакай Юкачев с товарищи. Они утверждали, что «в прошлых де годах даны дедам и отцам их и им вотчины бортной ухожей по Ику реке по обе стороны рыбные ловли с ыстоки и с озеры и со всякими звериными ловлями». В границах вотчины объявлялись речки Мазярь, Мушуга с левым притоком Атрякли, Мелля. А сама деревня, судя по ландкартам Красильникова 1755г., находилась на устье р.Мушуга при слиянии с речкой Ик. Видимо, Акешка с товарищи, чувствуя недостаточность имеющихся у них документальных подтверждений на свои земли, стали разыскивать более старые данные, так как предпочтение при спорных делах отдавались таковым. Первый, предоставленный суду документ, убедивший суд закрепить спорные земли за Акешкой с товарищи, и оказался тарханным ярлыком Сахип-Гирея. Акеш Доскеев утверждал, что указанные в этом ярлыке персоны являлись его предками, а его дед, Доскей Беляков, владел этой грамотой. Переводчики посольского приказа Девлет абыз, Кучюкай Сакаев перевели тарханную

грамоту так: «Абхазы Сахипгарей хан велел быть в тарханех Шихахмеду Мохаммедову сыну да Абдалу Шихахмедову сыну да ево брату Балашу да его брату Нурсеиту да Саетахмедову брату Мухоммадова сына Дасякова, Муся Сеедова сына, всего семи человеком. И до животов их и до земель дела нет. Писано то письмо 929 года» [по хиджре]. При тщательном исследовании оригинала ярлыка И. А. Мустакимов обнаружил в 14 строке позднюю дописку, который мог, в его прочтении, означать принадлежность документа к «землям по Ику». То есть Акешка с товарищи могли пойти на подделку ярлыка для более убедительного доказательства своего права на земли по р. Ик. Второй, предоставленный в суд со стороны мушугинцев документ, был за 785 г. (скорее всего, 185/1677 г.), по сути, не имеющей отношения к делу, а только указывающий на принадлежность к их родственникам и товарищам земель по р. Каме в районе нынешнего села Бетки Тукаевского района Татарстана (что важно в выявлении связи ярлыка с землями по обе стороны Камы) и по обе стороны р. Ик.

Мишәр мулла Рангазарга килгәч авыл халкы аңа да җир бирми яки аны авылның җир фондына кушмый. Шуңа карамастан үзе игенче гаиләсеннән чыккан кеше буларак, җирнең кадерен белергә чакыра, халыкны җир сатудан тыя. Һәр җомга намазында халыкка эшләргә, җирләрне ятларга сатмаска, иген чәчү, мал асрау, сәүдә итү хәләл дип вәгазьләр сөйли. Мәчеткә килмәгәннәрне махсус мәчеткә чакыртып яман гадәтләрен ташлауларын үтенә, үгетли. Ходаның каһәре, җәһәннәм уты белән куркыта. Ошбу нәсихәтләрдән акылга утыручылар да була.

Талип мулла Рангазар халкыннан җир сатып алып өч басуда күп итеп иген игүгә керешә. Игенчелекне алып бару өчен ат-арба, бик күп яхшы эш кораллары кирәк. Әле бу таләпләрне үтәргә кулда бераз акча булуы да шарт. Ул Яхшыбай Мусинга барып, кечкенә процент түләү шарты белән бер меӊ сум көтәргә акча ала да Чистай өязендәге Мораса авылы танышларыннан кустар ысулда ясалган тимер сабаннарын бик күпләп кайтара башлый. Чөнки Минзәлә, Чаллы, Бөгелмә тирәләреедә яшәүче татар-башкорт игенчеләре тимер сабанның нәрсә икәнен дә белмиләр. Бөтен кыр эшлрен агач сука белән башкаралар. Талип мулла бу тимер сабаннарны ничек көйләргә, ничек эшләтергә икәнен үзе өйрәтеп күрсәтә. Шулай итеп Рангазар халкы тимер сабанга күчә. Мондый сабан кулланылган җирләрдә чүп үләне югалып игеннәр икеләтә уңыш бирә. Сабанга да «мишәр сабаны» дип исем кушалар. Бу сабаннар эшләнеше ягыннан бик әйбәт булмасалар да, агач сукага караганда эш җиңеләя. Игенчелектән шактый табыш керә башлгач авыл халкы яңа агач өйләр кора, яхшы туклана һәм киенә башлый. Халык бу үзгәрешләрне Талип мулладан күрә. «Мишәр мулланың аягы җиңел булды», – дип бу икътисади җанлануга үз мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Ул гына да түгел, авылда шырпы дигән нәрсә байлар кулында гына була, әле анысы да бик тупас эшләнгән. Халык көндәлек кирәк булган утны үзенең мичендә, учагында саклый. Нәкъ шуның аркасында, бигрәк тә салам түбәле йортларда янгыннар чыга, хуҗалык корылмалары көлгә әйләнә. Талип Чистай ягыннан күп итеп шырпы китертеп сата. Бу зур яңалык була. Халык шырпыдан файдаланырга өйрәнә, янгыннар да кими төшә. Аннан соң авыл халкының йөз проценты чабата кия. Чабата ясап кияр өчен якын тирәдә урман юк, күре, юкә агчлары бик сирәк үсә. Яңа Әлмәт базарында бу товарлар тулып ята, яз айларында бәясе дә арзан. Әлмәт Рангазардан 45

чакырымнар ераклыкта, ул якка беркем дә йөрми. Сәүдәгәр монысына да өлгерә. Аның өйдә булуы булмавы хуҗалыкка тәэсир итми, барысына да абыстай чаба. Сыерларны үзе сава, сарык бәрәннәренең йонын үзе кисә, ашау эчү хәзерли. Абыстай хисаплау эшенә дә зиһенле, хуҗалыктагы бөтен сәүдә исәп-хисабын ул алып бара. Ике арадагы мәхәббәт тә ныгый. Үзе мулла, сәүдәгәр, игенче һәм укытучы булган мишәр мулла бик тиз баеп ындырлары – кибәнгә, буралары – ашлыкка тула, ишекалдында, лапасларда төрле товарлар шыплап тулган, хәтта эшчеләр ялларга туры килә. Аның мәчеттән кайтканын унлаган урыс, татар крәстияннары сабан алырга яки башка йомыш белән көтеп тора. Хәзер ул тарантаска яхшы атлар гына җигеп йөри.

1905 еллардан соң «мишәр сабаннары» урынына Германиядән килгән, заводта яхшы җитештерелгән яңа калыптагы сабаннар тарала. Мораса сабаннары сатылмыйча Талип мулланың ишек алдында өелеп кала. Ул кәефен төшерми, сәүдәсен киңәйтү өчен Карамалы, Сарман, Нөркәй, Языков базарларында тимер-томыр, чалгы, пычак, йозак ише товарлар белән сәүдә итүче Борһан хаҗи Айдашев белән танышып, килешеп, яңа чыккан сыйфатлы «московский» сабаннар белән сәүдә итәргә тотыналар. Зур табыш та килә, моңа халык та шатланып бетә алмый. Күпчелек игенчеләрнең тормышы күзгә күренеп яхшыра, алар ике-өч ат тоталар, байлар өч-дүрт сабан белән иген игә, ярлылар ике кеше сабандаш булып эшлиләр. Кайберләре җирләрен сатып Донбасс шахталарына, Урал завод-фабрикаларына китеп бара. Рангазарның тигез, кара туфраклы җирләрендә, киң басуларында кул көче җитмәстән эшләнми, чәчелми, «калдау» булып яткан чирәмнәр ачыла, бәхетләренә каршы игеннәр дә уңыш бирә. Сугылмаган ашлык каралты арасына сыймастан авыл халкы яңа ындырлар ясыйлар. Бу елларда авылның «аргы ындыры»на куелган кибәннәр, эскертләр курганнарны хәтерләтә. Рангазарда беренче мәртәбә бәрән тиресеннән тышлап тегелгән толыпны мишәр мулла тектерә. Ул чалбар һәм кара йоннан басылган киез итек кия. Аңардан күреп башкалар да шулай киенә башлый. Шул елларда ул урам башка икенче өй кордыра, мунча, лапасларны башкадан ясата.

## КЕНӘЗ НУРЕТДИН

Тиз арада абруе күтәрелгән мишәр мулланы икенче мәхәлләдә яратып кабул итәләр. Ләкин беренче мәхәллә кешеләре эчендә аның дәрәҗәсе үсүенә, байлыгының киңәюенә көнчеләр барлыкка килә. Талип Зәйни мулла сөйләгәннәрдән чыгып авылда үзен ничек тотарга икәнен яхшы белә. Халыкның вак-төяк эшләренә аралашмый, урамга чыгып йөрми, үзен бераз читтәрәк тота. Бу исә аны төрле имеш-мимешләрдән саклый. Абыстайның ачык күңелле, юмарт һәм кунакчыл булуы да мәхәллә хал-

кына ошый. Муллага ачуы килгән кешеләр аны ничек тә каралтып күрсәтергә җаен эзлиләр. Түбән оч мәхәлләсендә яшәүче «кенәз» кушаматлы Нуретдиннең бер ак сарыгы көтүдән кайтмый кала. Инде көз килә, әмма сарык табылмый. Кемнәрдер юри коткы таратып ул сарыкны мишәр мулла абзарында күргәннәр икән, дигән хәбәр чыгара. Кенәз Нуретдин килеп мулла белән сөйләшү яки абзардагы сарыкларны карарга рөхсәт сорау урынына, урам буйлап «мулла минем сарыкларны үзенә алып кереп бирми йөри», «мулла кеше сарыклары керсә, чыгармый» дигән сүзләр таратып кеше ышандырырга тырыша. Талип мулла бу сүзләрне ишеткәч бик нык гарьләнә. Сарык, кәҗә урлау, иген басуында бер көлтә яки печән, урман урлау башкортлар өчен гади нәрсә булса да үзен саф мөселман дип йөргән дин әһеленең вөҗданы бу сүзләрне күтәрә алмый. Шулай вөҗданы кыйналып торган көннәрнең берсендә күрше Шаһвәли карт белән кенәз Нуретдин мулланың ишек алдына килеп керәләр.

– Әссәләмәгаләйкум хәзрәт!

– Вәгаләйкумәссаләм...!

– Менә Нуретдин әйтә, аның ак сарыгы сезнең сарыклар белән ияреп кереп, көтүдән кайтмастан калган икән? Шуны күреп чыгу өчен мине дә җитәкләп килде, – дип башын кашып куя Шаһвәли.

– Безгә чит сарыклар кергәне юк, Нуретдин! – дип аптырап җавап бирә мулла.

– Безнең ак сарык, сезнең сарыклар белән аралашып кергән, ул хәзер дә сезнең абзарыгызда ди, күзен дә йоммыйча Нуретдин.

– Мин абзарда чит мал тотмыйм, шулай ук кеше сарыгы да күргәнем юк.

– Мин үзем кичә генә килеп карап киттем. Безнең ак сарык сездә хәзрәт!

– Ярар хуш, алай булгач, әйдә күрсәт, кайсы сарык сезнеке икән? – дип, алар бергәләп абзарга керәләр.

– Әнә юан койрыклы ак сарык, минеке! – дип кычкыра Нуретдин.

– Ярый алай булгач, тот син аны, ди мулла тыныч кына. Нуретдин абзар буйлап сарыкларны куып үзе күрсәткән сарыкны тотып килә.

– Тамгасын кара әле Нуретдин!

– Менә тамгасы да безнеке, уң колагында астан ике уйган.

– Нуретдин хата кылма, тамгасын яхшырак карагыз, Шаһвәли абзый син дә караш әле... Нуретдин белән Шаһвәли карт сарыкның колагын тикшерәләр, бармаклары белән капшап карыйлар.

– Тамга яңа салынганмы, әллә иске – яшь вакытта салынганмы, ди мулла.

– Әйе иске тамга, яшь вакытта салынган, диешәләр тегеләр.

– Шул сарык синекемени Нуретдин?

– Әйе хәзрәт, бу сарык минеке.

– Тамгасын яхшы карадыңмы?

– Әйе дим бит, менә уң колагы астан ике уйган!

– Башка тамгасы юкмы, сул колагын яхшы карадыңмы? Нуретдин белән Шаһвәли карт сарыкның сул колагына күз салалар, сул колакның астынна бер кисем күрәләр.

– Тамгасы бармы, юкмы? дип җитдиләнеп сорый мулла. Нуретдин аптырап кала, ни әйтергә дә белми.

– Шаһвәли абзый! Син бу сарыкны тотып тор, ә син Нуретдин, бар тагын бер сарык тотып кил. Нуретдин беренче кулга эләккән сарыкны тотып килә.

– Кая Нуретдин тамгасын кара әле, ничек икән? Нуретдин хәйран кала, бу сарыкның да тамгасы ак сарык тамгасына охшый.

– Нуретдин бар әнә теге сарыкны да тоып кил, ди Талип мулла. Нуретдин тагын бер ак сарыкны тотып килә, тикшерсәләр, ул сарыкның да тамгасы әвәлгеләренә охшаган.

– Йә Нуретдин, бу сарыкларның һәммәсе синекеме?

– Хата бездә икән хәзрәт. Тәксир, гафу итәсез дип, Нуретдин каушап куркып кала.

– Шул вакыт үзен көчкә тотып торган мулла җан ачуы чыгып атларга башак болгатып бирә торган карлау белән ккнәз Нуретдиннең җилкәсенә бик каты итеп берне төшерә. Бу сугудан кеняәз егылып китә, мулла аңа тагын берничәне өсти.

– Берәүне угыры иткәнче үзеңне тикшереп күр, ахмак. Мин синең сарыгыңа мохтаҗмени, җәһәннәм азыгы. Мин ходаның каһәреннән курыкмыйммени? Минем абруема кара табы төшерергә сине кем өйрәтте?

Кенәз Нуретдин урыныннан көчкә торып абзардан чыгып китә. Үзендә гаеп булгач, һичкемгә гарыз кылып йөрми.

## БҮКӘЙ ГАЙФУЛЛА

Рангазар башкортларының эчендә бик юаш, әдәпле, тәртипле һәм диндар акыллы кешеләр күп булса, шулар арасында дөньяның астына ут куеп, кабәһәтлектән кайтмый торган, тупас холыклы, хәттә кеше үтерүдән дә тайчынмый торганнары да бар. Ат, кәҗә-сарык угырылары, амбар басучылар һәр елда бер-ике мәртәбә ишетелә. Авылда Фәйзулла балалары, Шәрифулланыкылар, Сахалин Төхфи, Бүкәй Гайфулла, качкын Зарип кебекләр иң начар, усаллардан санала.

Бигрәк тә көз айларында халык үзеннән арткан ашлыкны, аяклы малны, ит-майны, йон-тирене сатып, сугым суеп кунак чакыра, кунакка бара, кыз бирә, килен ала яки улын өйләндерә. Рангазар халкының ашап эчүе гади булса да, булганы белән кунак итәргә ярата. Бер җирле яман гадәтләре дә бар. Кунакны сиздерми генә ачы бал белән сыйлап аны аяктан еккаенча эчертү. Шуның аркасында кызып дошман булган кешегә барып

сугышу яки бер кавем икенче кавемгә каршы бер сәбәп табып кырылып беткәнче күсәк, пычак кебек нәрсәләрдер тотып оршышу. Дөрес, авылда эчмәгән, яхшы тәрбияле гааиләлр аз түгел. Алар сугышып эчеп йөрүне яратмыйлар, бу гадәтне зур гөнаһ дип саныйлар. Кайбер гаиләләр кардәш кавеме аз булганга күрә усал кешеләр белән бәйләнешмәстән, аларың ихтыярларына буйсынып канунсыз таләпләрен үтәргә мәҗбүр. Шуларның берсе беренче мәхәлләнеке Бүкәй Гайфулла («бүкәй» усал, куркыныч дигән мәгънәдә) олы юл буенда яши. Ул симез туры алашасын кабыклы йөк арбасына җигеп Рангазардан сигез чакырымдагы Александровка базарына баргалый. Ит-май, арыш сатканнан соң кабакка кереп лыкынганчы аракы эчә. Ул вакытта аракының бутылкасы 40 тиен. Башы-күзе әйләнеп, аякта тора алмый башлагач арбасына чыгып ята да, атын кыйный-кыйный Рангазарга чаба. Авыл урамына килеп кергәч дөньяда булмаган пычрак сүзләр кычкырып, кемнәрнедер сүгеп, акырып, бертуктаусыз чыбыркы белән атына кизәнеп түбән очка таба менә. Бүкәй Гайфулланың шулай исереп базардан кайтканын авылдагы берничә инсафлы бай хуҗалыклар ит пешереп, өстәлгә бер чирек аракыны куеп, капканы ачып көтеп алмасалар, ул атын туктатып, хуҗаларга кереп аларны куркыта, сугышып чыга, ут төртеп яндырам дип сүгә. Әнә шул рәвешле биш-алты хуҗалык аның кыланмышларына түзеп яши. Раббани белән Сирай хаҗилар, Хәбибулла кебек байлар аның бу гадәтенә инде күптән өйрәнгән. Бүкәй кайбер муллаларны да үзенә буйсындырып, аларны да аракы алып, бер табак сарык итен пешереп, өстәлгә куярга мәҗбүр итеп үзенең кагыйдәсен үтәткән. Авылга килгән яшь мулла баеп китсә дә Бүкәй Гайфуллага бер мәртәбә дә аракы коеп биргәне юк. Моның өчен аның теше сызлап ачуы килеп, эче пошып йөри. Моны ничек итеп акылга утыртырга дип уйлый Бүкәй.

Салкын көзге көннәрнең берсендә халык иртүк Карамалы базарына ашыга. Базарга баручылар кайсы атлы-арбалы икешәр, өчәр кеше утырып бара, кайсылары арбасына йөк төягән, кайберләре салмак кына җәяү атлыйлар, сөйләшкән авазлары еракларга барып ишетелеп тора. Талиптан өч-дүрт өй аркылы гына яшәгән күршесе Сираҗетдин ямаулы чикмәненең өстеннән билен киндер бау белән бәйләп аңа шешә асып куйган, җилкәсендә бер төен бара, анда күкәйләр булса кирәк. Сирай карт күкәйләрне сатып, ярты бутылка керосин алырга сигез чакырымдагы базарга җәяү бара. Һәркемнең үз кайгысы.

Талип мулла да атын җигеп базарга кузгала. Көзге яңгырлардан соң тигезләнеп бетмәгән юллардан баручы йөкле арбаларны узып киткәннән соң ул җилкәсенә 4–5 кием чабата күтәргән, үзе беркадәр бөкерәя төшкән, су буендагы тыкырык эчендә яшәүче Афзал картны куып җитә. Кычкырып биргән сәламга Афзал көчкә башын борып кына сәлам ала.

Мулла янында утырган улын үз итәгенә ала да, Афзал бабайны арбага утырта, тегесе моңа балалар кебек сөенә.

Талип базарда ат тугарып тормый, аны иркенерәк бер урында агачка бәйләп куеп, улын ияртеп базарга кереп югала. Борһан хаҗи Айдашевка сабаннар сатыша. Атна буе сатылган сабаннарның хакын ала да шуның белән базарда эше бетә. Бер зур калачны сатып алып брезент сумкасына салып куя. Күкерәк кесәсеннән көмеш сәгатен алып карый. Әйе, шактый вакыт узган, авылга өйлә намазына кайтып җитәргә кирәк дип ашыгып юлга чыга. Урыс Карамалы белән Татар Карамалысы арасындагы елга күперен чыккач, Рангазарга китә торган тыкырык белән үргә күтәрелә. Әле бу вакытта базардан кайтучылар ул кадәр күп булмый. Тауны менеп, дилбегәләрне җыебырак тотып алга караса, басу капкасыннан янәшәдә Рангазарның исерек Бүкәй Гайфулласы кабык арбасыннан төшеп, атын туктатып бәвелен агызып басып тора. Мулланың күңелендә шомлы шик туа. Бүкәй оятсыз халәттә арбадагы кешенең мулла икәнен танып ала да үз арбасына утырырга ашыга. Бүкәй арбасына менеп утырганчы мулла кара алашасына каеш чыбыркы белән берне сизелерлек итеп сызганнан соң, кара алаша ыжгырып басу капкасыннан чыгып элдертә. Бүкәй исереклеге белән арба күчәре эләгеп, тәжесе өзелеп тоткарланып кала.

Талип өч чакрымнар чамасы юлны үтеп Баллы сызасына килеп төшкәндә Бүкәй Гайфулла атын кыйный-кыйный чаптырып артыннан килеп җитә. Мулла Баллы сызасындагы көзге баткаклыкларны әкеренерәк үткән чакта ул аның арбасы янына ук чаптырып сазга керә һәм кулындагы чалгы пычагы белән кизәнә, һәр мизгелдә суеп ташларга әзер икәнлеген күрсәтә. Талип мулла да югалып калмый, улы белән үзен саклау хисе көч кертә. Ул елгадан чыккан вакытта чыбыркы белән бер кара алашага, бер Бүкәй Гайфулланың үзенә җибәрә. Алар Хуҗи кулы сызасына кадәр ике чакрым юлны чабышып, сугышып узалар. Бүкәй аны куып җитеп арбасына сикерергә уйлый. Ләкин чыбыркы Бүкәйнең атына янәшә килергә юл бирми. Алар бөтенләй юлсыз җирләрдән куышып Хуҗи кулы сызасына килеп керәләр. Талипның каты орылудан канатлы тарантасының алдагы тимер күчәре сынып, бер тәгәрмәче төшеп кала. Бүкәй исә сызада батып кала. Шул форсаттан файдаланып мишәр мулла өч тәгәрмәч белән атын чаптырып исән-аман авылга килеп кереп ындырлар артыннан өенә кайтып җитә. Күршеләре Габдулла Арсланов, Шакир Мөхәммәтҗановлар бу гаҗәп хәлне күреп чабып керәләр. Бу маҗараның асылына төшенгәннән соң, алар бер ун кеше тупланып, күсәкләр белән коралланып Бүкәйне өенә барып кыйнамакчы булалар. Ләкин Талип мулла эшнең зурга китүен, үтерешләр булуын уйлап моңа рөхсәт бирми, аларны тыя.

Талип мулла мәчеттә өйлә намазын укып кайткач, өс-башларын алыштыра да үз мәхәлләсендәге урыс тимерче Лукъянга барып кистән ясата, аны озын агач сапка куйдырта. Ул бу салкын коралны бервакытта да үзеннән калдырмый. Күпчелек чакларда кистәннең тимер башы тарантасның аркасыннан күренеп, чылбырлары шалтырап шом салып йөри торган була. Шул ук көнне арбасының күчәрен ясатып, янә кара алашаны җигеп, кистәнен арбага салып түбән очтагы юл белән кешегә күренмичә волость үзәге булган Сарманга китә. Минзәлә суы аркылы салынган такта күперне чыккач, беренче зур урам башында, сул почмактагы калай түбәле өйдә яшәүче урядник Николайга барып туктый. Николай урядник Кармыш янындагы Елховой дигән урыс авылыннан килгән (искәрмә: автор ялгыша, Елховойда татар-мишәрләр яши, монда иң якын урыс авылы Дальняя Ивановка бар). Алар якташ буларак танышлар, бер-берсен хөрмәт итәләр. Талип мулла Кармышка киткәндә Николайга әйтмичә китми. Чөнки Николайның карт әнисе Елховойда үз өе, хуҗалыгы белән яши, урядник исә әнисенә һәрвакыт күчтәнәч, акча җибәреп тора, аның чәчә торган җирләре дә Елховойда була. Николай үзе дә чистай якларына киткәндә мишәр муллага әйтмичә юлга чыкмаган. Чәй өстәле янында бүген булган бөтен маҗараны сөйләп бирә. Үзенә эш таба алмый йөргән урядник бик тиз кабынып китә. Сары, калын озын мыеклы, иләмсез зур гәүдәле Николай шинелен киеп, револьверын каешы белән биленә буып, кылычын асып, кулына камчысын ала. Алар икәүләп Рангазарга китәләр.

Авылга кергәч тә Николай арбадан төшеп, сабуллашып, эшнең нәтиҗәсен иртәгә белерсең дип төнге караңгылыкка кереп югала.

Урядник туры тыкырыктан ерак булмаган Гыйльфан сазлыгына салынган күпер төбендәге пожар лапасына барып керә. Анда ат юк, бочкага кулын тыгып карый, су да юк икән. Шырпы сызып карый, монда дежурда һич кем юк бугай. Урядникның тагын ачуы арткannan арта. Тагын шырпы кабызып, лапасны әйләнеп чыга. Ниһаять почмакта калын итеп җәйгән арыш саламы өстендә гырлап йоклап яткан Кенәз Нуретдинне күреп ала. Ул күп уйлап тормастан Нуретдиннең артына калын солдат итеге белән китереп тибә. Нуретдин сискәнеп сикереп тормакчы була, әмма торалмый, исереп йоклаган була. Урядник аның колак төбенә дә менеп төшә. – Кая ат, кая су, кая лампа? дип өстенә акырып тора. – Бар хәзер үк старостаны, десятникны алып кил, моментально килсеннәр. Җаныңны суырып алырмын, дуңгыз, марш бегом!

Кенәз Нуретдин башыннан тәгәрәп төшкән мескен бүреген дә эзләп тормый пожар лапасыннан чыгып йөгерә. Караңгы урамда аның ава-түнә лап-лоп чапкан тавышы гына ишетелеп кала.

Урядник Николай Фәртдин картның яңа өенә урнашкан «мирски дом»га килеп керә. Өй эчендә зур утызлы лампаны кабызалар, бүлмә эче

яктырып китә. Урядник үзенең каршысында ак күлмәктән, ак ыштаннан басып торган озын гәүдәле Кәрамны күрә. – Кая староста, давай старостаны, – дип аңа җикеренә. Кәрам Фәртдинов та старостаны эзләп китә. Озак та үтми күкерәгенә сары чылбырлы ак калай таккан сукыр Гыйсмәт тыны кабып килеп җитә. Ул курка-курка мескен бүреген кулына алып: – Мин сельски староста Гыйсмәтулла Нигъмәтуллин, – дип әйтергә дә өлгерми аны урядник иң әшәке сүзләр белән сүгеп китә: – Син кем? Старостамы, әллә ачыган кәбестәме? Авылда ни карыйсың син. Күперләрең ватык та җимерек, пожар лапасында ат юк, бочкаларда су юк, порядок юк, барыгыз да исерек, авылда бандитизм! Авылыңда бандитларны саклап ятасың, бергә эчәсез. Хөкүмәткә каршы бунт ясыйсыз. Указной муллага юлда һөҗүм ясыйсыз. Кем ул Бүкәй Гайфулла? Хәзер үк табып китерегез миңа ул сволочьны. Булмаса, икегезне бергә бәйләп Себергә озатам. Указной мулланың правасы полковниклар белән бәрабәр... Ул да булмый ишектән Княз Нуретдин, сотский Хәйрулла, десятник Хәмидуллалар килеп керә. – Марш вон! Хәзер үк Гайфулла Фәйзуллины табып китергез, үлеген булса да алып килегез, – дип барысын эзләүгә куа урядник.

Гыйсмәт урам капкасы төбендә десятникларны куып җитә. – Вәт ахмак, безне нинди бәлага салды бит. Базардан кайтканда Талип хәзрәткә пычак белән ташланган, аңа кул сузарга ярыймы соң?

Аларны шактый озак көтеп утырган, төнге йокысы калуыннан газапланганлыгы, урядникның зәһәрлеге битенә чыккан. Авызыннан папиросын өзмәстән арлы-бирле идән буйлап йөри. Менә староста Гыйсмәт ярдәмендә Бүкәй Гайфулланы десятниклар ике култыгыннан тотып урядник алдына китереп бастыралар. Гайфулла аяк үрә тормастан тагын да исереккә сабышып, башын кыйшайтып утыра. – Гайфулла Фәйзуллин синме, көндез нәрсә эшләгәнеңне беләсеңме? – Минават урядник хәзрәтләре, мин карт дурак, күп эчеп куйганмын шул, – дип мыгырдый Бүкәй. Аның көндезге батырлыгының эзе дә калмаган. – Виноват-виноват, теперь сам признаешься сволочь, хәзер синнән допрос алам дип десятникларны, старостаны өйләренә кайтарып җибәрә урядник. Аларның киткәнлеген белү өчен өй алдына чыгып карый да, өйгә кереп ишек келәсен бикләп куя. Гайфулла эшнең нәрсәдә икәнен сизеп бик тиз айный. Урядник бер-ике тапкыр аркасына камчы белән тамызгач ул кычкырып господин урядниктан гафу сорый. – Әйт бандит, кем сиңа Талип мулланы чалгы күтәреп куып йөрергә кушты. Тегесе шайтан котыртты, шайтан дип акланмакчы була. – Кем ул шайтан, исемен әйт, юкса җаныңны җәһәннәмгә җибәрәм, – дип урядник тагын аны камчы белән яра. Бүкәй авыртуга түзми, дөресен әйтеп сала. – Сукма әйтәм, әйтәм! Раббани хаҗи белән Шакирҗан муллалар миңа акча бирделәр. Талип мулланы үтерергә куштылар. Ул мишәр, дин бозучы, әнә

мәктәп салдырып мәктәпкә кара такталар ясатып, шунда кызларны язарга өйрәтәләр. Балаларны урыс итәләр, кяфер ясыйлар. Аны авылдан куарга кирәк. Мишәр дүрт-биш елда баеп китте, күп җирләрне сатып алды, соңырак барыбызның да җирен алып бетерәчәк. Мин шуңа ышанганмын, исерек идем. Гаеп миндә түгел, аларда...

Раббани хаҗи белән Шакирҗан мулла килеп кергәндә Бүкәй Гайфулла идәндә сызланып ах-ух килеп ята. – А нука Гайфулла әйт, аракы алырга кем акча бирде, Талип мулланы пычаклап үтерергә кем кушты? Бүкәй моңарчы сөйләгәннәрен яңадан кабатлый. Урядник протокол яза башлый. Тегеләре без кеше үтерергә бернинди дә әмер биргәнебез юк, – дип урядникка ялваралар, ә үзләре куркып Бүкәйгә һич бер каршылык күрсәтмиләр. Бүкәй Талип муллага кагылмам дип сүз бирә. Аны бер атнадан соң волостька бару шарты белән өенә җибәрәләр. Урядник баштан соңгыларын төрмәгә утырту, Сахалинга кудырту белән каты куркыта. Сездән йөз сум штраф дигәч, хаҗиның йөзләре ачылып китә. Урядник бик зур канәгатьлек белән акчаны кесәсенә салып куя. Инде таң да аткан, лампалар сүндерелеп тынычлык урнаша.

Талип муллага яңа сулыш керә. Хәзер аңа бу төбәктә яшәргә берkем дә комачауламый. Инде ул дошманнарының этлекләреннән шүрләп Себер илендәге Томск шәһәрендәге туганы Гайфулла Гобәйдуллинның чакыруы буенча мулла булып күчеп китү ниятеннән дә кире кайта. Ул Рангазарда ныклап утырып кала.

## ШӘХСИ ҖИР

Рангазар башкортлары эчендә «Казан кешеләре» дигән бер катлам халык яши. Рангазар халкы аларны үзләренә аралаштырмый, алыш-биреш ясамый, иген җирләре дә башкортныкыннан аерым тора. Бу ясашный крәстияннар кайчандыр татар морзаларының крепостной коллары булып, 1861 елда яки аннан алдарак, чукынмаган татарларны җирләреннән куган вакыттамы, аларны Казан ягыннан күчереп китереп, татарлар белән башкортлар арасын бозу өчен Рангазар башкортларының җирләреннән җан башы хисабына үлчәп, землемерлар җир аерып бирәләр. Рангазар елгасының сул ягыннан, авылның югары очыннан бер аерым басу итеп аларга иген җирләре билгеләнә. Үзләренә бирелгән җирнең авылга килеп кушылган почмагына алар кечкенә хутор булып, урамның ике ягына бәләкәй балчык өйләр салалар. Алар 20–25 гаилә булып, бер-икесе генә җитеш тормышта яшәгән. Күбесенең аты да, сыеры да юк. Җан башына тигән җирләрен дә эшкәртеп ризык хәзерли алмыйлар. Шулар арасында абруйлы, атлы-сыерлы, агач өйле Хафизетдин дигән бер карт була. Ул үзенең иптәшләре булган Казан кешеләреннән байтак кына җир сатып ала. Аның угыл балалары булмый, кыз балалары күрше авылларга тормышка чыгып китәләр. Мишәр мулла монда килгәндә карт белән карчык үз җирләрендә эшли алмас булып картайганнарын күрә.

Хафизетдин баштан җирләрен муллага эшләргә биреп тора. Үзара җылы мөнәсәбәтләр урнаша. Хафизетдин картның 30 дисәтинәләп җирен нотариус аркылы хөҗҗәтләрен ясатып, аның үзе исән вакытта ук акчаларын түләп куя. Казан кешеләренең кайберләре шәһәрләргә күчә. Мишәр алардан да җир алып 120 дисәтинә чәчү җиренә ия булып, тагын 7000 сумга чирәм җирләр алып гомерлеккә документлар, җир картасы ясата. Столыпин реформалары аны баетып җибәрә. Мишәр мулла җирләре Казан кешеләре яши торган урамның югары очыннан башланып, Раегазар суы буйлап ике чакрымга сузыла да, аннары югары шималга карап 500 метр бара, аннан уңга борылып туры юл белән авылга кайта. Казан кешеләренең авыл очында «Бабай елгасы» дип аталган сызага кадәр, Рангазар суы буенча 2 чакырым оынлыкта, 10 метр киңлектә куе яшел чирәмлек була. Бу җирләрне халык «мишәр мулла отрубы» дип йөртә.

Бу елларда авылда мишәр мулла Теләнче-Тамак Хәлфиннарга, Нөркәй Гали Зәйнетдиновларга, Алабугадагы Стахеевларга 3000–4000 пот һәртөрле иген сата. Аңа мәхәллә мөселманнарыннан 120–150 арба гошер кергән еллар була.

## ГАИЛӘДӘ МӘДӘНИЯТ

Талип мулла үз заманының үзгәрешләреннән хәбардар кеше була. «Шура», «Кояш», «Йолдыз» кебек газеталарны алдырып укып бара. Китапханәсендә төрле эчтәлектәге китаплар бихисап күп була. Ул мәдрәсәдә балаларны җәдитчә укытуга күчә. Бу дәвердә Һади Максудиның «Савадхан» исмле төрки телдә әлифбасы чыга. Балалар Ризаэддин Фәхреддиннең «Әдәпле бала», Шакирҗан Хәмидинең «Әдәби әхлак» һәм «Тарихел Ислам», «Нәсихәтил салихин», «Миһмәтел мөслимин», «Гыйлме хәл», «Фазаилшеһүр», «Һәфтияк», «Коръән» кебек китапларны укыйлар, ә «Иман шарты»н, «Кырык хәдис»не ятлыйлар. Шулар белән бергә татар шагыйрьләренең әсәрләрен дә ятлыйлар, еш кына җыйнаулашып, көйләп укыйлар. «И бәһале», «Уянмас йокы», «Сөембикә манарасы», «Ачы җилләр» исемле шигырьләрне яратып хәтерләрендә калдыралар. Мулла Ислам диненә сын күңелдән ышана һәм сөя, башкаларны да шуңа өнди. Ул Ислам мәдәниятен иң югары мәдәният дип исәпли. Калган мәдниятләр бу вакытлы дөнья өчен генә уйлап чыгарылган дип уйлый. Биш вакытлы намазын һич калдырмый, юлдамы, сәяхәттәме, эштәме, намазын укый. Намаз артыннан ук кычкырып Коръән укып җибәрә. Юлга чыкканда гел тәһарәт алып чыгып китә. Юлында нинди генә авылның мөселман зыярәте булмасын, әрвәхләргә сәлам биреп дога кылып китә. Өйдә балалар белән берлектә ашап-эчеп, сөйләшеп утыруны яхшы күрә. Үзе белгән-күргәннәрне сөйләргә ярата, сүзгә оста, мантыйклы, мәгънәле итеп вакыйганы ашыкмыйча сөйләп бирә. Аны кызыклы һәм көлкеле итеп ба-

ланың акылына сеңдерә. Буш вакытында кулыннан китап, газета төшеп тормый. Балалары үсә төшкәч алар белән бәхәсләшеп шигырь яки хикәя яздыру, кычкырып аваз белән Коръән укулар, һич булмаса хисаплау-санауда ярышу бер матур гадәткә әйләнә. Гаиләдә балалар белән утырганда вак-төяк сүзләргә урын калдырылмый. Кем өйләнгән, кем аерылган, кем сугышкан, кем нәрсә эшләгән кебек гайбәт сүзләр һич кузгатылмый. Үзенең балаларыннан берәрсен кайда гына барса да утыртып алып китә. Юлда аларга яңалыкларны күрсәтеп, сөйләп китәргә ярата. Чистайда, Чаллыда, Минзәләдә булганда балаларын «томанлы картина» карарга алып керә. Ә ул чакларда муллаларга киногa бару әле зур гөнаһ саналган.

Талип мулла җәен дә, кышын да бик иртә тора. Иртәнге намазларын тәмам кылгач, балалар һәм абыстай белән чәй эчә. Гадәттә иртәнге чәй табынында бодай күмәче, ак май, шикәр, куе такта чәй хәзерләнә. Бер чиләк су керә ала торган самавыр паровоз кебек чыжлап утыра. Чәй күп вакытта сәкегә җәйгән калын киез як келәм өстенә әзерләнә. Сәкедәге келәм өстенә зур кулдан тукылган ашъяулык җәелә, аның өстенә ялтырап торган җиз поднос куела, аның эчендә чашкалар, сөт савытлары, майлар, баллар куела. Кечкенә җиз подноста самвыр пошкырып утыра. Хөмәйра абыстайның урыны гел самавыр янында, ул чәй ясап бирә. Чәй кечкенә фарфор чәйнектә пешерелеп һәрвакыт самавыр башында тотыла. Коры чәйне әледән әле чәйнеккә аз-азлап ташлап торыла. Чәйне куе каймаклы сөт белән эчәләр. Гадәттә мулла түрдә аякларын бөкләп утыра. Балаларга аш өстәлендә уйнап, селкенеп, шаяып утырырга рөхсәт юк. Чәй янында эшләнгән яки эшләнәсе эшләр, нинди вазыйфалар башкарылырга тиешле гамәлләр турында гына сөйләнелә. Аш ахырында Аллаһы Тәгаләгә дога кылу, амин тоту фарыз була.

Көндезге аш гадәттә сәгать бердә оештырыла. Анда гел кайнар аш әзерләнә (шулпа, токмач, өйрә, ботка, боламык, бәлеш, тәкә, пилмән, коймак, кабартма, кыстыбый, сумса кебек ризыкларның берсе әзерләнә). Аштан соң кышта ат ите, җәй көннәрендә сыер, сарык итләре белән шулпалы бәрәңге куела. Ит күп салына һәм үлчәүсез пешерелә. Аш зур чаган агач табак белән табынга куелып һәркем үзенә кирәгенчә ашау тәртибе куелан. Кечкенә чүмеч белән ашны тәлинкәләргә бүлеп салалар. Кашыклар чаганнан эшләнгән. Яхшы куе каймаклы катык, сөт хисапсыз, һәркем теләгәнчә ашый-эчә. Кич белән дә кайнар ашлар, чәйләр әзерләнә. Мулла өендә исерткеч исемлекләр тотылмый, бер генә исерекнең дә йортка, хуҗалыкка керергә хакы юк. Монда уен коралларында уйнау, җырлап йөрү кебек гадәтләр ят нәрсә. Дини шигырьләрне яки Коръәнне көйләп уку гына рөхсәт ителә.

*[Башка дәфтәрләрне эшкәртү дәвам итә].*

***С.М. Газизьянова,***
***Ф.Ф. Сабирьянова***

# РАЗВИТИЕ ТАТАРСКОГО КРАЕВЕДЕНИЯ И ТУРИСТИЧЕСКИЙ ПОТЕНЦИАЛ ТАТАРСКИХ СЕЛ РЕСПУБЛИКИ МАРИЙ ЭЛ

*Краеведение – самый массовый вид науки,*
*которым может заниматься любой желающий.*

*Д.С. Лихачев.*

***Аннотация:*** *В статье раскрыт туристический потенциал Республики Марий Эл в районах компактного проживания татар.*

***Ключевые слова:*** *краеведение, татарское общество, религиозные деятели, история татар, туризм, туристический маршрут, туристский продукт.*

Общеизвестно, что летописи, исторические повествования и устные предания помогают приобщаться к истории, археологии и архивным делам. Созданное в августе 2016 г. Татарское общество краеведов способствует приобщению широких кругов населения нашей республики к своим историческим корням. Энтузиасты среди татарского населения Республики Марий Эл с целью сохранения прошлого в настоящем поддерживают идею краеведения исторических ценностей.

*Работа нашего общества направлена на изучение истории татар и знаменитых личностей республики, а также культурного наследия и быта жителей Звениговского, Мари-Турекского, Медведевского, Моркинского, Параньгинского районов и городов Йошкар-Ола и Волжск, где они компактно проживают. Они составляют около 6% населения Республики Марий Эл [komanda-k.ru].*

Дальновидность краеведов-земляков своего времени, их увлечённость литературой в силу грамотности, дали возможность нашему поколению иметь уникальные экземпляры источников, которые хранятся в фондах Института языка, литературы и искусства Республики Татарстан.

Стоит отдельно отметить, что в этих источниках содержатся сведения, переданные Ахмедом ибн Хафизетдином, Расихом Ижматом (Гаязовым), Магруфом Гаязовым и его дочерью, автором двухтомника «*Нәсел хатирәсе*» о своем роде Райханой Гаязовой, возглавляющей краеведение Параньгинского района [Гаязова: 2012]. Все имена, содержащиеся в последнем труде, составляют генеалогическое древо знатного рода Урмата. В рукописных работах полутора десятков служителей Ислама из этого

рода, в том числе в «Истории Параньги», можно найти богатую информацию по этнографии. Ждут своего часа непереведенные стихи Хафизетдина, обращение-наставление из 93 строк в стихотворной форме к туташам (татарским девушкам) о нравах и правилах, начиная с их одеяния. А также учебные пособия, рассказы о трех братьях-камнетёсах, мастерах по изготовлению намогильных камней каллиграфической надписью, умерших в один год из-за плохих условий при работе с известняком [Ахметьянов: 1991]. Рецензент книги «Нәсел хатирәсе» («Святой земли» знатный род) М.И. Ахметзянов оценил данное издание как историческую энциклопедию.

Свой вклад в изучение истории нашей республики вносят учитель истории и обществознания МОУ «Кульбашинская основная общеобразовательная школа» Р.М. Фахриев (Моркинский район), Р.А. Зулькарнаев и Р.М. Гаязова (Параньгинский район), Ф.Ф. Сабирьянова (Медведевский район), С.М. Мухарлямов (Мари-Турекский район). Добрую славу о краеведческой работе оставила ветеран педагогического труда Ф.Х. Вагизова, сейчас продолжающая дело своего отца по духовно-нравственному воспитанию населения. Большинство этих краеведов работают с архивными материалами. Но, к сожалению, желающих заниматься этой деятельностью пока недостаточно.

Любые познания о родном крае помогают нашим краеведам лучше узнать историю своей семьи, предков, людей, живущих рядом с нами, и тем самым понять ценность стараний, направленных на то, чтобы сохранить и преумножить уже созданное предыдущими поколениями. В результате из-под пера татарских мемуаристов появляются новые исторические воспоминания, помогающие увековечить изученный материал, который приобретает форму печатного издания. Например, книга учеников Куянковской средней школы «Пронести через века» [Пронести через века: 2005]. В ней – воспоминания одноклассников по школе и Параньгинскому педтехникуму коллег Гайнана Курмаша (в феврале 2019 г. исполнится 100 лет со дня его рождения), выпущенная под руководством директора школьного музея Ф. Вагизовой в годы её работы.

В 2017 г. увидел свет сборник литературных произведений татарских авторов в республиканском масштабе «*Чык тамчысы*» («Капелька росы»). Автору проекта Ф.Ф. Сабирьяновой удалось удачно сочетать сведения краеведения с литературными произведениями */*Чык тамчысы: 2017*]*. Рецензент «*Чык тамчысы*» («Капелька росы») Р.М. Миннуллин назвал данное издание литературно-культурной энциклопедией. 5 мая 2018 г. прошла презентация этой книги с приглашением местных авторов и гостей из Республики Татарстан.

Следует отметить, что наши краеведы принимали участие в сборе информации для книг из серии «История сёл и деревень» [12rus.ru]. А краевед с многолетним стажем Ф. Мухаметова руководила авторским коллективом, при этом подготовив весь материал к печати.

Народные промыслы и фольклор – такие темы охватывает книга «Национально-культурное наследие татар Марий Эл» выездной экспедиции казанских учёных под руководством М. И. Ахметзянова в Параньгинский район. Татарское население марийского края с большим желанием поведало ученым о хранившихся долгие годы в памяти легендах. Охотно были представлены также семейные сокровища народных промыслов из сундуков.

Также историю сёл и деревень республики узнаём ведя работу с земляками, проживающими в других регионах, в зарубежье. В сборнике очерков «Наша семья и я» Р. Зиминой, уроженки деревни Верхняя Алашайка, ныне жительницы Набережных

Челнов, мы знакомимся с историей уже давно не существующих деревень и производственных объектов, таких, как база «Заготскот» и Яхинский овощесушильный завод, построенных и возглавленных ее отцом.

Уроженец деревни Куянково, полковник в отставке, М. Халирахманов из г. Алматы, всегда на связи с земляками. Славно прожив 90 лет, он в библиографическом формате делится с читателем впечатлениями о проведённых и прожитых с родственниками годах вместе с коллегами [Халирахманов: 2016].

Сегодня круг носителей информации в корне изменился, более популярными стали электронные варианты книг. Поэтому, телеведущие республиканских передач «*Туган тел*» и «*Изге мәчет*» М. Гумарова и С. Шакирова, записав историю татарских деревень и мечетей в Республике Марий Эл, создали ценную информационную базу, может быть, пригодную даже для страниц Интернета.

В последнее время почти в каждом номере татарского вкладыша Параньгинской газеты «Наша жизнь» (к сожалению, единственной в республике) публикуются исторические материалы о деревнях и мечетях. Взявшийся с обострённым интересом за работу энтузиаст Ф. Мусин тесно сотрудничает с краеведами Р. Гайнановым из Параньги, Р. Гайнановым из Москвы и Н. Бариевым из Алашайки.

Наши очерки о татарских религиозных деятелях, написанные с использованием архивных материалов, доступны для широкого круга читателей. Они печатаются в Федерально – просветительской газете «*Татар дөньясы*» («Татарский мир»), в изданиях, выпускаемых под редакцией Д. М. Исхакова [Туган җир: 2017. № 1; Туган җир: 2018. № 1].

Приятно отметить, что татарскому краеведению в последнее время начали уделять больше внимания в печатных изданиях, выпускаемых на марийском и русском языках в нашей республике: журналах «Ончыко» и «Марийский архивный ежегодник». А в двух изданиях Марийского научно-исследовательского института языка, литературы и истории им. В. М. Васильева «Социологические исследования межнациональных и межконфессиональных отношений» [Социальные исследования: 2010], «История Марийского края в лицах» [Казимов, Кузьмин, Кошкина: 2017] использованы научно-обоснованные данные, полученные из Уфимского Духовного управления и Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова.

*В настоящее время продолжается работа по включению общественных деятелей в ряды краеведов, составлению плана работы на ближайшее время. Осуществляется совместная деятельность со школами, СМИ, учреждениями культуры и ветеранскими организациями.*

*В апреле 2018 г. в городе Йошкар-Ола прошла Республиканская научно-практическая конференция по краеведению с участием ученых Республики Татарстан, в которой было предложено 2019 г. объявить годом Гайнана Курмаша.* Для нас важным является пополнение родословной соратника Мусы Джалиля – Гайнана Курмаша, где одну ветвь составляет семья моего прадеда Шарифа Курмашева. Эта работа, несомненно, вызывает интерес и школьных краеведов.

Краеведение татар Республики Марий Эл богато традициями, к сожалению, порою уходящими в забвенье, но оно занимает важное место в возрождении татарских сел и деревень. Соприкосновение с прошлым, подкрепленное документальными материалами, оказывает влияние на формирование чувства гордости за тот край, где живет человек, являясь самым действенным механизмом воспитания.

В нашей республике имеются потенциальные возможности для развития татарского туризма. Этому способствуют уникальные природные ресурсы и богатое историко-культурное наследие татар. Туризм является одним из инструментов оживления экономики, стимулируя развитие таких сфер экономической деятельности, как услуги по размещению, транспорту, торговле, производства сувенирной продукции, связи, общественного питания, сельского хозяйства, строительства.

На современном этапе осуществляется разработка туристических маршрутов по достопримечательным местам компактного проживания татар, предусматривающих посещение татарских Домов культуры, школ, библиотек, мечетей, памятников, музеев, мест отдыха и экологических зон.

В Параньгинском районе существует 10 татарских деревень и сел: Алашайка (*Мазарбашы*), Ирнур (*Яңавыл*), Купай, Куянково (*Куян авылы*), Ляжбердино (*Лажы*), Поле-Кугунур (*Олыкыр*), Портчара (*Путчара*), Портянур (*Пуртаныр*), Тоштоял (*Иске авыл*), Хасаново (*Хәсән пүчинкәсе*). В поселке Параньга (*Бәрәңге*) нескольким улицам присвоены имена видных татарских личностей: Хасанова (*Хәсәнов урамы*), Тукаевская (*Тукай урамы*), Гаязова (*Гаязов урамы*), Гайсина (*Гайсин урамы*), Абдуллы Алиша (*Абдулла Алиш урамы*), Хасана Туфана (*Хәсән Туфан урамы*), Курмашева (*Курмашев урамы*). Интерес посетителей вызывают духовные и культурно-образовательные объекты поселка Параньга: Центральная мечеть и мечеть микрорайона «Молодежный», Центр татарской культуры, библиотеки, музей, школа и строительно-технологический техникум.

В деревне Алашайка с 1829 г. функционирует соборная мечеть. В деревне Портчара установлен бюст Героя Советского Союза Ахмеда Саффа Гайсина. В Куянковской среднеобразовательной школе прикреплена мемориальная доска Гайнану Курмашеву [komanda-k.ru].

В Мари-Турекском районе существуют 15 татарских деревень и сел: Болгары, Верхний Мир, Дружино, Малый Исмаил, Малые Нослы, Малая Нуса, Малый Тюнтерь, Малые Янгурцы, поселок Мариец, Новопавловский, Новый Мир, Тат-Китня, Тат-Шолкер, Шишинер, Яхино. В Моркинском районе – 3 деревни и села: Кульбаш (*Күлбаш*), Алмаметьево (*Татар Кошнасы*), Тат-Чодраял (*Комырхуҗа*). В деревне Алмаметьево с 1899 г. функционирует мечеть. Нетронутая природа в виде прудов, лесов и полей становится популярным местом для спокойного семейного отдыха, лучших нежели достопримечательности и шумные представления. Моркинский район богат рекреационными зонами: пойменными и карстовыми озерами, родниками и сосновыми борами.

Наиболее перспективным является развитие сельского туризма в татарских деревнях и селах, включая различные направления с проживанием по маршрутам. По современным меркам данный вид не требует больших затрат и имеет меньший срок окупаемости по сравнению с другими видами туризма. При этом используется весь потенциал края. Развитие сельского туризма способно частично решить и проблему занятости на селе. Этот вид деятельности стимулирует развитие сопутствующей туризму индустрии: производство сувенирной продукции, сбор ягод и грибов для последующей реализации туристам, сбыт части сельскохозяйственной продукции. Сельский туризм может быть одним из внутренних источников инвестиций для развития сельскохозяйственного производства, способствующий объединению в себе агро-, рекреационного, ак-

тивного, этнографического туризма, способная функционировать круглый год [Газизьянова: 2015].

Для успешного развития туризма в татарских селах и деревнях республики мы планируем создание комплексной республиканской программы поддержки, привлечение инвестиций в туристскую отрасль, инфраструктуру. Благодаря малым издержкам и приемлемым ценам, туристский продукт высокого качества может оказаться вполне доступным. Развитие татарского туризма в соседствующей с Татарстаном Республике Марий Эл будет достигнуто только при эффективном росте культурно-экономического потенциала районов.

## Литература


1. Ахметьянов Р.Г. Тарихе Беренгеви. /Перевод рукописи/ «История Параньги» со старотатарского, персидского и староарабского языков. Казань: 1991.
2. Газизьянова С.М. Перспективные направления развития туризма в Республике Марий Эл//Россия и Европа: связь культуры и экономики: Материалы XI международной научно-практической конференции (27 февраля 2015 г.). в 2-х частях. Ч. 2. / Отв. редактор Уварина Н.В. Прага, Чешская Республика, 2015.
3. Гаязова Р.М. Нәсел хатирәсе. 1–2 том. Й-Ола: 2012.
4. Казимов А.С., Кузьмин С.П., Кошкина О.А. История Марийского края в лицах. Йошкар-Ола: 2017.
5. Пронести через века: сборник материалов /Под редакцией Ф.Ф. Сабирьяновой. Йошкар-Ола: ГОУДПО(ПК)С «Марийский институт образования», 2005.
6. Социальные исследования межнациональных и конфессиональных отношений. Йошкар-Ола: 2010.
7. Туган җир: Төбәк тарихы буенча басма [Родной край: Краеведческое издание]. Вып. 1 Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017.
8. Туган җир: Төбәк тарихы буенча журнал [Родной край: Краеведческий журнал]. № 1. Казан: Бөтендөнья татар конгрессы. 2018.
9. Халирахманов М.Х. Жизнь продолжается. Алматы, 2016.
10. Чык тамчысы (Капелька росы)/Под редакцией Ф.Ф. Сабирьяновой. Йошкар-Ола, 2017.
11. Шигапов Р.Ш. Дорогая моему сердцу сторона. Й-Ола, 2016.
12. http://komanda-k.ru/Марий-Эл/татары.
13. http://www.12rus.ru/list/26.

## Мирасыбызның төбәк тарихына кагылышлысы

## Наше историко-краеведческое наследие

# ИДЕГӘ ДАСТАНЫ

*(Дәвамы. Башын карагыз: № 1, 3, 2019).*

### V

Идегә би Шаһ Тимергә барып күренгәч, Шаһ Тимер аны бөтен юлдашлары ман бик хуплап каршы алды. Сарай кешеләренең катнашы ман өлкән бер мәҗлес ясатты. Идегә Шаһ Тимергә Ак Урда (Алтын Урда) иле турысында бераз сөйләгәннән соң, аны барып алгалы чакырды, болай диде:

– Әй, Әмир күргән[1] (кушаматы), теләгең өлкән, гаскәрең күп, көчеңне кая куйгалы белмәйсен. Ерак-ерак илләргә, малсыз-фәкыйрь йирләргә, утсыз-сусыз чүлләргә чачаулыклар[2] кыласыз. Күз алдыгызда яткан, балга-майга баткан монау илне – Ак Урданы күрмәйсез. Туктамыш хан ман аның кайбер биләре, төмән[3], мең башлыклары, toткавыл[4], ясавыллары[5] арасында берлек булмаганын абайламайсыз, шәйләмәйсез. Аны алу сезгә йиңел дә, тиз дә, файдалы да булачак. Сиңа каршы торырлык көч – дошман, сиңа тоткар булырлык киртә – курган юк. Майга чумарга, балда йөзәргә теләсәң, әйдә тор, гаскәреңне йый! Син үзең баш бул, мин сиңа аяк булаен! – диде.

Шаһ Тимергә Идегәнең күрсәткәннәре ятыш күренде. Ул тизлек белән гаскәрен (чирүләрен) йыйды. Сугыш кораллары, ерткычларын тайярлады. Иравыл[6], чагдавыл[7], сургавылларга[8] бүлде. Сарайга Идегә киңәше буенча Урал таулары ягыннан барып баскынлык кылгалы булды.

Сәмәрканддан Ишем, Тубыл суларының башларына килеп, Урал таулары буйлап килеп чыкты. Көтелмәгән йирдән сугыш башлады, бөтен йирне саранча кебек каплап, бураннар уйнатып, очкыр уклар алып, кискен кылычлар ялтыратып, очлы сөңгеләр тибрәтеп, кеше буар арысланнар үкертеп, кеше өстенә сикерәр юлбарыслар, капланнар йөгертеп, Шаһ Тимер гаскәре белән килгән Идегә мән шулай ук тайярланган Туктамыш гаскәре арасында сугыш башланды.

Иң элек зур батырлар арасында көрәш башланды. Туктамышның батырларына каршы көрәшкә, гаскәренә куркыныч салу өчен иң элек Идегә чыкты. Көрәш башланды.

Идегә тотып, аны элек йиргә атты,
Дошман батыр салмагыннан[9] йиргә батты.
Шуннан соңын «инде күкне күреп кил»!» дип,
Күтәреп алып, тагын аны күккә атты.
Зур батыр менеп китте күккә әйләнеп,
Кылыч, мылтык, садакларын һәм бәйләнеп.
Иртән китеп, кичкә таба зур батырың
Төшеп килә бүз тургайдай кайта әйләнеп.
Идегә шунда күккә тагын карап калды,
«Бүз тургайны» төшермичә кулга алды.
Бармагының очларында уйнаткан соң,
Мосафирны[10] әйләндереп гүргә салды.

Шуннан соң Идегә Шаһ Тимер ягындагы гаскәр белән Туктамыш гаскәрләре арасында сугыш башлады. Шулкадәр каты сугыш булды ки, бу кадәр сугыш моңача йир йөзендә булганы юк иде. Берничә көн буенча көн-төн туктамастан сугыштылар. Актыктан Туктамыш гаскәре җиңелеп качты.

Сарай, Әстерхан шәһәрләрен алгач, Шаһ Тимер Сәмәркандка кайтып китте. Идегә Ак Урдага (Алтын Урдага) хан булды. Ил көтә башлады. Туктамыш качып китте.

Туктамыш хан качкан чагында үзенең шәүкәтле ханлыгы, туыпүскән йирләре, Идел буйлары, Сарай шәһәре, үзе торган Алтын Ташы ман аманлашты (саубуллашты). Аманлашканда күз яшьләре мән өзелеп аманлашты. Үткәндәге яхшы, матур тормышларының Идел, Сарай ман бәйләнгәннәрен искәреп, сагынып, кайгырып ерлады.

Туктамыш ханның халыктан аерылганда халкы ман аманлашып ерлаганы:

Әй байтагым, байтагым,
Сине алдырдым мин тагын.
Дошман талар килгән соң
Әл-әман бул миннән соң!
Байтагымның эчендә
Ун сан минем нугаем;
Ун сан нугайдан азак –
Өч йөз алтмыш йорт казак,
Синнән тагы аерылдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Унбиш батыр арталмас[11],
Унике атан[12] тарталмас,
Олы туым[13], биек Урдам,
Башта сезне алдырдым,
Сезне яуга калдырдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Үзән дә Үзән, Үзән су –
Үзәкләп Урдам кунган йорт,
Үзәкләп кунган Урданың
Башына тынгы кунган йорт.
Тынычлык-мазаң алдырдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Тулыксыган ана Идел,
Тулыксып урдам кунган йорт,
Байтагымның баласы
Туып-үсеп уңган йорт,
Уңышыңны алдырдым,
Әл-әман бул миннән соң!

Балыклары чумышкан,
Кошлары очып куышкан,
Сыгын[14], киегең йөгерешкән,
Елкыларың кешнәшкән,
Сыер, куйларың маңрашкан
Идел-ау, синнән аерылдым.
Әл-әман бул миннән соң!
Аюларың үкерешкән,
Агачың айбар[15] күренгән,
Алмасы җиргә түгелгән,
Талларың суга иелгән,
Идел-ау, синнән аерылдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Кундакка[16] урдам кундырып,
Хан сараен сулдырып,
Артыма чатыр кундырып,
Алдыма базар кордырып,
Алтыннан акча кистереп,
Аңарга мөһерен суктырып,
Тагы аз гына мин анда
Хан булаен дип идем,
Аркасындан даулаган
Даным калсын дип идем,
Сине тагын алдырдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Уты үскән утлы йорт,
Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт,
Синнән тагы аерылдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Ябагалы яшь тайлак[17]
Ярдай атан булган йорт,
Ятып калган бер туклы[18]
Йәелеп, мең куй тулган йорт,
Атам кияү булган йорт,
Анам килен булган йорт,
Күрекле туган сылуны
Бикәч итеп алган йорт,
Алып кулым салган йорт,
Әл-әман бул миннән соң!
Йуыктан сиңа киләлман,
Алтын Таш[19], сиңа керәлман,
Алысдан сине күрәлман,
Әл-әман бул миннән соң! –

дип, Туктамыш хан яна-яна аерылып, качып китте. Гаиләсе торып калды. Туктамыш хан качканда өстенә көбәсен кигән, садагын биленә таккан, тукмак яллы турысын менгән иде. Үзенең сер сакларлык дип ышанган кешесенә элек Төлке-күлгә барып ятачагын, анда куркыныч булса, Ку-күлгә барып качып ятачагын әйтте дә юнәлә бирде. Туктамыш аргымакка бер типкәндә, аргымагы йиргә мең типте. Канатсыз хәлдә кош очты, ләкин күз-колактан ераклагач, акыртын бара башлады. Кызарып таң атты, моңаеп көн чыкты. Туктамыш баруында һаман да дәвам итте. Бара торгач сусады, далада торган өйгә туктап, тиз генә сусын эчте дә, Төлке-күлгә китте. Күлгә йитте. Куаклык-камышлык арасына кереп атын бәйләде дә тынарга ятты...

Туктамыш качканнан соң Идегә гаскәре Сарайга керәр-кермәстән аның яклы кешеләр тарафыннан Сарай шәһәренең төрле ягына төнлә ут салынды. Халык сугыш куркынычы эчендә генә түгел, ут куркынычы эчендә дә калды. Кая баргалы урын тапмастан, Сарай шәһәре эчендә шау-шу күтәрелде. Бөтен шәһәрне дәһшәт каплады. Халык куркыныч астында гөж килгәндә бик аз гына каршылык ман Идегә гаскәрләре Сарайны басып керде. Керү мән Туктамыш ханны эзләделәр, ләкин тапма-

дылар. Сораша торгач, аның кайсы якка качканын белделәр. Идегә үзенең углы Норадынны Туктамыш артыннан куа чыгарды.

Туктамыш хан качып киткәндә аның бик сылу ике кызы калды. Олысы Кузыкай, кечесе Күзекәй дип атала иде. Норадын Туктамышның артыннан куа чыкканда атасына:

Туктамышның олы кызын үзеңә улҗа итәрсең, кечесен миңа сакларсың, мин сиңа Туктамышның башын китерермен, – дип үтенде.

Идегә:

Тыныч бул, кечесе синеке, – диде.

Норадын Тарлан Бүзне менеп, алга иелә биреп, тезгенен бушата төшеп, «чү» дип бер тибенгән иде, койрыгы йорттан чыкканда башы шәһәрне үтеп чыкты. Далада артыннан күтәрелгән тузан басылып та өлгермәде, Тарлан Бүз өстендә очкан Норадын киң даладагы күремнән[20] дә югалды. Озак заманнар чапты, Төлке-күлгә җитте. Камышлыклар арасына кереп карап тормады, камышлыклар өстендәге һавага бер күз ташлап чыкты, һавада бер тирәдә әйләнә-әйләнә очкан кызгачтаулар[21] күренмәде. Норадын күлгә таба үтте.

Бу вакытларда Туктамыш Төлке-күл белән Ку-күлнең арасындагы яртылык юлны үткән иде. Юрта-чаба барадыр иде. Инде Сарайдан яхшы ук ерак җирдә барамын дип уйлады Туктамыш. Авырлык кылган мең чүкеч көбәне куеп калдыргалы булды. Ләкин яшергәле билгеле бер урын тапмады. Аптырап, бүз юшанга[22] ташлап калдырды. Ташлаганда шуны ерлады:

Бер билгесе юк икән
Мең чүкечне салгалы,
Билгесенә каранып,
Кайтып эзләп алгалы.

Карап калгыр кара тун
Бүз юшанга салаен,
Алла үземә биргәндә
Кире кайтып алаен, – дип,

көбәсен юшанга ташлап калдырды. Байтак кына вакытлар барганнан соң Ку –күлгә җитте. Ку-күлнең иң озын камышлы йиренә кереп куян посты.

Туктамыш хан артыннан куа килгән Норадын Туктамышның юшанга ташлап калдырган көбәсенең өстенә килеп чыкты. Аны өстенә киде дә Ку –күлгә юнәлде. Юрта-чаба баруында дәвам итте. Ку – күлгә якынлаша төшүгә акрынлап бара башлады.

Качып яткан Туктамышны бу вакытларда әллә нинди төрле куркынычлар чорнап алды. Бар әйбер дә аны төртеп күрсәтәләр төсле күренде. Тирәсендәге әйберләрдән зарлангалы тотынды:

«Дөрс-дөрс» итеп, «дөрс» итеп,
Дөрселдәмә, сум йөрәк;
Тынычлыкка зар чакта

Дөрселдәвең ник кәрәк!
Кыштырдама, бала усак,
Минең казак яткан чак.

Кыштырдавың йаныма
Куркынычлар аткан чак.
Тыңламасаң үземне,
Зарлап әйткән сүземне,
Батырларым, беләрем
Сөңге сабына кыярлар,
Кыштырдап япракларын,
Иргә төшеп суларлар.
Тулкынмачы, тонык су,
Мине өшеткән суык су,
Тыңламасаң сүземне,
Өстеңә елкы әйдәрмен,
Бер суырса, корырсың,
Таңга калып торырсың.
Кыйгулама, кызгач кош,
Тавышың зарлы байгыш[23] кош
Баш өстемдә әйләнмәче,
Канатың куыш, муеның буш.
Батлавык[24] тулган елкым юк,
Ояң таптар малым юк.
Оя тулган йомыркаңны
Итәкләп алыр улым юк.
Син күл иясе булсаң да,
Мин – күпләрнең иясе,
Баш очыма әйләнеп,
Сине күлдән аерган,
Кыйгу салып йөрмәче!
Мине илдән аерган,
Минеңдәен саргаеп,
Казакъ чыксын иленнән!
Садаклары салбырап,
Бер төшмәсен биленнән!
Минем газиз байтагым
Тубыктан канга батты ла,
Тугыздан үрмә кыл аел
Аргымакка батты ла!
Әзәлдә[25] яу Идегә
Малымны алып туймадың,
Сылуларның сылуы
Кузыкайны алмай куймадың,
Арттан төшми йилдең син,
Арттан эзләп йөрдең син.
Аждаһадай ажгырып,
Баш йоткалы килдең син! –

дип ерлап туктап та өлгермәде, кызгач кошның кыйгулап очып йөргән җиренә Норадын килеп тә йитте. Туктамыш хан сыбай килгән тавышны ишетеп, урман, камышлыклар арасыннан тора килде. Норадынның килә ятканын күрде дә:

Син ич минем колымсың,
Мин Чыңгызмын, беләмсең?
Үлтермәмен мин сине,
Үлтермәссең син мине! – диде.
Норадын әйтте:
Мин бер колың түгелмен,
Син дә Чыңгыз түгелсең.
Мин кымырыска[26] булып та,
Син Сөләйман[27] түгелсең!
Камчысы кайма алтын
Каныбәк тә хан булган,
Ул да «Чыңгызмән» дир иде,
Ул да Чыңгыз түгел, – ди.
Тибенгесе[28] тезмә алтын[29]
Тыныбәк тә хан булган,
Ул да «Чыңгызмын» дир иде,
Ул да Чыңгыз түгел иде,
Өзәңгесе өзмә алтын[30]
Үзебәк тә хан булган,
Ул Чыңгызмын димәс иде,
Ләкин ул Чыңгыз иде.
Мине колым, димәче,
Сине беләм, димәче,
Минем атым Норадын,
Үлтергәле торамын,
Әйтереңне әйтеп кал,
Атарыңны атып кал, – диде.

Туктамыш хан өмидсез бер хәлдә кошларга, Аллага әйтеп, ярдәм сорайды:

Кыйгышлар да казкошлар (кызгачлар)
Белә алмайсыз, байгышлар,
Сезне күлдән аерган,
Мине илдән аерган
Идегә улы Норадын,
Бер Алладан сораек:
Һич бирмәсен морадын!
Казакъ чыгып йиреннән,
Садагы төшмәй билённән,
Минеңдәен аптырап,
Куркуыннан калтырап,
Баш куярга йир тапмай,
Куылып йөрсен иленнән!

Шул вакытта Норадын әйтте:

Әй, Туктамыш, Идегәне
Кем качырды иленнән?
Кем йөретте Идегәне
Садагын төшермәй биленнән?
Үз кылганың үзеңә кайта,
Икърар[31] юктыр телеңнән!

– Әйт, Туктамыш! Беренче кизәктә (нәүбәттә) син атасыңны, минме? Әйдә, син ат! Беренче кизәк синеке.

Норадын талтая[32] басып торды. Туктамыш аның йөрәгенә карап атты, ләкин Норадынга бернәрсә дә булмады. Чөнки Норадын эчке яктан Туктамыш ханның юшанга ташлап калдырган мең чүкечле көбәсен (тимер киемен) кигән иде. Туктамыш үзе күлмәкчән иде.

Норадын: «Инде кизәк минеке, туры тор!» – диде. Ук ман үлтермәслек итеп кенә атты да, туңкайтып, башын кисеп алып, канҗагасына асты, аннан Тукмак яллы турысына менеп, Сарайга юнәлде. Бара торгач карыны ачты. Берәр йиргә туктап төшләнгәле[33], тынгалы, атын утлатып алгалы булды. Алдарак зур бер тирәк күренде. Атын шуңарга таба борды. Тирәккә якынлашуга, анда кара аргымагын утлаткалы бушатып, тирәк күләгәсендә йоклап яткан бер кешене күрде. Норадын атының аяк тавышына, пошкыруына уянып китсә, алдында Норадын килә ятканын күрде. Норадынны таныды. Аның Туктамышны куа киткәнен ишеткән иде. Норадынның астында Туктамыш ханның Тукмак яллы турысы булуы мәсьәләне тагын да ачыкландырды, ул:

Әй, Норадын, Норадын,
Һич бирмәсен морадың,
Тукмак яллы турыны
Кайда мендең, Норадын?
Мең чүкечле көбәне
Кайда кидең, Норадын?
Саурык[34] бия сөте булган,
Тыныч йортка кот[35] булган,
Туктамыштай ханымны
Син нишләттең, Норадын?

Норадын әйтте:

Тукмак яллы турыны
Тунаган йирдә менгәнмен;
Мең чүкечле көбәне
Үлтергән йирдә кигәнмен!
Саурык бия сөте булган
Тыныч йортка кот булган,

Туктамыштай ханыңны,
Синең якын коныңны[36]
Төлке-күлдә эзләнеп,
Эзен чыгарып алганмын;
Ку-күл дигән урында
Баса барып йиткән соң,
Уклашып[37] көрәш иткән соң
Туңкайтып башын алганмын.

Туктамышның якыны тагын:

Әй, Норадын, Норадын,
Һич бирмәсен морадың! –

диде дә, үткәннән өмид өзеп, киләчәккә өмид баглап әйтте:

Түбәгә качкан дүртәүгә
Түрә булыр көн туармы?
Аркада торган алтауга[38]
Ага булыр көн туармы?
Идегә мән Норадын
Көне батар көн туармы?
Түбәдәге дүрт йолдыз
Таңы атар көн туармы?
Калган-каткан ил булып,
Кадыйр Бирде хан булып,
Борынгыдай дан булып
Торыр көннәр туармы? – диде.

Ачыктан әйтеп сөйләшкән кешене үлтерүне Норадын урынсыз санап, бу кешене үлтермәй калдырды, тимәде. Төшләнгәннән (әбәд ашаганнан) соң атасына, Сарайга кайтуында дәвам итте.

Сарайга барып йитте, атасының йортына көлә барып керде дә Туктамышның башын ияр канҗагасыннан чишеп алып, атасының алдына китереп салды. Китереп салганда әйтте:

Төннәр, көннәр куган соң,
Төлке-күлдә эз алып,
Төлке-күлдән Ку-күлгә
Юнәлгәндәй сүз алып,
Ку-күленә барган соң
Күз йөгертеп алган соң,
Казкошларны кычкыртып,
Тукмак ялны пошкыртып,
Поса-поса баргалап,
Туктамышны тапкан соң,
Ул миңа, мин аңа
Күп сүзләрне әйткән соң
Туңкайтып башын алганмын,
Алдыңа китереп салганмын, – диде.

Идегә:

– Афәрин, улым, афәрин! Һурра, һурра! – дип кычкырып каршы алды.

Туктамыш ханның башын алып килгәнне Идегә белән Норадын бәйрәм иттеләр. Туктамышның гаиләсеннән аның хатыны, кызлары үксеп-үксеп елаштылар. Күп гомерен Туктамышның сарай ермаучысы булып үткәргән Янбай да әсәрләнде моннан. Гаиләсенең сөйләнеп-сөйләнеп, Янбайга даниләрдер әйтеп елашулары аңа да тәэсир итте, аның да күңеле йомшады. Башта өйдәге бу вакыйганы күргән Янбай Идегә янына барып, болай ерлап сорайды:

Каз төшермәс күлләргә
Каз төшердең ни өчен?

Ятим бәбкә тавышы ман
Кан елаттың ни өчен?
Куу төшермәс күлләргә
Куу төшердең ни өчен?
Атылган куу тавыш ман
Зар елаттың ни өчен?

Идегә Янбайга җавап ерлайды:

Каз төшермәс күлләргә
Каз төшердем ил өчен,
Ятим бәбкә (чүри) тавышы ман
Кан елаттым ил өчен.
Куу төшермәс күлләргә
Куу төшердем йорт өчен,
Атылган куу тавышы ман
Зар елаттым ил өчен! – диде.

**Сүзлек – аңлатмалар**

1. Күргән – гүргән, кияү, әмир мәгънәсендә.
2. Чачаулык – һөҗүм.
3. Төмән – ун мең.
4. Тоткавыл – тышкы сакчы.
5. Ясавыл – эчке сакчы.
6. Иравыл – алдан бара торган гаскәр.
7. Чагдавыл – арттан бара торган гаскәр.
8. Сургавыл – дошман артыннан күзәтеп баручы; артта калган яугирләрне куып баручы. – В.В.Радлов. «Опыт словаря тюркских наречий». Т.IV, Ч.1. С.822.
9. Салмагы – авызы.
10. Мосафир – юлчы.
11. Арыту – аркылы бәйләп салу.
12. Атан – печелгән дөя.
13. Ту – байрак.
14. Сыгын – ата поши.
15. Айбар – мәһәбәт.
16. Кундак – куну урыны.
17. Тайлак – ике яшьлек тай (Н.Х.).
18. Туклы – тукты, алты айлык бәрән.
19. Алтын Таш – Урданың хан тәхете торган төп бинасы.
20. Күрем – күз күреме.
21. Кызгачтау – кызгач кош, тәкәрлек, чибис.
22. Бүз юшан – ак әрем.
23. Байгыш – ябалак; кайгы-хәсрәтле мескен кеше: «байгыш туйганчы бер ашаса, баедым дияр»(мәкаль).
24. Батлавык – яшь үлән.
25. Әзәлдә – мәңгелек, башы билгеле булмаган борынгылыкта. Биредә – әзальдә (гар.) булуы мөмкин – туры юлдан язган.
26. Кымырыска – кырмыска.

27. Сөләйман – хайваннар, кошлар телен белүче дип саналган патша (б.э.к. 965–928 еллар).
28. Тибенге – ияр астына салына торган күн ябу.
29. Тезмә алтын – боҗралы алтын.
30. Өзмә алтын – өзеп (кисәкләп) коелган алтын.
31. Икърар – тану.
32. Талтая басу – киерелеп, мәгъруранә басып тору.
33. Төшләнгәле – төшке ашны ашарга.
34. Саурык – «ярсу, чарыс» мәгънәсендә булырга мөмкин (В.В. Радловта айгырга карата әйтелә).
35. Кот – бәхет.
36. Кон – күрек, ямь.
37. Уклашып – ук атышып.
38. Дүртәү, алтау – Туктамыш хан якыннары күздә тотыла.

*(Дәвамы бар)*

Алынды: Татар эпосы. Дастаннар. Казан: «Раннур», 2004. – 286–336 бб.

*И.Г.Закирова*

## «АК КҮБЕК» ДАСТАНЫ

Иҗат ителүе белән Алтын Урда чорына нисбәт ителгән «Ак Күбек» дастанының фәнгә өч варианты (тубыл, бараба, алтай) һәм хакас (абакан татарлары) вариантының өзеге билгеле. Алар барысы да академик В.В.Радловның «Образцы народной литературы тюркских племен» дигән ун томлыгында дөнья күргән. Дастанда бәян ителгәнгә якын вакыйгалар атаклы гарәп сәяхәтчесе Ибне Халдун (1332–1406) китабында [Тизенгаузен: 1884. С.641.], Мисырда яшәгән Ән-Нувәйри (1279–1333) энциклопедиясендә дә бәян ителә.

Ак Күбек турындагы вакыйга Ән-Нувәйри энциклопедиясендә Алтын Урда дәверендә чынбарлыкта булган хәл, тарихи вакыйга буларак тасвирлана. Бу хезмәттә Ән-Нувәйри кыпчакларның унбер кабиләсен искә ала. Аларны Чыңгыз хан гаскәре яулап ала, әмма һ.б. 616-нчы елда монгол гаскәре киткәч, бу кабиләләр яңадан элеккечә тынычлап яши башлыйлар. Бу һ.б. 626-нчы елга кадәр шулай дәвам итә. Бервакыт *дурут* кабиләсеннән Көтән улы Мангуш ауга чыга. Анда *токсоба* кабиләсеннән Аккүбел белән очраша. Ике кабилә арасында күптән килгән дошманлык сәбәпле, Аккүбел Мангушны әсирлеккә ала һәм үтерә. Әтисе, Мангуштан хәбәр булмаганга борчылып, Ќамгарь (яки Ќалангар) дигән кешесен җибәрә. Ул кеше кире кайтып Мангушның үтерелүе хакында сөйли. Мангушның әтисе гаскәр җыеп Аккүбелгә каршы яу белән килә. Ике кабилә арасында бәрелештә Аккүбел яралана, сугышчылар тарала. Аккүбел абыйсы Ансарны (Унсарны) Чыңгызханның улы Душиханга ярдәм сорарга җибәрә. Абыйсы үзләренә дурут кабиләсе һөҗүм итүен сөйли, әгәр дә хәзер Душихан аларга яу белән килсә, дурутлардан башка беркем дә каршы тормаячагын әйтә. Душихан гаскәре белән килеп дурутларны тар-мар итә. Күпчелеген әсирлеккә ала[Шунда ук].

Ән-Нувәйри 1279-нчы елның апрелендә Мысырда туа. 1333-нче елда Каирда үлә. Гомеренең күпчелек өлешен фәнгә багышлый. 30 томлык энциклопедия төзи. Хезмәтнең тарихка багышланган өлешендә Алтын Урда һәм мәмлүкләр солтаннары тарихы буенча да мәгълүмат бирелә [Шунда ук. С.129]. В.Тизенгаузен Ак Күбек турындагы хикәятнең Ибне Халдун хезмәтендә дә булуын әйтә. Мангуш анда Манкыш Китмир улы дип, Аккүбек – Акакибәк, Ансар – Аксар дип бирелгән. Дурутларның *кыпчак*, ә токсобаларның *татар* булуы аңлашыла [Шунда ук. С.541.]. Ибне Халдун галим, өлкән кади була, XIV–XV гасырда яши. Алтын Урда турында да мәгълүматлар тупланган тарихи хезмәтен 1406-нчы елда

яза [Шунда ук. С.365.]. Ән-Нувәйри энциклопедиясендә бәян ителгән вакыйгада кабиләара ызгышлар тасвирлана. Кыпчак кабиләләренең үзара дус-тату яшәмәве аларның монголлар тарафыннан җиңелүенә китерелүе күрсәтелә. Ибне Халдун хезмәтендә исә кыпчаклар белән татарлар арасындагы конфликт тасвирлана.

«Ак Күбек» дастанының В.В.Радлов тарафыннан бараба, тубыл татарларыннан һәм алтайлылардан язып алынан вариантларының нигезендә шушы ук геройлар турында сүз бара. Әсәрнең һәр вариантында аның борынгылыгын күрсәтүче шигъри өлешләр күп сакланган. Аларның кайберләре бер варианттан икенчесенә кергән, икенчеләре исә, һәр вариант өчен үзгәләр. Дастанның сюжетында традицион мотивлар барысы да диярлек очрый – геройның могҗизалы тууы, исем алуы, ат сайлавы, корал барлавы, дошманнар белән көрәше.

Дастанда ыру-ара ызгыш-талашларның яхшылыкка китермәве күрсәтелә, бердәмлек идеясе күтәрелә. Ән-Нувәйри һәм Ибне Халдун вариантларында төрле кабиләләрнең монгол тарафыннан яулап алынуының, тар-мар ителүенең сәбәбе итеп аларның үзара дошманлыгы күрсәтелә.

Әсәрдә халыкның гореф-гадәтләре, ышанулары белән бәйле күп кенә эпизодлар бар. Себер татарлары ислам динен XIV гасырдан башлап кына кабул итәләр. Ә бараба татарларына ислам XVIII гасыр урталарында гына керә[1]. Әсәрдә исламга кадәр чорны чагылдырган күренешләр, мәсәлән, җада (дьада), камчы белән дәвалау, терелтү мотивлары саклана.

Әсәрнең сезнең игътибарга тәкъдим ителә торган варианты академик В.В.Радлов тарафыннан хәзерге вакытта Новосибирск өлкәсенең Каргат районына карый торган Тәрәнә авылында язып алынган. Әсәрнең теле, бараба татарларының сөйләм үзенчәлеген саклаган хәлдә, барлык укучыларга аңлаешлы итү максатыннан, беркадәр әдәби телгә яраклаштырылды. Шулай да гаҗәеп аһәңле бу сөйләшкә караган сүзләрне, әсәрнең үзенчәлеген югалтмас өчен, сүзлек белән биреп барырга омтылдык.

## АК КӨБЕК
## (Бараба варианты)

Инәсенең карнында Ак Көбек йөрде, туар вакытына җитте. Җиңгәләре килде инәсенә, урнына инәен урнаштырдылар. Ак Көбек инәсеннән тумады, таң калдылар. Инәсенең карнында Ак Көбек сүләшеп торды: «Мин тумаймын бу юлыңнан, карынның бер ягыннан җыртып чыгармын!», – диде. Җиңгәләре әйтте:

Алтын бишеккә бер салып
Биләр идек Көбәйне,

1 Кайбер яңа чыганаклар буенча – XVII гасырдан (Редакцион искәрмә).

Көмеш бишеккә бер салып
Биләр идек Көбәйне.

Инәсе әйтте баласына: «Балам, син ходайның яраткан юлыннан чыкмасаң, минем ризалыгым юк». Ак Көбек аннан соң ходай яраткан юл белән туды. Торды, атасының кылычын толымына бәйләде, ялангач күлгә аулап балык тотарга китте. Бер үзәнгә барып төште, бер амыцка үзәннең янында балык тотарга ята. Ак Көбек аңа килде.

Кара әле, кара әле, таз-ай!
Сулар төбен күргән таз-ай!
Бер балык тоткан таз-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!

Бер чабак сорады. Амыцка орышып җибәрде аны: «Фу, кит бу җирдән, сиңа бирергә һич нәрсә балыгым юк», – диде. Ак Көбек үзән белән йөреп китте, анда барды, тагы бер балык тотучы амыцкага җитте. Ул амыцканың янында бер цортанак ятадыр. Ак Көбек аңа килде, әйтте:

Кара әле, кара әле, таз-ай!
Сулар төбен күргән таз-ай!
Бер балык тоткан таз-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!

Карт әйтте: «И балам, ал бу балыкны ялгыз булса да». Бала бу балыкны алды, капчыгына салды, кайтты кире. Көз вакыт иде, су тонган икән, бер сулыкка Ак Көбек карап күрде, кыдыс кыдысны куып йөри, чуртан чуртанны куып йөри, аны күрде Көбек. Аны күреп Көбек әйтте: «Суда балык яу кубара», – диде: «Мин монда тудым, адәм булып мин дә яу күтәрим», – диде.

Аннан кайтып йөреп барса, үзәннән кырга чыккан җирдә, Көден хан алты аяклы аргамакка менеп саклап тора. Бая ялангач суга йөргән баланы күреп, Көден хан әйтте бу балага: «Атың кем?» – диде. Бу бала әйтте: «Ак Көбек кеше, синең атың кем?», – диде. Көден хан әйтте: «Атым минем Көден хан». Ак Көбек әйтте аңа:

Көден, көден дәшәрләр-ай
Атта күрәмен көденне-ай
Атта күрәмен көденне-ай
Көденгә диеп аталган-ай
Син дә бер кеше булыпсың-ай.

Ак Көбек әйтте: «Минем атым Ак Көбек», анда Көден хан әйтеп ятты Ак Көбеккә:

Күбек, күбек (дип) дәшәрләр-ай
Күлдә күрәмен күбекне-ай,
Сөттә күрәмен күбекне-ай,
Күбек диеп аталган-ай
Син дә бер кеше булыпсың-ай!

Ак Көбек атасының кылычын алды, алты аяклы аргамакның бер аягын кисеп алды, Көден хан нәмә белми өенә кайтып китте. Ак Көбек тә өенә кайтып барды, килде инәсенә. Инәсенә Көден хан аргамагының алты аягыннан кисеп алган бер аягын бирде, чуртанны да бирде. Инәсе аларны казанга салып кайнатты. Ашадылар, җыйдылар. Ак Көбек әйтте инәсенә: «Мин менәр ат бармы, инә?» – диде. Инәсе әйтте: «Син минем карнымда йөргән вакытта бер бия җиленләде унике ай, ул бия инде колынлаган булмак», – диде. «Аның туган колыны син менәр ат ул булыр». Ак Көбек йөгән бау алды, Ак Көбек үргә китте. Барды. Биядән Кызыл Ор туган. Кызыл Ор биянең биле өстеннән ашыра муйнын салып, ар ягыннан имчәген авызына алып имеп тора.

Килде Ак Көбек Кызыл Орны колактан тотты, йөгәнләде, өенә алып барды, кайтып өендә иярләде, тун-шайларын киде, бер шәһәргә чыкты. Анда алтмыш алты балта урлап алды; бер башка авылга барды, җитмеш җиде балта урлап алды.

Аннан чыгып килеп Кытай җиренә китте, кылыч суга торган оста кешене эзләп йөрде. Анда барып бер Күцемец атлы останы тапты. Балталарны Күцемецнең алдына куйды.

Алтмыш алты балтаны сызгыртып
Саф булатны калдыргыл!
Җитмеш җиде балтаны сызгыртып
Саф булатны калдыргыл!
Күцемец оста булсаң
Ул булаттан кылыч суккыл!

Күцемец оста бер көн, бер төн сукты, кылычны бетерде, Күцемец алты балтаны җуеп яшерде, кылычны алып китерде, Көбеккә бирде. Көбек кылычны кулына алып салмаклады .

Алтмыш алты балтаның ай
Алтысы кайда, Күцемец-ай?
Алтысын ялгап сукмасаң-ай
Башыңны кисәрмен, Күцемец-ай.

Җитмеш җиде балтаның-ай
Җидесе кайда, Күцемец-ай?
Җидесен ялгап сукмасаң-ай
Башыңны кисәрмен, Күцемец-ай.

Күцемец кайтты, курыкты, алты балтаны кагып кушты, җиде балтаны янә кагып кушты, өч көн суккач, бетереп кылычны алып килде Көбеккә, кылычны кулына тоттырды. Ак Көбек кылычны башыннан тотып салмаклап әйләндерде, көнгә тотты, кояш туклап багып күренде. Ак Көбек бу кылыч(ны) яхшы дип сөенде. Күцемец Көбеккә әйтте: «Кылычны ярар дисәң инде ял бирмәк кирәк». Ак Көбек торды, Күцемецне мактады:

Сугышына чыдамый,
Сум палгалар[2] уалды,
Басуына чыдамый,
Кап күрекләр ярылды,
Андый минем Күцемец-ай!
Мондый минем Күцемец-ай!
Торга[3] булсын бу җирдән-әй!
Камга[4] булсын бу җирдән-әй!
Ишегеңнән тәк[5] иңсен-әй!
Төнлегеңнән тәк төшсен-ай!
Атың-елкың бай булсын!
Баеп-череп үлерсең!

Бу мактаганнан башка ял бирмәде, кайтты аннан соң Ак Көбек өенә. Дәрья якасына барып, Ак Көбек бер таз тайга менде, бер киез такыяны[6] киде, бер киез тунын киде, малын багып ятты. Анда багып йөргән чагында Самыр Казан Алып Ак Көбеккә килде. Ул Ак Көбекнең карт бабасы иде. Самыр Казан әйтте: «Бу кемнең малын багып торасың, таз кол!», – диде. Ак Көбек әйтте Самыр Казанга: «Ак Көбекнең малын багып ятам», – диде. Самыр Казан алып әйтте: «Ак Көбек үзе кайда киткән?». Ак Көбек әйтте: «Ак Көбек ялангач бу күлгә кышлагалы[7] китте». Самыр Казан әйтте: «Кичәге көн туып, бүгенге көн минем белән бәхәсләште, минем диңгеземне ул поклап[8] яткан тора», – диде.

Самыр Казан дәрьяның уртасына барып суга утырды, дәрьядан башы гына чыгып калды. Ак Көбек шайларын[9] алды, яхшы туннарын киде, кылычын баглады, атка менде, көн җадалады[10].

2 Палга – чүкеч.
3 Торга – ефәк тукыма төре.
4 Камга – ефәк тукыма тере.
5 Тәк – байлык.
6 Такыя – баш киеме.
7 Кышлагалы – кышларга.
8 Поклау – пычрату.
9 Шай – корал.
10 Җадалау – магия ярдәмендә һава торышына тәэсир итү.

Яхшы көндә бер әйтсәм-ай
Көн төшер, Ак Көбек-ай
Яман көндә бер әйтсәм-ай
Көн ярәшер, Ак Көбек-ай.

Бер җиде көн җадалады, җиде карыш боз туңдырды; җиде көн җадалагач Кызыл Орына менде, кылычын кулына алды, дәрьяның уртасында утырган Самыр Казан алыпка барды, башын кисәргә килде. Самыр Казан аны өргән иде, тау башына ат белән чыгып китте. Янә Ак Көбек Самыр Казанга кире кайтып килде, үтермәкче касланды[11]. Самыр Казан тагы өреп тау башына чыгарды. Өченче кире тагы килде. Самыр Казан әйтте: «Ак Көбек, син алдар хәйләкәрсең, инде мине бу кылыч белән үтерә алмассың. Кире кайтып бар! Кырда кылычым ятыр. Син бу кылычымны ал! Ул минем башымны кисәр». Аннан барып кылычын алып Самыр Казанның башын кисеп китте. Самыр Казан Алып тубулады[12], җиде карыш боз туздырды, боздан Ак Көбекнең малы егылды, кырылды, Ак Көбек үзе тере калды.

Маңгуш алып, Көден ханның улы, үз җирендә төскә[13] чыккан иде, төсләп[14] йөрде, бер ак киекне үтерде. Анда йоклап яткач, Маңгушның колы киекнең итен пешерер иде. Самыр Казанны үтергәндә боз шаулаганын уктулар[15].

Маңгушның колы әйтте:

Көзгедә бозлар гүләшер-ай,
Ул ни иде, Маңгушым-ай?
Язгыда бозлар шаулашыр-ай,
Ул ни иде, Маңгушым-ай?

Маңгуш уянып башын күтәреп әйтте:

Көзгедә бозлар гүләшер-ай,
Куяклар савыт[16] булмасмы, эцәй[17]?
Язгыда бозлар шаулашыр-ай,
Кылычлар белән булмасмы, эцәй?

Ак Көбек юыртып килә аларга, Кызыл Орына менеп, мылтыгын салып иңенә, саудагын[18] бәйләп, кылычын тагып, йыдасын[19] турылап сөңгесенең, һәрбер шай белән киләдер, Маңгушның колы Ак Көбекне күрде.

11 Каслану – нәфрәтләнү, үчләнү.
12 Тубулады – бәргәләнде, тыпырчынды (?)
13 Төс – урман.
14 Төсләп китү – ауга китү.
15 Укту – ишетү.
16 Куяк савыт – көбә күлмәк. Биредә яу кораллары, көбәләр шавы күз алдында тотыла.
17 Эцәй – икән.
18 Саудак – ук савыты, саадак..
19 Йыда – сөңге очы.

Уң ягында орайган-ай[20],
Су ягында сурайган-ай[21],
Ул ни үзе Көбекнең-ай?
Кызыл Орның пазыгы-ай[22]
Элекке пазыгы әбәс тур-ай[23],
Ак Көбекнең күзләре-ай
Элекке күзләр әбәс тур-ай.

Маңгуш торды, Ак Көбекнең килә ятканын күрде, Маңгуш әйтте:

Уң ягында турайган-ай
Йыдалар-мылтык булмас микән?
Сул ягында сурайган-ай
Уклар-саудак булмас микән?
Кызыл Орынны пазыгы-ай
Аркасына камчы тигәндер-ай.
Ак Көбекнең күзләренәй
Аракы буза чыккандыр-ай.

Ак Көбек юыртып җитеп киләдер. Маңгуш ягысын[24] керешен салдырырга баскан чакта, ул сынып китте. Ак Көбекнең алдына чыгып утырды. Ак Көбек чабып килде, Маңгушның колы ак киекнең пешкән ботын алып аткан иде, Ак Көбекне җиргә төшермәде, кулы белән тотты, ат өстендә ашады. Килде Маңгушның одауына[25] Көбек. «Аш җыешкан яулашмас, диде, дус булаек! Минем йортыма бараек!» – диде. Чакырып китте. Маңгушның колы өенә кайтты, Маңгуш үзе Ак Көбек белән барды; йортына алып барды, сыйлады арацан-корацан[26] белән, куйлар, үгезләр суеп ашатып ятты аны.

Маңгуш әйтте Ак Көбеккә: «Син миңа кушлугыңны[27] сылагыл[28]». Ак Көбек әйтте: «Юк, җизнә, кушлугымның бәясе кыйммәт».

Кактан[29] какка чабар кушлугым,
Казларның башын чабар кушлугым,
Күлдән күлгә чабар кушлугым,
Үрдәкләрнең башын чабар кушлыгым.

20 Ораю – төз, туры тору.
21 Сураю – кырын тору, кыегаю.
22 Пазыгы – басуы, йөреше.
23 Әбәс тур-ай – имәс, түгел
24 Ягы – җәя.
25 Одау – шалаш.
26 Арацан-корацан – сөттән ясалган аракы.
27 Кушлук – ау эте, кошлар аулаучы эт.
28 Сылагыл – бир.
29 Как – күл, сазлык эчендәге утраучык.

Маңгуш әйтте: «И Көбегем, бу кушлугыңның һөнәре яман икән». Көбек әйтте: «И, Маңгуш, син бөркет кошыңны сылагыл миңа!». Маңгуш әйтте: «Юк, җизнә, бу бөркет кошымны сыламаймын, бу кошымның бәясе кыйммәт икән», – диде.

Цөдерер[30] яхшы цөдерер-ай,
Кырык бер марал цөдерер-ай,
Цөдерер белмәгән ул яман-ай,
Атыңнын башын цөдерер-ай,
Үзеңнең башын цөдерер-ай.

Көбек әйтте: «И Маңгуш, синең бөркет кошыңның һөнәре яман икән, миңа кошың кирәк түгел, калсын синдә». Аннан соң Маңгуш әйтте: «Кушлугың яман торыр, Кызыл Орыңны сылагыл миңа!». Көбек әйтте: «Кызыл Орымны сыламаймын, аның бәясе кыйммәт тора», – диде.

Кызыл Орым холыклы,
Койган камыш колаклы,
Тустагандай тояклы,
Сарымсактай азулы[31],
Бәясен җиткерсәң, алырсың,
Бәясен син җиткермәсәң,
Кызыл Орым калыр үземә.

Аннан куйдылар, аш җыйдылар, арацан-корацан эчтеләр, исерек булдылар. Кичкә төн булды. Маңгуш исереп егылды, Ак Көбек әйтте үзе үзенә: «Бу Маңгушны үтерергә кирәк», – диде. Бау белән баулады. Маңгушны бәйләсә дә, бау өзелде. Бау өзелгәндә алты яшьле үгезләрнең тиресеннән ясаган каеш арканнар белән бәйләде. Шул ук заманда бәйләгән каешы өзелеп китте, тузәлмәде. Каеш өзелгәнгә Ак Көбек тимердәй богау салды. Маңгуш кыймылдап бирсә, тимер дә сынып китә. Аннан Ак Көбек урамга чыкты бау эзләп. Урамның ул читендә бер ак сакаллы карт кеше килә иде. Амыцка килде Ак Көбекнең катына. Ак Көбек әйтте амыцкага: «Ирне бәйләргә нәрсәнең тиресе чыдам булыр?», – диде. Амыцка әйтте: «Ир бәйләргә ир тиресе яхшы булыр», – диде. Ак Көбек әйтте: «И амыцка, сүзең чын булса, ир тиресе яхшы булса, син тиреңне миңа бир! Ашыңны ашагансың, яшеңне яшәгәнсең». Ак Көбек амыцканың маңгаена чиертте, үтерде, артыннан телде тиресен, аягыннан телде тиресен, кулыннан телде тиресен. Картның сөяген уалады, пилгеп цыргады[32], тиресе калды. Алып калды бу картның тиресен, Мангушның кулын кеше тиресе белән бәйләде. Ташлап китте Мангушны. Кунып йоклап

30 Цөдерер – ау кошының табышны тибеп алуы.

31 Азулы – тешле (азу теш).

32 Пилгеп цыргау – ыргыту, атып бәрү.

калды, кулы-аягы бәйләгән көйгә кунды. Иртән исереге сәректе[33], уянды. Үзе бауда ятыр, аны күрде. Ак Көбекнең апасы бар иде, ул кыз Маңгушның янында утырды. Ул кыз күптән Маңгуш белән уйнаш иде, бу кызның аты Көн Сылу иде. Көн Сылу Маңгушны күреп әйтте:

Алтын аякка бал коеп-ай,
Исермәдең, Маңгышым-ай;
Көмеш аякка бал коеп-ай
Исермәдең, Маңгушым-ай.

Маңгуш әйтте кызга:

Алтын аякка бал коеп-ай
Атаңа кыя[34] аш чәчкел-ай!
Көмеш аякка бал коеп-ай
Иңәңә кыя аш түккел-ай!

Тулунуп[35] иелеп типте Маңгуш, җиленә Көн Сылуның бер күзе чыгыр булды. Инде Ак Көбек килде атын иярләп. Маңгушның акбүз атын иярләп китереп, ул үзенең атына аркан җигеп Маңгушны өйдән сөйрәтеп алып китте. Кабыргасына таш тигәндә ут чыкты. Ак Көбек әйтте:

Кабыргасыннан ут чыккан
Атасы күрсен бу кыен-ай[36]!
Көкрәкләреннән ут чыккан
Инәсе күрсен бу кыен-ай!

Ак Көбек Маңгушны Күрләк[37] дигән җиргә алып барды, алып баргавнда Ак Көбек әйтте: «Йә, Маңгуш, әҗәлең монда булсынмы?». Маңгуш җирдә ятып әйтте:

Күрләк дигән олы су ай
Күр[38] адәмнең йорты иде-ләй,
Күрләк[39] бичә бер алып-ай
Салып киткән[40] йорты иде-ләй.

Аннан тагын сөйрәтеп алып китте, аны алып киткәч Шарлак[41] дигән үзәнгә барды. Ак Көбек әйтте: «Йә, Маңгуш, монда әҗәлең булсынмы?», – диде. Маңгуш җирдә ятып әйтте аңа:

33 Сәрегү – бетү.
34 Кыя – гына (только).
35 Тулуну – ачулану.
36 Кыен – читен, авыр.
37 Күрләк – гөрләп, чылтырап аккан.
38 Күр – сукыр (?).
39 Күрләк – әшәке, яраксыз.
40 Салып китү – ташлап китү.
41 Шарлак – шарлап аккан.

Шарлак тигән олы су-ай
Шәр[42] адәмнең йорты иде-ләй,
Шаргы[43] бичә бер алып-ай
Салып киткән йорты иде-ләй.

Аннан тагы аны сөйрәтеп алып китте, кабыргасына таш тигәндә ут чыга иде, күкрәгенә таш тигәндә очкын чыга иде. Ак Көбек аны күреп тагы әйтте:

Күкрәкләреннән ут чыккан-ай
Атасы күрсен: бу кыен-ай!
Кабыргасыннан ут чыккан-ай
Инәсе күрсен: бу кыен-ай!

Манар тау башына алып чыкты. Көбек әйтте: «Йә, Маңгуш, әҗәлең монда булсынмы?», – диде. Маңгуш әйтте: «Йә, булсын минем әҗәлем монда», – диде, «Инде мине үтер! Кылыч белән башымны кисәрсең! Ул, минем башымны үзеңнең башыңа тот! Миндәй алып булырсың», – диде, «Йөрәгемне чокып алып йөрәгеңә тот!», – диде. Миндәй алып батыр булырсың», – диде, «Эчәгемне алып чорнал! Миндәй алып батыр булырсың». Ак Көбек Маңгышны башын кисеп үтерде, башын кисеп башына тотарга теләде. Бер җирдән бер ак сакаллы кеше килде, әйтте: «Ак Көбек, ни кылып торасың?». Ак Көбек әйтте: «Мангушны үтердем, башын алып башыма тотарга телим», – диде. Ак сакаллы кеше әйтте: «И Ак Көбек, башыңа башын тотма! Бу башын сүри[44] тауга ташла!». Тау башына башын ташлады, таш җимерелеп төште. Ак сакаллы кеше әйтте: «Йөрәген алып оймат[45] күлгә ташла!», – диде. Йөрәген аңа ташлады, ул тирән күлнең суы кайнап бетте. Ак сакаллы кеше янә әйтте: «Эчәген алып бу бай тирәкнең башына ташла!» – диде. Эчәген алып бай тирәкнең башына ташлады, бай тирәк башыннан көеп тамыры белән көеп китте. Ул карт әйтте Ак Көбеккә: «Мин булмасам, син үләр идең».

Аннан кайтты Ак Көбек йортына. Көденнең халкы Маңгушны Ак Көбек Манар тау башында үтергәнен укты. Маңгушның атасына әйтергә кирәк. Йортында Маңгушның улы унике яшәр бала булды. Картлар аны өйрәттеләр: «Атаңны Ак Көбек Манар тау башында үтергән; аны карт атаңа – Көден ханга әйт!», – диделәр. Бала барды карт атасына өйрәткән сүзне әйтергә:

Маңгуш бием мартлап[46] тор-ай,
Манар тау башында йортлап тор-ай,

42 Шәр – бай, дәрәҗәле кеше, кенәз кебек титул.

43 Шаргы – усал, әшәке.

44 Сүри – кыя.

45 Оймат – тирән.

46 Мартлау – йоклау.

Сәлам бирсәм дә алар юк-ай,
Сакалдан капсам да угар[47] юк-ай.

Көден хан аны угуп алды. «Бу бала ни-ни сөйлидер?» – дип әйтте. Көден ханга халык әйтте: «Маңгушны Ак Көбек Манар тау башында үтереп киткән». Көден хан улының үлгәнен угуп кайгылы булды, сыктады. Инде җиде йөз чиру шайлап[48] Көден хан: «Ак Көбекне яуларга кирәк», – диде. Җиде йөз чиру белән шайланып чыкты. Ак Көбекнең йортына китте, яу белән. Төнлә бардылар, урта юлга җиттеләр. Анда Ак Көбек белде: «Көден хан җиде йөз чиру белән миңа яулашырга киләдер», – диде. «Алай булса, мин дә шайлап удура[49] чыгыйм!», – диде. Ак Көбек күп кеше алмады.

Талым Коцаның[50] таз улы,
Сүән төбе[51] Сүп Сүрү,
Казан төбе Кап Кара,
Солым – Ак Көбекнең агасы,

Биш кенә кеше удура чыкты. Ак Көбек агасына үр айгырын мендерергә алды. Киттеләр каршы. Анда барганда әйридә[52] йөзгән алабуга балыклар канатларын судан чыгарып кыдырайтып[53] йөриләр. Кырда йөргән Солым балыкларның күрсәткән канатларын күрәдер, әйтте:

Кыдырайганга кыдырай,
Миңа ни өчен кыдыраясың?
Көдерәйгәнгә көдерәй
Миңа нәрсә көдерәясең?

Көден ханга барды Ак Көбек кешеләр белән. Көден ханның халкы әйтте Көбекнең кешеләренә:

Талым Коцаның таз улы
Талган[54] сугарга килгәнме
Сүөн төбе Сүп Сүрү
Сүөн басарга килгәнме?

Аннан Ак Көбек үзе Көден ханның халкына керде, аларны кылыч белән кырып бетерде. Ак Көбек белән Көден хан икесе очрашты, найза[55]

---

47 Угу – ишетү, сизү.

48 Шайлау – коралланy.

49 Удура, утура – каршы.

50 Коца, куца – ата яки ананың бертуган энесе, дядя.

51 Сүән – туганнан туган, двоеродный, сүән төбе – иң соңгы туган.

52 Әйри – елга.

53 Кыдырайту – башны чыгарып карау, бу очракта судан чыгарып, күрсәтеп йөрү.

54 Талга – корбан.

55 Найза – сөңге төр.

белән чәнчештеләр. Көден хан Ак Көбекне йыда[56] белән үтәли чәнечте. Ак Көбек әйтте:

Чәнчүең дә бар икән-ай,
Күтәрүең дә юк икән-ай.

Көден хан Ак Көбекне йыда белән күтәрде, үз өстендә тотты, Йыданың очында әйтте Ак Көбек:

Күтәрүең да бар икән-ай,
Селтәвең дә юк икән-ай.

Көден хан йыдасын селтәгәч, Ак Көбек йыданың сабына каклыгып[57] елбышып[58] төшеп киләдер. Ул төшкәч кылычын сузды, Көден ханның башын кисеп ташлады. Көден хан әйтте: «Бүрегем йыгылды», – диде. Ак Көбек йыданы чыгарып ташлады. Кызыл Орына менде, өенә кайтты, Көден ханның кешеләре бер агач алды, муенның сөягенә тыгып куйдылар, ул агачка Көден ханның кискән башын пәкләделәр[59]. Көден хан тере булды, кайтты үз йортына. Көден ханның чирүенең тереләре кайтты, үлгәннәре калдылар.

Көбек ялгыз кайтты. Ак Көбек алтмыш алты яра белән чыкты, көн ярыгы[60] яраларга төшсә, топла[61] күренер иде, андай да булса, үлмәде. Кызыл Ор аты җитмеш яра белән чыкты. Ак Көбек төрле яхшы һөнәрле кеше иде; яралы булганга, ядыганын[62] бер агачка элеп салды, чиртергә көче юк иде.

Каен агачлар ботагы-лай
Сыгылса да сынмас булгай лай,
Исән булсам да, килермен-ай,
Төгәл[63] торсам да, алырмын-ай.

Аннан китте, камчы сабы белән иярнең кашына таянып, түшенә таянып, чак кына кайтып барадыр; бер җирдә имән агачка килде, аның ботагына кыцагын[64] элеп куйды:

Имәннәр агач ботагы-лай
Иелсә дә сынмас булгай-лай,
Исән булсам да, килгәймен-ай
Төгәл торсам да, алгаймын-ай.

56 Йыда – сөңге төр.
57 Каклыгу – ябышу.
58 Елбышу – шуу.
59 Пәкләү – ныгыту.
60 Көн ярыгы – кояш нуры.
61 Топла – үтәли.
62 Ядыган – чиртеп уйный торган кыллы музыка коралы.
63 Төгәл – исән-сау.
64 Кыцак – скрипка.

Аннан китте, барып-барып бер җиргә килде, бер уалган[65] арба анда ятыр, аның алдына килеп торды Ак Көбек.

Алтмыш алты кәгәйле[66] ай
Бу арба нидән уалган ай?
Җитмеш җиде кәгәйле ай
Бу арба нидән уалган.
Алтмыш алты ялары ай
Ак Көбек нидән үлмәгән ай?
Җитмеш җиде ялары ай
Кызыл Ор нидән үлмәгән ай?

Аннан камчысын алды, сукты, арба йөреп китте. Ак Көбек юлы белән китте, барып утырса, бер җирдә бер аккош үлгән, аның канат-йоннары җирдә ята, Ак Көбек аны күреп әйтте:

Алтмыш алты кавырсынлы-ай
Бу аккош нидән үлгәндер-ай?
Җитмеш җиде кавырсынлы-ай
Бу аккош нидән үлгәндер-ай?
Алтмыш алты ялары-ай
Бу Ак Көбек нидән үлмәгән-ай?
Җитмеш җиде ялары-ай
Кызыл Ор нидән үлмәгән-ай?

Аккошның йонына камчы белән сукты, ул аккош очып китте. Аннан Ак Көбек йортына кайтып китте. Үзенең шәһәренең юлына төште, шәһәренә якынлашты; юл кырында бер күл бар иде, анда кызлар, хатыннар йегән[67] тартып яталар. Ак Көбек йыдасын алды, йыда белән ул хатыннарның, кызларның күлмәген ыштанын ертып тартып алды; үзенең алтмыш алты ярасына, атының җитмеш җиде ярасына тутырды, җил тимәсен дип. Хатыннар, кызлар ялангач сыкташып калдылар. Ак Көбек юл белән акырынлап юыртып барыр иде. Хатыннар, кызлар аны күрде, Ак Көбеккә әйттеләр:

Алтмыш алты ялары-ай
Акылын куймас Ак Көбек-ай;
Җитмеш җиде ялары-ай
Холыгын куймас Ак Көбек-ай,
Яхшы җирем капцуг-ай[68],

65 Уалу – ватылу.
66 Кәгәй – киги, спица.
67 Йегән – камышның бер төре, аннан чыпта сукканнар.
68 Капцук– дошман.

Яман җирем япцугу[69]-ай
Анда салсаң Ак Көбек-ай
Анда салсаң Ак Көбек-ай.

Ак Көбек укмады, ыштанын-күлмәген салмады, барып китте. Йортына барды, шәһәрнең читендә күп кеше гүр ясадылар. Ак Көбек ул кешеләргә килде. «Бу кемнең гүрен казып ятсыннар?», – диде. Ул кешеләр әйттеләр: «Ак Көбек яралы килә, аның гүрен казып ятабыз», – диделәр. Ак Көбек әйтте: «Инде мин үләменме? Бу җирдә ятармынмы?». Ак Көбек саудагын гүргә төшерде, әйтте: «Чынлап та үләр булсам, төбенә төш! Терелсәм, тола төш». Саудагын салгач, куягын[70] да салды, түбәндә ятты саудагы-куягы. Ак Көбек аты белән гүргә керде, ятты, кешеләр аны күмделәр. Борын куркак агасы Солым яудан качып кайткан иде. Гүрнең янында торган Солым агасына Ак Көбек әйтте: «Көден хан йортында янә җиде йөз чирү җыеп, җиде йөз чирү белән тагын килер. Җиде йөз чирү белән Көден хан килгәндә миңа тавыш бирерсең!», – диде, «Анда мин торып чыгармын».

Инде күмеп ташладылар. Ак Көбек ике кунды, өч кунды күмгәч. Өч кунганда Ак Көбек гүрендә, Солым агасы аракы эчте, буза эчте, исерек булды. Солым агасы: «Ак Көбек үлгән булыр», – диде: «Үлгән кеше гүрдән чыгалмас», – диде, тереләренә ышанмады. «Үлгән кеше терелмәс кой», – диде, «Мин аңа барып, аны камчы белән сугаем!», – диде. Солым агасы бер атка менде, камчы алып гүргә китте, гүрнең катына барды. «Ак Көбек тор!» – диде. «Ни эшләп ятасың?», – диде. Гүренә камчы белән сукты. Һәр шайларын алып, атына менеп, гүрне ертып, Ак Көбек аты белән чыгып килде. Өч кабат чабып әйләнде чүлне, Көден ханның чирүен эзләп, һич кешене күрмәде. Кайтып килде Солым агасына. Ак Көбек әйтте: «Көден ханның явы кайда? Ни күренми?», – диде. Солым агасы әйтте: «Көден хан чирү белән килмәгән, мин үлгән кеше терелмәс дип сынамакка суктым иде», – диде. Ак Көбек әйтте: «Инде миннән соң үлгәннәр терелмәсен! Инде мин үләмен, минем яраларым сөгүлде[71], җиде кунарга толдырмадың[72]», – диде. Аннан гүренә аты белән кереп китте, үлеп калды.

## Әдәбият

Тизенгаузен В. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Т. I. Спб., 1884.

69 Япцук – яхшы.
70 Куяк – көбә күлмәк.
71 Сөгүлү – ачылу.
72 Толдыру – тутыру.

*Айзирәк Гәрәева-Акчура*

## ТӨРКИЯГӘ КҮЧЕНҮЛӘР

Бу язмамда 1966-нчы елны «Төрек күчмән һәм сыенучы җәмгыятьләре федерациясе» («Türk Göçmen ve Mülteci Dernekleri Federasyonu») тарафыннан Истанбулда нәшер ителгән «Төркиягә күченүләр» («Törkiye'ye göçler») китабы белән таныштырырга һәм 1970–1980-нче елларда татар мөһаҗирләренең бу оешма белән бәйләнешләре, җәмгыятьләре хакында мәгълүматлар белән уртаклашырга ният иттем. Китаптан татар мөһаҗирләренә кагылышлы кайбер өзекләрне Татарстан укучыларына да тәкъдим итәргә карар иттем.

Китапка керешкәнче, башта федерация хакында аңлатма бирү урынлы булыр.

1954-нче елда Истанбулда барлыкка килгән әлеге оешманы коручылар булып, Болгариядән күченгәннәр һәм кавказлылар санала. 1954-нче елгы сайлауларда җиңү яулаган Демократлар партиясе планлы рәвештә күчмән мәсьәләләрен кулга ала. Демократлар, җиңү белән рухланып, күчмәннәрнең Болгариядә калган малларына һәм туганнарына кагылышлы мәсьәләләре белән якыннан шөгыльләнәләр. Күчмәннәр тагын да оешкан рәвештә хәрәкәт итсен өчен Истанбулда Көнбатыш Тракия күчмәннәре ябык кооперативын коралар. Премьер-министр Аднан Мендерес мигрантларга кагылышлы сәясәткә үз карашын белдереп, «Төрек күчмән һәм сыенучы җәмгыятьләре федерациясе»нең мактаулы рәисе була. Шуны әйтергә кирәк, гомумән алганда, федерация корылуга һәм аның эшчәнлегенә карата Төркия мөһаҗирләре һәм сәясәтчеләре, шулай ук мигрантлар темасын өйрәнгән белгечләр, галимнәр төрле карашта. Мәсәлән, төрек телендәге фәнни-тарихи китапларда бу оешманың, нигездә, коммунистлар идеологиясенә каршы алып барылган сәясәт сәбәпле, дәүләт тарафыннан оештырылуы хакындагы фикер өстенлек итә. 1960-нчы еллар башында дәүләт тарафыннан финанслана башлавы, аннары чит илгә килгән мигрантларны борчыган төп сорауларны караудан, проблемаларын хәл итүдән читләшүләре, күбрәк алар килгән илләрдәге сәяси вәзгыять белән кызыксынулары шул турыда сөйли дип уйланыла.

Дөнья буйлап күченеп йөрүләр тукталмаса да, һәр заманнаның үз сәясәте дигәндәй, бүгенге көндә бу төр оешма инде гамәлдә түгел.

XX гасыр башында чит илгә килеп урнашкан мөһаҗир гаиләләрнең ярдәмгә ихтыяҗлары зур була: тормыш алып барырга, үз юлларын салырга, укырга, эш табарга кирәк... Төркиядә татар авыллары корган мөһаҗирләрнең яңа буынына – шәһәрләргә күченгән балаларына, оныкларына үз көннәрен үзләре күрергә, үз юлларын табарга вакыт җитә. Авыллар инде аларның эшкә, яшәү урынына бәйле ихтыяҗларын канәгатьләндереп бетерми. Алардан тыш Төркиягә яңа татар мөһаҗирләре, инкыйлабтан соң да, Бөек Ватан сугышыннан соң да килүен дәвам итә.

Иң беренче чиратта, мөгаен, ярдәмгә ихтыяҗлык Истанбул шәһәрендә 1955-нче елда оешкан татар мөһаҗирләренең «Идел-Урал төрекләре социаль ярдәм җәмгыяте»н 1960–1970-нче елларда федерация әгъзасы булырга этәргәндер.

Татарлар федерациянең Таксим бистәсендә урнашкан күпкатлы бинасында җәмгыятькә аерым бүлмә бирелүдән, федерация тарафыннан оештырылган төрки милләтләрнең күмәк чараларында катнашып, татар мәдәниятен тәкъдим итә алу мөмкинлегеннән азмы-күпме файда күрәләр. Мәсәлән, 1959-нчы елдан башлап уздырылган «Тунадан Алтайларга кадәр Бөек Фольклор тантанасы» («Tuna’dan Altaylara Büyük Folklor Şöleni») дип аталган фестивальгә татарлар бию күлмәкләренә кадәр үзләре тегеп әзерләнәләр һәм бик теләп катнашалар. Шулай итеп татар җырларын, биюләрен башкарып, милли хисләрен җанландырып торалар, мәдәниятләрен пропагандалыйлар.

Федерациягә әгъза булган вакытларда татарлар җәмгыятенә Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң Төркиягә килгән җәмәгать эшлеклесе Кәбир Канбир, Мәхмәт Акиф Идел, Мәхмәт Хулуси Акчура һәм башкалар җитәкчелек итә. 1980-нче елның сентябрь аенда Төркиядә хәрбиләр инкыйлаб ясыйлар. Инкыйлаб сәбәпле җәмгыятьләр эше туктатыла, шул исәптән татарларныкы да.

1982-нче елда Төркиянең яшь татарлары ябылган җәмгыятьне яңадан торгызыр өчен тырышып карыйлар. Һәм федерация урнашкан бинага баралар, татарларга бирелгән бүлмәне карыйлар. Бирелә Тукай бюстлары, диварларга эленгән карталар, китаплар, Төркиядә чыга торган «Казан» журналлары саклануын күрәләр. Әмма алып китеп урнаштырыр өчен урын булмау сәбәпле, бернигә дә кагылмыйлар. Тагын бер хәл аларны сагаерга мәҗбүр итә. Яшьләр башка бүлмәләргә дә керәләр һәм анда күргәннәре гаҗәпкә калдыра, ул бүлмәләрнең бүтән максатларда кулланылуын аңлагач, тизрәк бу бинадан чыгып китү ягын карыйлар.

Бинага керер өчен ачкыч биргән Көнбатыш Тракия төрекләре җәмгыяте җитәкчесенә вәзгыятьне аңлаталар һәм анда кабат барырга теләмәүләрен

җиткерәләр. Тракия төрекләре аларга үзләренең элек кибет өчен файдаланылган бер фатирларын тәкъдим итәләр. Шуннан соң татар яшьләре Истанбулның Фати районында урнашкан шул җиргә юл тоталар. Әмма фатир аларны бик ташландык, пычрак, җыештырылмаган хәлдә каршыйлый. Шуңа карамастан, яшьләр бергәләшеп аны тәртипкә кертәләр һәм биредә фольклор төркеме оештырып, үзләренчә җыр-биюләргә өйрәнәләр. Татар кичәләрендә, туйларда татарча җырлап-биеп йөриләр. Татар бию киемнәре аларга фестивальләрдә катнашучылардан мирас буларак калган була.

1986-нчы елда федерация оешуга 30 ел тулу тантанасы уздырыла. Шул вакытта 1970-нче елларда алып барылган хезмәттәшлекне хәтерләтү һәм хөрмәт белән искә алу йөзеннән, Мәхмәт Хулуси Акчура исеменә язылган «Төркия тышындагы төрки дөньяга хезмәтләрегез өчен рәхмәт хаты», аның туганнарына килеп ирешә.

Менә шушы мәгълүматлардан хәбардар булу федерация чыгарган «Төркиягә күченүләр» китабына карата аерым кызыксыну уятты. Китап авторы – Дагыстан мөһаҗирләреннән, журналист, язучы Кадырҗан (асыл исеме Абдулкадыйр) Кафлы (1899–1969). Ул 1954-нче елда корылган «Төрек күчмән һәм сыенучы җәмгыятьләре федерациясе»н оештыручыларның берсе. Беренче тапкыр 1957-нче елда, икенче тапкыр 1966-нчы елда аның җитәкчесе итеп сайланган.

Кулыма килеп кергән бу төрекчә басма, брошюра калынлыгында гына булса да, шактый эчтәлекле: Төркиягә Русиянең төрле төбәкләреннән, шул исәптән Идел-Урал буеннан килеп сыенган мөһаҗирләрнең кемлеге, хәле, саны турындагы һәм Төркиянең аларга карата карашы чагылган мәгълүматлар тупланган. Автор үзе китапны әзерләгәндә Әхмәт Җевад Эрен, Әхмәт Баттал, Исмаил Беркок, Наим Өктем һәм башка галимнәрнең хезмәтләре файдаланылуы турында искәртә. «Икенче тапкыр җитәкче итеп сайлангач, юкка чыккан өлкәләрдән Төркиягә, кайсы заманнарда, нинди сәбәпләр белән, ни кадәр күчмән килгәнен һәм кайларда урнашканнары турында белергә теләдем. Федерация архивында мондый мәглүматлар юк иде. Бу җитешсезлекне бетерер өчен шактый әсәрләрне өйрәндем, федерацияне тәшкил иткән җәмгыятьләрдән сорадым. Шул рәвешле бу кечкенә китапны мәйданга китердем», – дип, яза автор.

Китап Коръәни-Кәрим сүрәсе, хәдис һәм Төркия Җөмһүриятенә нигез салучы һәм аның беренче Президенты Мостафа Кемал Ататөрекнең: «Күчмәннәр югалган өлкәләребезнең милли хатирәләредер» дигән сүзләре белән ачыла. Иң беренче бүлектә төрле илләрдә яшәүче халыкларны мөһаҗирлек юлына этәргән сәбәпләрнең уртак булуы күрсәтелә. Алдагы бүлекләрдә төрле төбәктән килгән милләтләр турында аерым язылган. Төркестаннан, Кырымнан, Төньяк Кавказдан, Әзербайҗаннан, Румыни-

ядән, Булгарыстаннан, Югославиядән, Грециядән, Кыбрыстан һәм башка өлкәләрдән килүчеләрнең мөһаҗирлек тарихы кыскача аңлатыла.

Алга таба бүлекләрнең тәрҗемәсен тәкъдим итәм

### *Күчеш һәм сәбәпләре*

Күчеш инсанлар өчен үлем, хөрриятсезлек вә гариплектән кала, иң бөек һәләкәттер. Чөнки мөһаҗирләр йортларын, өйләрен, малларын, эшләрен югалтырлар, мөһаҗирлек юлында гомерләрен һәм яратканнарын югалтканнар да күп.

Күчеш сәбәпләре шулардыр:

1. Табигый һәләкәтләр йөзеннән күчәргә мәҗбүр булу.
2. Эшсезлек һәм халык саны арту сәбәпле, яшәр өчен башка җир эзләү мәҗбүриятендә калу.
3. Яшәү өчен тагын да яхшырак, уңайлы шартларның башка җирдә барлыгына ышану.
4. Яулап алган һәм бәреп кергән дошман басымында калу һәм үлем белән очрашу ихтималы.
5. Авырлыклар.

Бу сәбәпләрнең иң начары – дошман яулап алуы, золымы һәм дошман китергән кыенлыклар белән бәйлеседер. Төркиягә күченүләр һәрвакыт шул сәбәптән килеп чыккан.

Икенче Дөнья сугышында Германиядә эшләр өчен Франция, Голландия, Италия, Польша, Русия һәм Балтыйк мәмләкәтләреннән китерелгән 9 миллион эшче, сугыш ахырында, мөһаҗирләр хәленә төшәләр.

### *Идел-Уралдан күченүләр*

Идел-Урал дигәнебез Төрки өлкә, аеруча Волга һәм Урал елгалары арасында һәм тирәләрендә җирләре булган, XIII гасыр башларында Алтын Урда дәүләте монда корылган. Бу дәүләт өч гасыр милли берлеген дәвам иттерә, аерым-аерым яшәгән Рус принцларына хаким була, соңрак ханлыкларга аерыла. Рус принцлары исә берләшәләр, Русия Царьлык идарәсен кора, төрки халыклар өстеннән хакимлек итә башлый.

Руслар төркиләр кебек мәрхәмәт күрсәтмиләр, иң шайтанча һәм куркыныч сугыш ачалар. 1552 дә Казан, 1554 тә Әстерхан Русларның басып керүенә дучар була, Кырым ханлыгы ялгызы бәйсез кала.

Русия биредә руслаштыру, христианлаштыру хәрәкәтләрен җәелдерә, басым ясый. Милләтенә һәм диненә тугры төркиләрнең һәм татарларның берникадәре башка төрки өлкәләргә күченәләр.

1768–1774-нче елларда рус басымы һәм сөргеннәргә җибәрүләр арта, 50–60 мең арбалык бер Ногай кәрваны, Төркестанны кичеп, Җунгариягә китә. 70 меңгә кадәр качак татарлар, төркем-төркем булып, зур авырлы-

клар белән, ул вакытта әле төрекләр идарәсендә булган Кырымга күчәләр. Бу арада Анадолуга килгәннәр дә булгандыр. 1780–1800-нче еллар арасында әлеге күченүләр дәвам итә, күченгәннәр саны да 40 меңгә җиткән.

Һәр төрек-рус сугышы Идел-Уралда рус басымы артуына, төркиләрнең күченүләренә сәбәп. 1854 тә һәм аннан соңрак елларда, күченгәннәрнең саны 100 меңгә кадәр җитә. Кырым ханлыгы да руслар тарафыннан егылгач, 1883-нче елллардан соң күчеш азая, фәкать бу юлы Кырымнан качканнар Төркиягә киләләр.

Идел-Урал төркиләренең шактые Төркиядә Истанбул кебек зур шәһәрләргә җирләшәләр.

### *Төркиягә күчеп килгәннәрнең саны*

Алтын Урда дәүләтенең ахыры саналган 1554-нче елдан соң һәм 1750-нче еллардан бүгенгә кадәр Госманлы Императорлыгы югалткан җирләрдән Төркиягә күчеп килгәннәрнең саны миллионлар. Болар арасында, мәсәлән, Румыниядән Тунаның көньягына, аннан Тракияга, Тракиядән Анадолуга килер өчен берничә мәртәбә күченгәннәр. Кырым төрекләре һәм Төньяк Кавказия төркиләре Балканга күченгәннәр, бераздан Анадолуга күчәргә мәҗбүр булалар. Хәтта бер үк гаиләләрнең берничә тапкыр күчеш һәлакәтенә очраганнары күренә.

Күчмәннәрнең саннары, күп заманнар төп-төгәл итеп билгеләнмәгән, әмма фаразланган. Фәкать, бу фаразларда әйтелгән саннар күп түгел, бәлки аздыр.

1554-нче елдан 1966-нчы елга кадәр, бүгенге Төркия чикләре эчендәге җирләргә сыенган һәм җирләшкән мөһаҗирләрнең саны, килгән өлкәләренә күрә:

| | |
|---|---|
| Төркестан | 14 500 |
| Көнчыгыш Төркестан | 3 900 |
| Идел-Урал | 210 200 |
| Кырым | 691 000 |
| Төньяк Кавказ | 1 616 000 |
| Әзербайджан | 49 000 |
| Румыния | 270 000 |
| Булгарыстан (Болгария) | 1 270 000 |
| Югославия | 795 000 |
| Греция | 1 260 000 |
| Кыбрыс | 70 000 |
| Башка өлкәләр | 35 000 |
| | 6 284 000 |

Төркиянең 1965 тә халык саны 32 миллион тәшкил итә. Мөһаҗирләр исәбенә күрә, халыкның яртысы күчеп килүчеләр яки күчеп килүчеләр нәселеннән чыгуы шөбһәсез. Чөнки 1927 дә 13 миллион буларак ачыкланган халык санының яртысы иммигрант иде.

Бу күчемнәр гасырлар дәвамында Анадолу Империяторлыгын, төрек барлыгын һәм дәрәҗәсен саклау юлында корбан булган инсаннардан калган бушлыкны тутыра, мөһаҗирләр сыенган урыннарын югалтмас өчен, бигрәк тә, Истиклал (Бәйсезлек) сугышында зур фидакарьлекләр күрсәтәләр. Бүген дә Төркия үсешендә «инсан көче» диелгән иң кирәкле вә файдалы капиталның мөһим өлешен тәшкил итәләр.

* * *

***Бу бүлеккә ике искәрмә ясау урынлы булыр.***

Беренчедән, татар мөһаҗирләренең юлы да «күченү һәләкәтен» күп тапкырлар кичерүдән торган. Мәсәлән, башта Русиядән Сүриягә килгәннәр, Сүриядән Ушак шәһәренә барып, аннары Искешәһәргә килеп төпләнгән татарлар бар. Шулай ук, Русиядән Төркиянең Юзгат шәһәренә килгән, аннары Әфьюнга, соңыннан Искешәһәрдә төпләнеп калганнар була. II Бөтендөнья сугышы алдыннан килгәннәр юлы: Кытай – Япония – Истанбул – Анкара. Кайберләре мөһаҗирлекне дәвам итеп, Америкага күченәләр. Әмма мөһаҗирлек юнәлешләре болар белән генә чикләнми. Болгариядән, Румыниядән килүчеләр дә булган.



Татар яшьләре чыгыш ясый. 1984 ел. Төркия.

Икенчедән, Идел-Урал күчмәннәре саны күрсәтелгәндә, күрәсең, автор татарлардан тыш ногайларны да исәпкә кертә[1]. Чөнки, Идел-Урал күчмәннәре турындагы бүлектә Урал елгасын искә ала. Әлеге тарафлар ногайлар яшәгән җирләр.

* * *

***Күчмәнләр һәм дәүләт***

Төркиягә зур күчешләр башланган 1790-нчы еллардан 1860-нчы елларга кадәр дәүләтнең бу мөһим мәсьәлә белән кызыксынмавы аңлашыла торгандыр. Мәсәлән, Җәүдәт Паша үзе язган бик кыйммәтле 12 томлык тарихи китабында 1815-нче ел вакыйгаларын аңлатканда «иң мөһим мәсьәлә – күчеп килгәннәрне җирләштерү һич каралмаган»ны яза. 1860-нчы елга кадәр күчкәннәрне урнаштыру проблемасын чишү өчен, алар киткән илләрнең җитәкчеләренә әмер бирү белән канәгатьләнелгән, бу әмерләрнең күбесе кәгазьдә калган.

Садразам Али паша иң беренче мәртәбә бу мәсьәлә өчен мал бирә, Падишаһның уңай карашы белән 1860-нчы елның 5 гыйнварында Күчмән комиссиясе корыла. Европада моның кебек оешма XX гасырда, I Дөнья сугышыннан соңрак кына барлыкка килә.

1860-нчы елда корылган Күчмән комиссиясе 1864-нче елда Төньяк Кавказиядән, 1877 дә Балканнардан килгәннәргә җирләшер өчен зур хезмәтләр күрсәтсә дә, тәҗрибәсезлек аркасында, күчмәннәр урнашкан җирләрнең уңайсызлыгы, ярдәмнең азлыгы һәм акрын килүе сәбәпле зур югалтулар кичерелә.

Күчмәннәрнең хәлен яхшырту ниятеннән күпкә соңрак, 1878 дә, «Мөһаҗирләр гомуми идарә комиссиясе» төзелә. 1913-нче елда ул Эчке эшләр министрлыгына карый башлый һәм 1912–23-нче елларда зур файдалар күрсәтә. Бүгенге көндә бу эшләр Төзелеш һәм реконструкция министрлыгы вазыйфасына керә һәм тагын да нәтиҗәле алып барыла.

* * *

*Шушы урында китапта язылганнарны күзаллар өчен Төркиянең татар мөһаҗирләре яшәгән бер авылына кагылышлы мәгълүматларны өстисем килә.*

Искешәһәрдән 65 км ераклыкта урнашкан иске төрек авылы Икепынарга да безнең мөһаҗирләр килгән. 1894-нче елда Идел буеннан Госманлы дәүләтенә күчеп килгән Казан (Идел-Урал) татарларыннан

1 Редакция искәрмәсе: чынлыкта бу дөрес караш, чөнки тарихи чыганакларда без «нугай татарлары» дигән сүзләрне дә күрә алабыз.

36 гаиләле мөһаҗир Падишаһ фәрманы белән төрекләрнең Икепынар авылына урнаштырылган. Мөһаҗирләрнең бер өлеше, болай да бик фәкыйрь, кайберләре исә күчеп килә-килә бик мохтаҗ хәлгә төшкән. Дәүләт боларга ашарлык һәм чәчәрлек орлык белән берәр үгез бирергә дигән карар чыгарса да, ярдәм килеп җиткәнче айлар уза. Бу вакытта мөһаҗирләр Багдат тимер юлында эшләп, үз көннәрен үзләре күрергә тырышалар. Дәүләт биргән бодай да һәркемгә җитми, дүрт кеше ачлыктан үлә. Соңрак бу татарларга дәүләт тарафыннан 50 юрган бирелү каралган.

1910-нчы еллардан соң Икепынарга качак кырым татарлары килүе мәгълүм. 1920-нче елларда Күтәһия шәһәре янындагы Әфәнде күпере татар авылыннан кайбер гаиләләрнең килеп утыруы билгеле. Алар – Казан татарлары, Казан һәм Идел (Волга) буендагы җирләреннән 1900-нче елда Төркиягә күчәр өчен аерылып киткәннәр. Максатларын тормышка ашыру өчен Кырымның Бакчасарай шәһәрендә дүрт айга кадәр көтәләр. Аннары Истанбулга килеп җитәләр, ике ел Күтәһиядә калалар. 1903–1904-нче елларда Әфәнде күпере авылын коралар. Икепынар авылына Чифтәләр районына бәйле Османие (Корыһөек) татар авылыннан килгән аерым татарлар да була. Казан татарларының Икепынарда милли гореф-гадәтләрен озак заманнар саклап яшәүләрен, ат ите ашауны дәвам итүләрен искә алалар. 1960-нчы елларга кадәр Икепынарда 20гә кадәр татар гаиләсе яшәгән, бүгенге көндә биш гаилә бар.

* * *

Янәдән «Төркиягә күченүләр» китабына кайтыйк. Автор Төркиягә килгән мөһаҗирләргә башка чит илләрнең ярдәме федерация барлыкка килгәч кенә күрсәтелә башлавын яза. Һәм оешма тарихын түбәндәгечә сүрәтли:

«1954-нче елда Истанбулда корылды, үзәге Истанбулда. Коручылары: Әзербайджан, Туна һәм Балкан, Кырым, Төньяк Кавказ, Төркестан, Югославия күчмәннәре ярдәмләшмә җәмгыятьләре җитәкчеләре. Күпкә соңрак федерациягә «Идел-Урал төрекләре социаль ярдәм җәмгыяте» һәм «Көнчыгыш Төркестан күчмәннәре җәмгыяте» әгъза буларак керде».

К. Кафлы бер генә оешма – «Америка Католик чиркәүләре берлеге» башта Кызыл Ай аша, «аннары 9 елдан бирле федерация аша» булышлык күрсәтүенә басым ясый. Американнар ярдәме белән мохтаҗларга кием, ризык таратыла.

Бу ярдәм 1957-нче елдан башланган. Һәр ел 220 бавыл кием-салым, ун мең килодан артык азык-төлек: киемнәр елга бер тапкыр, ризык елга ике мәртәбә бирелгән. Мәсәлән, 1966-нчы елда бер тапкыр бирелгән азык-төлекләр шул кадәр:

100 капчык бодай оны – 5000 кило,

100 капчык бодай измәсе – 600 кило,

60 капчык талкан – 3000 кило,

100 савыт үсемлек мае – 1800 кило.

Федерация, мөһаҗирләр корган җәмгыятьләр һәм аларның әгъзалары бу төр ярдәмгә бик рәхмәтле».

Төрки күчмән җәмгыятьләре

Бу исемдәге бүлектә сүз 1960–1970-нче елларда Төркиядә гамәлдә булган җәмгыятьләр һәм аларның торышы хакында бара.

Мәгълүм вәзгыять, Төркиядә 1945-нче елга кадәр күчмәннәргә җәмгыятьләр корырга рөхсәт ителмәгән, рөхсәт ителгәннәр дә берәр сылтау белән ябылган. Кадырҗан Кафлы бу күренешне шушы рәвешле аңлата:

«Бу сылтаулар «Советлар илә дуслыгыбыз бозылыр, Югославия белән дуслыгыбызга аркылы килер» рәвешендәге түбәнчелекле хисләр белән тулган. Бу хәл күпкә соңрак та вакыт-вакыт дәвам итә. Мәсәлән, 1946-нчы елда Истанбулда кыбрыс төркилеген яшәтү өчен корылачак җәмгыятьнең исеме «Кыбрыс мәктәпләрендә җитешкәннәр җәмгыяте» рәвешендә кабул ителә, чөнки, мәсәлән, бу исем «Кыбрыслылар ярдәмләшмә җәмгыяте» булса, инглизләр хуш калмас һәм дуслык бозылыр, имештер».

Аннары автор җәмгыятьләр белән таныштыруын дәвам итә:

«Бүгенге көндә Төркиядә эшләүче мөһим күчмән җәмгыятьләре шулардыр (барлыкка килү еллары чиратында язылган):

1. Әзербайджанлылар ярдәмләшмә җәмгыяте (1945).
2. Көнбатыш Тракия күчмәннәре ярдәмләшмә җәмгыяте (1946).
3. Күчмәннәргә ярдәм җәмгыяте (1947 дә Туна һәм Балкан төрек күчмәннәре исеменә корылган).
4. Кыбрыс төрек культур җәмгыяте (1948).
5. Вардарлылар ярдәмләшмә җәмгыяте, Югославиядән килгәннәр оешмасы (1950).
6. Төньяк Кавказ төрек культур һәм ярдәмләшмә җәмгыяте (1951).
7. Кырым төрекләре ярдәмләшмә җәмгыяте (1952).
8. Төркестанлылар ярдәмләшмә җәмгыяте (1954).
9. «Идел-Урал төрекләре социаль ярдәм җәмгыяте» 1955 тә корыла. Коручылары Мәҗит Сакмар, Нуруллаһ Ата, Фикрет Алтан һәм башка 9 кеше. Үзәге Истанбулда.
10. Көнчытыш Төркестан күчмәннәре җәмгыяте (1960).

Күчмән җәмгыятьләре һич кенә дә сәясәт белән шөгыльләнмиләр, миллиятче, культур, ярдәмләшмә формасында калалар. Җәмгыятьләр канунына күрә эшлиләр. Башкарган эшләре:

– үзләре килгән төрки өлкәләрнең тарихын, географиясен, мәдәниятен таныту һәм яшәтү;
– күчмәннәргә акчалата, ризык, кием-салым, дару белән матди һәм дәвалау, укыту кебек мәгънәви ярдәм күрсәтү;
– китапханәләр кору, җыеннар, конференцияләр, чәй һәм бал кичәләре, фикер алышулар үткәрү, милли биюләр һәм музыкаларны күрсәтү;
– чит тел һәм башка белемнәрне өйрәнү өчен курслар ачу;
– яңа килгән күчмәннәрне каршы алып хәлләренә керү, яңа урынга җирләшүдә, эш табуда ярдәм күрсәтү.

Җәмгыятьләрнең күбесенең милли бию һәм спорт төркемнәре бар. Берникадәре журнал, китап нәшер итәләр, хыялларын тормышка ашырырга тырышалар, бик файдалы эшләр башкаралар».

* * *

Китапта федерация башкарган эшләр санап үтелгән аерым бүлек тә бар. Өч айга бер тапкыр «Төрек дөньясы» дип аталган фикер алышуга, культурага багышланган журнал чыгарылганлыгы әйтелә. Бу басма белән татарларның да кызыксынуы мәгълүм. Әлеге басманың беренче саны 1966-нчы елда дөнья күрә. Бу уңайдан профессор, доктор Әхмәт Тимер җитәкчелегендә чыккан «Төрек культурасы» («Türk kültürü») журналының 1966-нчы елгы июль санында журналист Наилә Бинаркның «Журналлар» дип аталган мәкаләсе басылган. Мәкаләдә: «Тарих буенча Кыбрыс утравы белән Балкан тауларыннан башлап, Көнчыгыш Төркестан һәм ерак Якутстанга кадәр булган киң географик кырларда 90 миллионга якын төрки җирләшеп яшәгән. Басып алынган җирләрдән качып килгән төркиләр Төркиягә сыенганнар... Һәр төрек җир йөзендә төрекләрнең кайларда яшәгәнен, санын, тарихын, әдәбиятын, сәнгатын, фольклорын, музыкасын өйрәнергә һәм өйрәтергә бурычлы. Федерация «Төрек дөньясы» журналын нәшер итеп, үз өстенә мөһим вазыйфа алган», – дип язылган, яңа басмага уңышлар теләнгән. Яңа журналның беренче санында 1966-нчы елда дөнья күргән Төрки телләр картасы да басылган.

* * *

Китапның иң ахырында автор тагын бер кабат мөһаҗирләрнең мөһимлегенә басым ясый һәм үзенең фикерләре белән китабын йомгаклый:

«Яңа Төркия корганнарның лидеры Мостафа Кемал Ататөрек 1931-нче елның 17 гыйнварында «Күчмәннәр юкка чыккан өлкәләребезнең милли хатирәләредер» дип, аларның кыйммәтен күрсәтте. Милли хатирәләргә хөрмәт күрсәтү – милли вазыйфадыр. Фәкать, шуны өсти-

сем килә, без, күчмәннәр, бары тик берәр милли хатирә түгелдер. Без ватанын сөйгән кардәшләр, милли барлыгыбызның бер кисәгедер, яулап алуларда һәм бозылышларда төркилек өчен зур фидакарьлек кылганнар, каһарманлык күрсәткәннәр яки аларның оныкларыдыр, дошман рәхимсезлегеннән газап чиккәннәр, якыннарын дошман өлкәләрдә калдырып китү ачысын күтәргәннәр, туган җирләрен сагыну уты белән йөрәкләре янганнардыр. Бабаларына, абыйларына, абзыйларына сыенган ватан ятимнәредер.

Күчмәннәр – Бәйсезлек сугышыннан соң йончыган ун миллионлык Төркиянең куәтле, эшлекле, иманлы, культуралы, бай, алдынгы һәм көчле 32 миллионлык Төркиягә әйләнүендә зур өлешләре булган газиз кардәшләребездер.

Кайгыртылган, йорт һәм эш белән тәэмин ителгән, үсешкә ирешкән һәр мигрант – кырык-илле елдан соң бик яхшы, файдалы милли байлык һәм милли куәт чыганагы, шулай ук милли идеягә ия һәм милләт сакчысына әверелгән биш-ун ватандаш».

Әлеге сүзләрнең ни дәрәҗәдә хак әйтелгәнен, тормышка ашуын Төркиядә яшәүче мөһаҗирләр бүгенге көндә ачык күрсәтә.

## Әдәбият


1. Aleksander Toumarkine. Türkiye›de Sivil Toplum ve Milliyetçilik. İstanbul: İletişim Yayınları, 2001. 616 s.
2. Kadırcan Kaflı. «Törkiye’ye göçler». İstanbul: Çelit Matbacılık Koll.Şti., 1966. 47 s.
3. Hakan Kırımlı. Türkiyedeki kırım tatar ve Nogay köy yerleşimleri. İstanbul: G.M.Matbacılık ve Ticaret A.Ş., 2012. 654 s.
4. Türk Kültürü. IV. Ankara: Ayyıldız Matbası, 1965–1966. 1152 s.

## Шәхесләребез

## Известные личности

*З.А. Тычинских*

# КРАЕВЕД, ПОДВИЖНИК. СЛОВО О ГУЛЬСИНЕ ГАЗИЗОВОЙ

Гульсина Ахматулловна Газизова (1952 г. р.) родилась и выросла в с. Сингуль Ялуторовского района Тюменской области. Закончив Яровскую 8-летнюю школу, она поступила в Омский индустриально-педагогический техникум, который окончила в 1975 г. Трудовая деятельность Гульсины Ахматулловны началась в Яровской школе Ялуторовского района, где она работала учителем черчения и рисования, воспитателем в интернате. В 1980 г. семья Газизовых переезжает в г. Урай Ханты-Мансийского автономного округа, где до августа 1994 г. Гульсина Ахматулловна жила и работала. Вернувшись в с. Сингуль, она прошла курсы повышения квалификации в Тюменском областном государственном институте развития регионального образования и в последующие годы работала учителем русского языка и литературы в Сингульской средней школе.



В течение многих лет Г.А. Газизова вела активную краеведческую деятельность, организовала кружок «Возрождение» при школьном музее, где вместе с детьми занималась изучением истории родного села. За время её работы в школьном музее была восстановлена история села Сингуль начиная с конца XIX в., собраны материалы по истории школы и сельской библиотеки. За этот период ею были собраны уникальные материалы, которые вошли в книги: «Ялуторовский район: этапы большого пути», «Татары земли Тюменской», трехтомник «Эхо войны», «Ялуторовск в годы Великой Отечественной войны» и др.

Древняя Сингульская земля богата историей, поэтому на территории озера Сингуль многие годы проводились археологические исследования под руководством тюменского археолога, профессора А.А. Ткачева. Сингульские школьники во главе с Г.А. Газизовой принимали активное участие в археологических раскопках. Многие предметы, найденные Гульсиной Ахматулловной и ее учениками (среди которых наконечники стрел, датируемые I тыс. до н.э., бронзовый нож, фрагменты орнаментированной керамики, медные монеты XVIII–XIX вв.), сейчас экспонируются в школьном музее. Эти предметы свидетельствуют о давности освоения людьми берегов прекрасного о.Сингуль и о том, что места эти были заселены в течение многих столетий.

С августа 1998 г. Г.А. Газизова стала работать в сельской библиотеке, выдавая книги односельчанам и жителям соседней деревни Русский Сингуль. Проводила она вечера отдыха «Аулак өй», «Бабушкин сундук» и т.д. Но краеведческая работа, которую вела Гульсина апа, не прерывалась. «В 1972 г. в селе был установлен памятник участникам Великой Отечественной войны, не вернувшимся с фронта. А в мае 2005 г. ко мне обратилась вдова участника ВОВ Алиуллина Мидхат абыя с вопросом: Почему нет списка солдат, вернувшихся с Победой? Дала ей слово, что установим в скором времени», – вспоминает Г.А. Газизова. Ее слово не разошлось с делом. Гульсина апа организовала сбор средств на установку памятника, вела поиск информации. 10 октября 2010 г. состоялось открытие этого памятника, на котором золотыми буквами высечены имена 63 жителей с. Сингуль, вернувшихся с победой с фронтов ВОВ.

В Сибири, как и во многих других уголках России, стремительно исчезают села и деревни. Молодежь уезжает в города, многие переезжают в крупные села. Поэтому на месте многих, всего лишь несколько десятилетий назад стоявших старинных сел, где веками жили люди, кипела жизнь, сегодня – поля и пустыри. Уроженцы этих сел не хотят, чтобы память о малой родине стерлась с лица земли и ставят на этом месте памятные знаки. Большую работу по сохранению памяти проводит и Г.А. Газизова.

В 15 км от с. Сингуль находилась д. Корсаки, которой сейчас уже нет. В 2008 г. Гульсина Ахматулловна восстановила историю д. Корсаки и в том же году 12 июля на средства, собранные от бывших жителей д. Корсак и жителей с. Сингуль, была установлена стела: «Стояла здесь моя деревня, колыбель моя Корсаки – Тэрсэк». В сентябре 2016 г. стараниями Гульсины апы и ее односельчан была установлена стела на месте д. Муслим, находившейся в 5 км от д. Сингуль. Как говорит Г.А. Газизова, «Рада, что в жизни установила 3 стелы на радость жителям и себе, что причастна немного к истории этих деревень».

В 2012 г. Г.А. Газизова совместно с сотрудниками школы д. Сингуль и работниками станции туристов в г.Ялуторовске начала кропотливую работу по проекту «Стена памяти». Баннеры с фотографиями односельчан – участников ВОВ и тружеников тыла, ежегодно выставляются ко Дню Победы на площади Суворова в г. Ялуторовске. А в 2014 г. на праздник села баннеры были привезены Гульсиной Ахматулловной в Сингуль. На сегодняшний день собрано 230 фотографий, но работа продолжается.

Ниже приводится рассказ Г.А. Газизовой о д. Корсаки Ялуторовского района.

## СУДЬБА АУЛА КОРСАКИ

Д. Корсаки находилась в 30 км о г. Ялуторовска. Она стояла вдалеке от больших дорог. Люди, живущие в ауле, занимались земледелием и скотоводством. Природа, окружающая деревню, чрезвычайно красива и богата, в лесу много ягод и грибов, в реке – рыбы. Рядом с деревней протекала речка Змейка. Она не отличалась глубиной и шириной, вода в ней всегда чистая, водятся гальяны и караси, у берегов растут камыши и цветут белые лилии.

История не сохранила до нас имена основателей и первых жителей этой деревни. Однако, по версии старожилов д. Сингуль и д. Корсаки возникли в середине XVIII в. Первым в деревне добротный дом построил Усманов Салим, у которого были два сына и дочь. Салим смог выкупить пахотные земли и луг у соседей староверов с. Слобода-Бешкиль. В конце XVIII в. и в начале XIX в. очень много было в Корсаках переселенцев из «Татарии». Одним из них был Насибуллин Алиулла. Со своим сыном Газизуллой он работал на строительстве железной дороги в г.Ялуторовске. Алиулла абый был хорошим рассказчиком, знал много сказок и былин. Вечерами он собирал у себя детей и часами рассказывал им древние предания. Так передавалась народная мудрость от старшего поколения следующему.

В ауле была построена мечеть, в которой мулла обучал детей Корану и основам ислама. Обучение проходило на арабском языке. Кроме религиозных дисциплин, учеников обучали математике и письму. Для общего

развития и нравственного воспитания в школе (мектеб) большое значение имели произведения древних писателей. Одним из главных учебников в мектебе была поэма Кул-Али «Кыйссаи-Юсуф» («Сказание о Юсуфе»), которая относится к XIII в. Такие книги как «Таһир һәм Зөһрә», «Кызыл алма» («Красное яблоко») и другие, читающиеся напевом, в мектебе и медресе знали наизусть и их сюжеты передавались из уст в уста. Это были художественные произведения полусветского содержания, в которых описывались жизнь, быт и практическая мудрость людей той эпохи.

В 1930 г. мечеть закрыли. Здание мечети отдали под школу. Первой учительницей в новой советской школе была Давлетгараева-Исмагилова Бибинур Мухамедьяровна. В 1935 г. школу на несколько лет закрыли. Вновь она открылась только перед войной. В ауле дети учились до 5-го класса. Учителями работали Х.М. Исмагилова, А.Р. Фаткуллина, З.М. Амирова, Н.Амиров, Ф. Алиуллина, М. Саитова. С 1947 по 1955 гг. заведующей Корсаковской школы была С.Н. Халидуллина. Под ее руководством в 1949 г. построили новую школу. Она состояла из двух комнат и коридора. В следующем году вокруг школы учителями и учениками были посажены акации.

Школа может гордиться своими учениками. Среди лучших выпускников Корсаковской школы М.А. Мулюков, политик, кандидат исторических наук, доцент Казанского государственного университета, народный депутат РТ, один из создателей Татарского общественного центра и его первый руководитель.

В 1932 г. в Корсаках был организован колхоз «Авангард». Председателем единогласно был избран Б.А. Фатхуллин, который отличался умом и крепкой крестьянской хваткой. Недаром на этом посту он бессменно проработал до 1951 г. За колхозом были закреплены два трактора. При МТС обучили своих трактористов. С первых лет дела в колхозе пошли в гору. Годы были урожайными, хлеба после сдачи государству хватало всем до следующего урожая. Начали строить дома. Дома строили всем селом. Этот обычай у татар называется «өмә». За работу не платили, а хорошо кормили. Мясо варили в больших казанах прямо на улице. Готовили домашнее пиво из ржаного солода. Долгое время в ауле не было магазина. Когда-то была лавка богача Шамиля. Продукты закупали в Сингуле и в Ялуторовске. В довоенный период не было клуба. Молодежь вечерами собиралась на улице, устраивала разные игры, пели и плясали под игру гармонистов. Все большие праздники отмечали в школе. В то время позором считалось появление на улице в нетрезвом виде.

В летнее время люди работали от зари до зари. Но, несмотря на тяжелейшие условия труда, колхозники находили время и силы для веселья.

Так бы и жили люди, поднимая свой колхоз, улучшая жизнь, если бы не началась самая кровавая в истории Великая Отечественная война. Аул быстро опустел. Всех мужчин, способных держать оружие, призвали и отправили на фронт. Корсаковцы сражались на всех фронтах. Легендарный Ленинград защищали М.К.Алиуллин, Ш.Зиганшин. Пали смертью храбрых братья Ахметзия, Ахметхан, Таир, Хусаин, Айнулла Халиуллины, Гайса Алиуллин, Ахмед, Айтмухамет, Нурмухамет и Самигулла Валиевы, Нурмукамин и Ахметкарим Абдрашитовы, Дильмухамед Яруков и др.

Зимой из осажденного Ленинграда в Ялуторовск привезли женщин с детьми. Председатель колхоза Бикмухамет Альмухаметович, узнав об этом, снарядил шесть подвод, чтобы привезти ленинградцев домой в аул. После отхода подвод женщины и дети занялись подготовкой домов для встречи. Протопили бани, приготовили еду. Встречать гостей вышел весь аул. Благодаря общению, татарские дети начали говорить по-русски, а ленинградцы понимать татарский язык. После войны ленинградцы вернулись в родной город.

Закончилась война и жизнь в деревне начала налаживаться. Решением райисполкома №109 от 16 февраля 1951г. были объединены колхозы «Урал», «Авангард», «им.Чкалова» Сингульского с/совета в один колхоз «Имени Чкалова». Шли годы, деревня росла, строились новые дома и здания, появилась водозаборная башня, клуб, магазин. По переписи 1970г. в Корсаках проживало 119 человек. К большому сожалению, славные трудовые и житейские традиции корсаковцев не нашли развития в дальнейшей истории деревни. Ликвидация деревни шла по отработанному сценарию: в 1975г. отключили электроэнергию, закрыли школу, магазин, угнали скот. Последней покинула аул семья А.А.Тимергалиева, деревня прекратило свое существование в сентябре 1977г.

Много воды утекло с той поры в Змейке. Однако вечен кругооборот в природе, ничто не исчезает в ней бесследно. Корсаковцы бережно хранят память о родной деревне. Как уже говорилось, в июле 2008г. на средства, собранные от бывших жителей д.Корсаки и жителей с.Сингуль, была установлена стела в память о том, что здесь была д.Корсаки.

*Рәшид Маликов*

# ТАНЫЛГАН ИШАН ӘХМӘР ХӘЗРӘТ ЮНЫСНЫ (1765–1819) ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕНДӘГЕ ЧЫГЫШ

*Буа районы Толымбай авылы,*
*25 январь 2019 ел*

Әссәләмүгаләйкүм хөрмәтле дин кардәшләр, милләттәшләр, җыелган кунаклар! Барыгызны да тәбриклим шушы тарихи матур чарада катнашуыгыз белән. Зур рәхмәт оештыручыларга!

Чыгышымны бер сораудан башлыйсым килә.

Сорау: Нинди кешеләрнең исеме тарихта сакланып калган?

Җавап:

1) Тарихи вакыйгаларга сәбәпче кешеләр. Мәсәлән: ил җитәкчеләре.
2) Галимнәр. Кешеләр тормышына файдалы фәнни ачышлар ясаган, күп файдалы гыйлем биргән, укыткан, кешеләргә туры юлны күрсәткән, яхшы китаплар язып калдырган.
3) Күп изгелек кылган кешләр**.** Ятим, мескен, мохтаҗларга булышкан, кешеләрнең тормышларын яхшырткан, күп файда китергәннәр. Мәсәлән, юллар, күперләр салдырган, мәктәп-мәдрәсә, уку йортлары, шифаханәләр ачкан, эш урыннары булдырган, кешеләргә дә хайваннарга, табигатькә файдалы кешеләр.
4) Аллаһка якын булган, камиллеккә ирешкән кешеләр**.** Боларга керә пәйгамбәрләр, алар артыннан ияргән изге бәндәләр.

Татар халкы тарихында изге кешеләр күп булган. 100–200 ел элек яшәгән мәшһүрләреннән: Чистайда Закир ишан Камалов, Троицкийда Зәйнулла ишан Рәсулев, Казанда шәех Галимҗан Баруди, Габдессаттар ишан Худжаев, Гали ишан Таһиров, Ор авылында Хәбибулла ишан Оруви, Түнтәр авылында Гали ишан Түнтәри, Кизләү авылында Мәхмүд, Хәсәнҗан ишан Гөбәйдуллиннар, Иске Кулаткада Хабибулла ишан ***Хәнсәваров,*** Буа ишаннары: Габделвәхид хәзрәт Габдрахман, Габденнасыр хәзрәт Мөхәммәтәмин, Нургали хәзрәт Хәсән, Габдулла хәзрәт Гобәйдуллин, Норлат авылында Фәхретдин ишан Мостаев, Үгез Куагы авылында хаҗи Мөхәммәд Габделкасыйм, Суксу авылында Шәрәфетдин ишан Суксуви, Олы Тархан авылында Нуретдин ишан Мустаев, Карлы авылында Гобәйдулла ишан Рәхмәтуллин, Толымбай авылында Әхмәр ишан Юнысов һәм башка бик күпләрне әйтеп үтә алабыз.

Бу кешеләр дин галимнәреннән шул ягы белән аерыла: галимнәр һәр нәрсәнең тышкы ягын белсәләр, бу кешеләр тышкысын һәм эчкесен,

ягъни, мәсъәләнең бөтен якларын беләләр. Мондый Аллаһка якын кешеләрне икенче төрле гарифләр – хакыйкатьне эзләүчеләр, хакыйкатьне табучылар диләр. Гади сүз белән әйткәндә «изге кешеләр, рухи остазлар, ишаннар», – дип атыйлар.

Шундый изге кешеләр рәтендә булыр өчен кешегә үзе өстендә бик күп эшләргә кирәк. Мондый зур рухи дәрәҗәгә ирешер өчен:

1) Камиллеккә ирешкән, Аллаһка якын булган рухи чын остаз табарга, аның укучысы булырга һәм аның әйткәннәрен үтәргә;
2) Гыйлем алырга, күп укырга, дини гыйлемне һәм үз һөнәреңне яхшы белергә;
3) Бөтен гөнаһлардан, кеше, хайван рәнҗетүләрдән, табигатькә зыян китерүдән сакланырга;
4) Хәләл, чиста рыйзык ашарга. Үз үзеңне, гаиләңне тәэмин итәргә, кеше хисабына яшәмәскә;
5) Аллаһны күп искә алырга, аны мактарга, рәхмәтле булырга, төрле өстәмә дини гыйбадәтләр кылырга;
6) Кимчелекләрне, начар гадәтләрне бетерергә, нәфсегә хуҗа булырга өйрәнергә;
7) Аллаһ рыйзалыгы өчен күп изгелекләр кылырга, кешеләргә ярдәм итәргә, кулың, телең, малың белән аларга гел файда китерергә.

Бу эшләрне даими эшләгән кеше әкеренләп Аллаһка якыная. Аңа Аллаһ рухын ныгытыр өчен төрле сынаулар, авырлыклар бирә. Шуларны үтеп ул тагын да чистара, ахыр чиктә, рухи остазы ярдәмендә, үз тырышлыгы белән рухи камиллеккә ирешә. Андый кешенең күңелендә бары Аллаһ, Аны һәм аның барлыкларын ярату була. Ул кешедә мактану, көнчелек, тәкәбберлек, рия, ялкаулык сыйфатлары булмый. Аңа җирдә яткан алтын, балчык белән бер була. Дөнья малы, дан, шөһрәт һич кызыктырмый. Бары Аллаһ һәм Аның ризалыгы аның асыл максаты була [Хаттар: 1999. С. 281; Чиркави: 2006. С. 219; Али-заде: 2007. С. 258 ].

Аллаһ Үзенә якын булган кешеләренә күп нигъмәтләрен бирә. Аларның догалары тиз кабул була, кешеләрне дәвалау сәләте ачыла, вакыйгаларны алдан күрү, кешенең эчке дөньясын белү, хакыйкәтне күрә алу сыйфатлары барлыкка килә. Бу кеше инде тулысынча Аллаһның рәхмәте, ризалыгы өчен кешелек дөньясына, кешеләрнең бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле булуы өчен хезмәт итә. Ул гыйлем бирә, дәвалый, дөрес киңәшләрен бирә, тәрбияли, акчасы белән булыша, шул изге юлда бөтен көчен куя, гомерен багышлый.

Мондый кешеләр караңгы төндә бер шәм, фонарь кебек. Алар янына бик күп кешеләр килә, көч ала, тәрбияләнә, яхшыга үзгәрә. Гомер гомер-

гә андый кешеләрне халык бик яраткан, хөрмәт иткән, хәерле догасын алырга тырышкан. Үлгәч тә андый кешеләрнең каберләрен караганнар, барып догалар кылганнар һәм һич онытмаганнар. Менә шундый кешеләрдән булган Буа районы Толымбай авылында 200 ел элек яшәгән ишан Әхмәр хәзрәт Юныс (1763–1819)[1].

Менә бу камилләшү юлы Ислам динендә суфыйчылык, тәсауф, тарикать юлы дип атала. Ул традицион Ислам диненең аерылгысыз өлеше. Гади мөселманнар диннең шәригать өлешен үти, ягъни намаз укый, ураза тота, хәрамнан саклана, изгелекләр кылырга тырыша. Ә инде кем Аллаһка тагын да якын булырга тели, бөтен кимчелекләреннән пакъланып, Аллаһның яраткан бәндәсе булырга ниятли, ул инде Ислам диненең тарикать, суфыйчылык юлына да баса.

Суфыйчылык юлында камилләшкән, Аллаһка якын булган кешеләр, ишаннар, белгечләрдә, миссионерларда зур кызыксыну уяткан. Бу хакта алар төрле аңлатмалар язып калдырганнар. Шуларның берничәсен карап үтик. Мәсәлән, танылган этнограф Н.П. Штейнфельд татарлардагы ишаннар хакында аңлатып, болай яза: «Отличающееся среди своих коллег особенным благочестием, безупречной справедливостью, ученостью, а также благотворительными делами, муллы получают от прихожан название «ишан», которое в переводе близко подходит к смыслу слова «угодник». Такие лица пользуются необыкновенным почетом и нравственным значением. К ним за советом и поучением идут совершенно чужие люди издалека. Об одном недавно умершем ишане рассказывают, что он не только давал весьма замечательные по своей мудрости наставления, но случалось, что, даже не спросив еще, по какому делу к нему пришли, сам вперед уже предугадывая вопрос, говорил просителю именно то, о чем тот хотел получить от ишана совет или указание. Ишан обладал, по-видимому, несомнительным талантом гипнотизера. Он умел угадывать некоторые мысли и этим даром, разумеется, совершенно поражал своих простодушных прихожан. Ко всему этому надо добавить, что он был богат, но далеко не скуп: благотворительность его славилась в целом околотке, а после смерти он из значительного своего состояния не оставлял наследникам почти ничего, так как все средства ушли на помощь ближнему. На свой счет он выстроил медресе и много помогал деньгами и хлебом бедным. Понятное дело, что после смерти его осталась глубокая память в народе и имя ишана теперь чтится, как святого» [Штейнфельд: 1893. С. 277].

1 Әхмәр хәзрәт Юныс Буа районы Толымбай авылында туган. Үз авылында, Оренбург өлкәсе Каргалы бистәсендә һәм Бохарада дини гыйлем алган. Туган авылында имам булып, мәдрәсә ачып, гыйлем биреп, мөридләр тәрбияләп, халыкны дәвалап, төрлечә ярдәм итеп яшәгән күренекле шәхес була. Кабере авыл зиратында

Танылган урыс православ миссионеры Н.И.Ильминский ишаннар хакында болай ди: «Эти люди соблюдают себя в постоянной чистоте, совершают непрерывные омовения, удаляются от сомнительных яств (еды) и поступков. Думают через некоторые особые [религиозные] практики состоять в ближайшем общении с Божеством» [Материалы: 2015. С.106.]. Ильминский шулай ук дәвам итеп әйтә: «Ученые профессора [не ишаны] преимущественно занимают своих учеников логикой и философией, а ишаны более обращают внимание на положительные уставы веры и практики. Стараются развивать в своих учениках не сколько дух учености, сколько строгое правоверие и строгую праведность» [Материалы: 2015. С.106.].

Демократ-разночинец П.И.Пашино татар муллаларын 12 категориягә бүлеп тасвирлый. Шулар арасында «Муллы-ишаны» дип аерым алар хакында мондый аңлатма бирә: «Эти люди были суфийскими наставниками, влияние которых на население было огромным. Они были далеки он интриг, сплетен, поисков новостей. Вели однообразную целомудренную жизнь, строго исполняли все религиозные предписания и нравственные постулаты. Каждый ишан имел медресе с большим числом учеников, которые старались подражать ему, даже, например, в одежде. Служебные обязанности выполняли тщательно, в их приходах население было очень религиозным, дружным, с хорошей нравственностью. В деревне, где они жили, невозможно было найти пьяных. Они много получали милостыни и подарков, в тоже время сами активно занимались благотворительностью, особенно помогали погорельцам, шакирдам. Их молитвы читались исцеляющими. С близкостоящим начальством ишаны были хорошо знакомы, каждый год они им давали подарки» [Шин[Пашино]: 1860. Т.81. С.274–284].

П.И.Пашино шулай ук ишаннарның Ислам динен тарату өчен күп хезмәт итүләрен, бигрәк тә чукындырылган татарлар һәм күршедә яшәгән урыс булмаган халыкларны дингә чакыруда актив булуларын ассызыклый. Фикерен дәвам итеп, ул болай ди: «Рядом с ишанами всегда находились их наместники – близкие ученики, которым он передавал свои обязанности. После смерти за праведную жизнь население причисляло их к лику святых (аулия) и их могилы всегда посещались и были почитаемыми. Среди них встречались и мошенники, то есть не настоящие ишаны» [Шин[Пашино]: 1860. Т.81.С.274–284].

Югарыда әйтелгән фикерләрдән аңлашылганча, чын камиллеккә ирешкән рухи остазлар, ишаннарның татар халкында дәрәҗәләре бик югары булган. Аларга карап кайбер кешеләр үзләре өстендә эшләмичә генә, «Мин шәйх, мин ишан», – дип үз-үзләрен атаган ялганчы ишаннар да очраган. Халык андый кешеләрне «Суган суфые» диеп йөрткән. Билгеле, бу кешеләрнең максаты Аллаһ ризалыгы өчен, кешеләрнең

бәхетле булуы өчен тырышу түгел, ә байлык туплау, дан, шөһрәт казанып яшәү булган. Шуңа да алар бу юлда төрле гөнаһлар да эшләгәннәр. Халык аларны яратмаган, күп тәнкыйть иткән. Бу ялганчы ишаннарны чагыштырып була укымыйча, үз өстендә эшләмичә, ялган юл белән табип (врач) дипломын алып, кешләр дәвалап йөргән шәхес белән. Билгеле мондый шарлатаннар кешеләрне дәвалый алмый, җәмгыятькә файда китерә алмый, хәттә зыянлы да булырга мөмкин. Ялгышып, белмичә аз кешеләр генә алар янына барган. Кем икәннәре тиз билгеле булгач, халык арасында начар исемнәре таралган, Кешеләр аларга барудан сакланганнар һәм гомумән исемнәре дә халык хәтерендә, тарихта калмаган.

1917-нче елны илдә Совет хөкүмәте урнашкач, ОГПУ хезмәткәрләре мөселман халыкларында динне бетерер өчен, иң беренче ишаннарны юк иткән. Халыкны алардан ерагайтыр өчен «Зәңгәр шәл» кебек спектакльләр күрсәтеп, газета-журналлар, китаплар аша аларны төрлечә мыскыл иткәннәр. Инде исән калган 5–6 ишан бик көчле күзәтү астында торганнар. 1980-нче елларда алар картаеп, бу дөньядан киткәннәр, укучылары-мөридләре дә калмаган, электән килгән суфыйчылык чылбыры өзелгән. Шулай итеп, татарларда суфыйчылык юлында камилләшкән ишаннар, рухи остазлар калмаган. Ә Урта Азия, Дагъстан якларында алар азмы-күпме бүгенгәчә сакланган [Миннуллин: 2006. С. 165; Миннуллин, Минвалеев: 2007. С. 250].

Совет хөкүмәте беткәч, 1990-нчы елларда Россиядә дингә ирек бирелде. Халык дин белән кызыксына, тота башлады. Әмма дин өлкәсендә белгечләр, китаплар әле юк иде. Россиягә Согуд Гарәбстаны, Катар кебек илләр аша ваххабизм дигән дини юнәлеш килеп керде. Бу чын булган традицион Ислам диненнән аермалы буларак, 200 ел элек ясалган аерым бер идеология, секта иде. Моңа ялгышып иярүчеләр дәүләтне сүгә, милли мәдәнияткә, гореф-гадәтләргә каршы чыга, изгеләр юк, суфыйчылык ялган, без генә дөрес юлда, калганнар адашкан, җәһәннәмдә дип сөйли, үзләрен бик әхлаксыз тоталар. Нәтиҗәдә шактый халкыбыз нәфрәтләнеп 1000 елдан артык әби-бабайларыбыздан килгән Ислам диненә, туры юлга баса алмыйча калды.

Аллага шөкер, соңгы елларда дәүләт Чечня, Сүриядәге сугышлар, ил эчендәге террор актлары сәбәпле ваххабизмның зур куркыныч икәнлеген аңлап, традицион Исламга юнәлеш алды. Бүгенге көндә суфыйчылык белән кызыксыну артты, чөнки Россиядә бөтен мөселман халыклары гомер-гомергә суфыйчылык белән тәрбияләнгән һәм башка халыклар, диннәр белән тату яшәгән [Якупов: 2003. С. 6.].

Чыгышымны йомгаклап шуны әйтәсе килә.

Толымбай авылында яшәгән ишан Әхмәр хәзрәт Юныска бәйле халык хәтерендә бик күп вакыйгалар, гыйбрәтле хәлләр саклана. Үзем белгән-

нәрдән ике мисал сөйләп үтәсем килә. 1995-нче елны Буа районында бик коры җәй килде. Халык яңгырга тилмерде. Ул вакытта Буада Камил хәзрәт Бикмөхәммәтов (1922–2000) дигән бик хөрмәтле кеше бар иде. Ул «Габделмалик» исемендәге мәчетнең имамы һәм Казанның соңгы ишаны Гарифулла хәзрәт Гайнуллинның (1894–1984) мөриде булган. Район җитәкчесе Габделхай Нәбиулла улы Хәйруллов өйлә намазына мәчеткә килеп: «Хәзрәт яңгыр кирәк бит, бөтен нәрсә кибә», – дип мөрәҗәгать итә. Хәзрәт аңардан машина сорый. Икенче көнне иртән Камил хәзрәт берничә мәчет картлары белән Толымбай авылында күмелгән Әхмәр хәзрәт Юныс, Норлат авылында – Фәхретдин ишан Мостаев, Үгез Куагы авылында хаҗи Мөхәммәд Габделкасыйм, Буадагы Габделвахид хәзрәт Габдрахман, Габденнасыр хәзрәт Мөхәммәтәминов, Нургали хәзрәт Хәсәнов, Габдулла хәзрәт Гобәйдуллин һәм башка танылган ишаннарның каберләренә барып алар рухларына Ясин һәм башка Коръән аятләре укыйлар. «Раббым күрәсең, хәлләребез авыр, шушы изге бәндәләрең хөрмәтенә шифалы яңгырларыңны яудырсаң иде», – диеп Аллаһтан дога кылып сорыйлар.

Нәтиҗәдә өйләдән соң күктә болытлар җыелып, кич яңгыр ява башлый. Яңгырлар берничә көн туктамый ява. Район җитәкчесе Камил хәзрәт янына яңадан килеп: «Хәзрәт яңгырлар артык күп ява, зыянга китте. Аллаһтан дога кылып сорагыз әле, туктатсын иде», – ди. Шуннан соң Камил хәзрәт җәмәгать белән дога кылалар һәм яңгырлар туктый.

Буа мәдрәсәсендә укыганда Мәүлет абый Таҗиев (1946–2015) шундый бер гыйбрәтле хәлне Казан шәһәренең «Шамил» мәчете имамы, якташыбыз Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдиновка сөйләп калдырган иде: «Толымбай авылы мулласы Җәүдәт хәзрәт Рәхмәтуллин үләр алдыннан Үзбәкстаннан бер хатын кайткан була. Ул хатын үзе тумышы белән Толымбайдан булып гомере буе Узбәкстанда яши. Аның аяклары бик нык авырта, көчкә йөри торган була. Табиблар янында күп йөреп шифа таба алмагач Бохараның изге җирләренә барып Аллаһтан шифа сорый. Шунда бер карт бабай килеп чыгып: «Кызым сезнең үз авылыгызда бер изге кеше күмелгән. Шунда кайтып рухына Коръән укып, Аллаһтан шифа сора, шифа табырсың» ди. Бу хатын акчаларын җыеп Толымбайга кайта. Җәүдәт хәзрәт белән күрешеп бергә Әхмәр хәзрәт Юныснең каберен эзләп табалар. Хәзрәт Ясин укый, рухына багышлый, бу хатынга Аллаһтан шифа сорый. Бу хатын үзе дә күп догалар кыла. Шулай берничә кат баралар. Ни хикмәт көчкә аякларын сөйрәп йөргән хатын бер атна эчендә терелеп, шатланып Узбәкстанга кайтып китә».

Бу булган вакыйгалардан аңлашылганча, Аллаһка якын булган кешеләргә, изге бәндәләргә Аллаһ бәрәкәт (благодать) дигән нигъмәт биргән. Шуңа аларның исән чата ук бик күп кешеләргә файдалары, шифалары тигән. Ул-

гәч тә халыкка тәэсире, файдасы бәрәкәте калган. Моны икенче төрле фән телендә аура, энергетик вибрация дип атыйлар. Ул күренми, әмма тәэсире изге кешеләргә бәйле урыннарда саклана. Шуңа да халык андый урыннарны кадерләп саклаган, әледән-әле барып зыярат кылганнар, ул кешеләрне онытмаган. Алар рухына Коръән укып, изгелекләр кылып әҗерләрен аларга багышлагач, алар шатлананып ята, диелгән дини китапларда һәм шуның хөмәтенә Аллаһ Тәгалә бу кешеләрнең сораган теләкләрен кабул итә. Аңлаган кешеләргә монда зур гыйбрәт һәм тәрбия бар.

Барыбызга да шундый Аллаһка якын булган кешеләрне искә алып, алар рухына догалар кылырга, алар мисалында Аллаһка якынаерга, Ислам динен ихластан тотып, әдәпле-әхлаклы булып, бәхетле яшәргә насыйп булсын!

### Әдәбият


1. Материалы по истории образования и просвещения народов Волго-Уралья в рукописных фондах Н.И. Ильминского. Сборник документов и материалов/Авторы составители: Р.Р. Исхаков, Х.З. Багаутдинова. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ; Изд-во «Яз», 2015.
2. Миннуллин И.Р. Мусульманское духовенство и власть в Татарстане (1920–1930 гг.). Казань, 2006.
3. Миннуллин И.Р., Минвалеев А.М. Суфизм в советском Татарстане: к постановке проблемы//Суфизм как социокультурное явление в российской умме: материалы Всерос. науч.-практ. конф. (Казань, 21 ноября 2006 г.). Н. Новгород, 2007.
4. Шин П.А. (Пашино П.А.). Волжские татары //Современник. 1860. Т. 81. С. 274–284.
5. Штейнфельд Н.П. Малмыжские татары, их быт и современное положение//Календарь и памятная книжка Вятской губернии за 1894 год. Вятка, 1893.
6. Юсуф Хаттар. Суфийская энциклопедия. Дамаск: Изд-во «Надр», 1999.
7. Саид-афанди ал-Чиркави. Сокровищница благодатных знаний. Казань: изд. «Иман», 2006.
8. Али-заде А. Исламский энциклопедический словарь. М.: Ансар, 2007.
9. Якупов В. Неофициальный Ислам в Татарстане: движения, течения, секты. Казань: Иман, 2003.
10. Маликов Р.И. Буа шәһәренең мөселман гыйбадәтханәләре тарихы. Казан: «Идел-Пресс», 2009.

*Галия Гайнетдинова*

## ТАТАРНЫҢ БӨЕК УЛЫ АТНАБАЙ

Һәр елны февраль урталары җиттеме, күңел туган якка, Башкортостанның Тәтешле районында урнашкан Күрдем авылына ашкына. Бу ашкынуны сүз белән генә аңлатып булмый. Сәбәпләре күптөрле аның. Минем туган авылым Сараштыбаш Күрдемгә 6 чакрым гына ераклыкта. 9–10-нчы классны мин шунда укыдым. Биредә минем туганнарым, классташларым, дусларым яши. Казаннан кайткан чакта да юлым Күрдем аша үтә. Бәлки шуңа күрәдер, миңа бу авыл туган авылым кебек якын һәм кадерле.

Бу авылда шагыйрь, драматург Әнгам Атнабаев туып үскән. Авыл халкы яраткан шагыйрен һаман сагынып яши. Ел саен биредә Әнгам Атнабаевка багышланган тирән эчтәлекле «Күрдем чишмәләре» шигърият фестиваль-конкурсы үткәрелеп килә. Аны Тәтешле районы мәдәният бүлеге, Күрдем авыл Советы һәм К. Маркс исемендәге хуҗалык оештыра. Бүгенге көндә әлеге бәйгенең географик чикләре тагын да киңәйде. Тирә яктагы районнардан килгән шигърият яратучылар да үзләренең сәләтләрен күрсәтеп, җиңү яулап, лаеклы бүләкләрен алып китәләр. Шунысын да әйтергә кирәк, алар арасында төрле милләт вәкилләре бар.

Фестиваль ике турда үткәрелә. Беренчесе – иң яхшы нәфис сүз осталарын сайлап алу конкурсы булса, икенчесе – җиңүчеләр катнашлыгында «Гала-концерт». Гала-концерт тәмамлангач, яшь категориясенә карап 1, 2, 3 нче урыннарга һәм «Гран-При» иясенә дипломнар, истәлекле бүләкләр тапшырыла.

Фестивальнең өченче өлешендә еллар дәвамында иҗади эшчәнлеге белән аерылып торган шәхесләргә Әнгам Атнабаев исемендәге әдәби премия бирелә.

«Күрдем чишмәләре» шигърият фестиваль-конкурсы 2007-нче елдан бирле үткәрелеп килә. Шушы дәвердә 23 шәхескә әлеге премия бирелде. Димәк, бу төбәктә, якын-тирә районнарда талантлы шәхесләребез, Атнабай юлыннан баручы шагыйрьләребез күп дигән сүз. Алар, үз чиратларында, эстафетаны яңа буынга тапшыра килә. Гаҗәпләнерлек бит. Иҗади рухлы кешеләре белән дан казана туган ягым. Күрдем авылында күп еллар дәвамында «Өметле каләм» клубына йөреп, шигърияткә гашыйк җаннар каләм чарлый. Шушы җирнең чишмә суларында да шигърият агадыр төсле. Чөнки монда һәр урам саен шагыйрь яши.

Мин үзем әлеге бәйгегә ел саен иҗади дәрт туплап, ашкынып кайтам. Баштагы елларда катнашып, «Гран-При» иясе булсам, соңрак Ә. Атнабаев исемендәге премиягә лаек булдым. Яза-яза, китаплар чыгара-чыгара

иҗат баскычларына шулай күтәрелдем. Күрдем авылы, аның шигърияткә битараф булмаган күркәм халкы, онытылмас Атнабае турында уйласам, күңелне горурлык, ярату хисләре били. Киткән чакта ярты җаным шунда каладыр кебек тоела миңа.



Шагыйрә Галия Гайнетдинова

Биредә үзенең Атнабае кебек халкы да шигъри җанлы, хезмәт сөючән. Татар җыры, татар моңы, татар теле һәр гаиләнең яшәешендә зур урын тота. Шунысы күренеп тора: Ә. Атнабаев үзенең иҗаты аша кешеләр йөрәгенә туган телгә карата сакчыл мөнәсәбәт, мәхәббәт, горурлык һәм тугрылык хисләрен тирән сеңдерә. Туган теленә беркайчан да хыянәт итмичә, кешелеккә якты эз калдырып китә. Китә дию бик дөрес тә булмас. Шагыйрь әле дә кабатланмас таланты һәм әдәбият фондына кыйммәтле җәүһәр сыман кереп калган титаник хезмәте белән бүгенге заман баласында милли үзаң тәрбияли, илаһи җанлы яңа буынны үстерә.

Ә. Атнабаев иҗатын өйрәнәләр, аның иҗаты буенча мәктәп укучылары, студентлар төрле фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашып җыеннар яулыйлар. Әнгам Атнабаев – тугандаш ике республика халкының да уртак горурлыгы.

РСФСР һәм БАССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе, Башкортостанның Халык шагыйре, республиканың Г. Сәләм премиясе лауреаты Әнгам Атнабаевның күпкырлы кабатланмас иҗаты турында томнар язарга кирәк. Әйтергә теләгәнем шул: мәктәп-гимназияләрдә әдәбият дәресләрендә балаларга кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов, башкорт язучысы Мостай Кәрим иҗатлары өйрәтелә. Ә нигә әле Татарстан мәктәпләрендә Әнгам

Атнабаев иҗатын да өйрәтмәскә? Бәлки якын киләчәктә безгә аның әсәрләрен дә әдәбият дәреслеге битләрендә күрү насыйп булыр.

**Шагыйрь туган көн**

Бүген бәйрәм Күрдем авылында,
Бүген бәйрәм – шагыйрь туган көн.
Бу бәйрәмдә әйтер сүзем барга
Шигырь язып куйдым узган төн.

Урамнарга сыймас төсле бүген
Иртәдән үк дуслар шатлыгы.
Бәйрәмгә бер илаһилык өсти
Февраль көннәренең аклыгы.

Әнгам абый Атнабаев кайткан
Безнең күңелләрне уятып.
Җиз кыңгырау чыңлый, чынлап чыңлый
Йөрәкләрне безнең кузгатып.

Шагыйрь кайткан, инде күргәнсездер,
Мин дә күрдем. Ярым елмаеп,
Афишадан карап тора әнә,
Киткән төсле бераз олыгаеп.

Үткен күзләр карый киләчәккә,
Җитди караш аңа килешә.
Бу чакта ул ни уйлады икән?
Җавап бирер кеше төрлечә.

Матурларга уйлагандыр җирен
Сагышларын йотып йөрәккә.
Бәлки уйлагандыр яңа җырлар
Багышларга туган төбәккә.

Шигырьләрен укыйм, укыганда
Ишетәм мин шагыйрь тавышын.
Ул – халкының затлы йөзек кашы,
Тавышын да, аның иҗатын да
Оныттырмас еллар агышы.

Һәр ел саен февраль кабатлана,
Кабатлана шагыйрь туган көн.
Кабатланыр алда Атнабайны сагынып,
Искә алып, шулай зур залларга
Дус-ишләрне бергә җыйган көн.

***Дамир Гыйсметдин***

## ДЕМОКРАТИЯ

*(Почти булган хәл)*

Ил өстендә шаулый демократик давыл,
Шундый хәлдә ничек сайлый икән авыл?
Әйтте башлык: «Ничек булса, шулай булсын –
Сайлаулар үз агымына гына узсын!..»
Менә Гайфи агай кайтып килә җырлап,
Буфетлар мул – җибәргәннәр моны сыйлап.
«Мин влачка тавыш бирдем – эшләсеннәр,
Первыйлыктан аска гына төшмәсеннәр!»
Хәсән абый демократларны яклаган,
Ләкин серен барсыннан да саклаган.
Башкаларга әйткән: «Шөкер бит Аллага,
Эшләр шәп бара!», – дип, рәисне мактаган.
Әнә тракторчы Сәйфи кайтып бара,
Усаллыгы күзләрендә – йөзе кара...
Үпкәсе рәискә: фуражларны кысты,
Шуңа тракторчы һәммәсен дә сызды.
Пенсиядәгеләр тавыш бирде өйдә,
Тәүге тапкыр үзләре теләгән көйгә...
Үткәннәрне өзелеп сагынганга күңел,
Зюгановны сайладылар алар бүген.
Шулай итеп ирекле сайлаулар узды,
Санадылар – нәтиҗәдән күзләр тонды:
«Тормыштан канәгать» авыл влачны сызган,
Шуңа беренчегә коммунистлар узган.
«Дөрес санамагансыз бит, ачәрвахлар!
Себер китә сезнең белән газиз башлар! –
Сүкте рәис избиркомны, тетте барсын: –
Төзәтегез – санау дөрес якка барсын!..»
Санадылар... Кая кирәк өстәделәр,
Канәгать булсыннар диеп өстәгеләр.
Нәтиҗәләр шунда гына дөрес чыкты:
Югарыга «Җиңдек!» дигән рапорт очты...

*Асия Галимова*

## ПРИКЛЮЧЕНИЯ РАСТИ



Жил на свете старичок,
Расти, маленький жучок.
Был он добрый, был он скромный,
Жил он в домике огромном
В деревушке у пруда,
Где зеленая вода.

Раз лежал он перед сном,
Думал так, о том, о сем:
О листве, о муравьях,
О заплатках на штанах,
О природе, о погоде,
Обо всем в таком же роде.

Вспомнил детство, вспомнил игры
И подумал жук о том,
Что он не был нигде в мире,
Сколько лет лишь этот дом.

Вот бы сделаться моложе,
Взять рюкзак и на порожек,
И бежать, бежать, бежать,
Чтоб закаты провожать
И встречать рассветы
Вдалеке от дома где-то.

Эта мысль его сверлила,
Не давала жить как прежде,
Путешествия манили,
И маячила надежда.

Наконец-то пробил час:
Жук решил оставить дом,
Теплый плед и свой диванчик,
Выйдя утром с рюкзаком,

Он подумал: «Будь что будет,
Буду мерзнуть, голодать,
Только-только непременно
Мир я должен повидать».

За углом он встретил кошку,
Быстро прыгнул ей на хвост
И доехал по дорожке
До пруда, где старый мост.

На мосту он поскользнулся,
Незаметно в щель скользнул,
Десять раз перевернулся
И воды в пруду хлебнул.

Расти жутко испугался,
Он не плавал никогда,
Иногда лишь умывался
Прям у краешка пруда.

Стал он лапками барахтать
И схватился за листок.
На него скорей взобрался
И поплыл с ним на восток.

Ветер гнал его все дальше,
Вот уже и мост пропал,
Было Расти очень страшно,
Он такоооое испытал!

Вдруг его корабль подпрыгнул,
Будто кто-то подтолкнул.
Это так играли рыбы,
Тут не водится акул.

«Как же хочется на сушу».
Стал он думать, как же быть.
«Вот бы сесть мне на Лягушку
И до берега доплыть.

Расти стал искать спасенья –
Может, утка проплывет,
Водомерка, иль корягу
Ветер к берегу несет.

Вдруг откуда ни возьмись
По пруду скользнула выдра.
Расти шепчет: «Соберись,
Будет рядом, быстро прыгай!».

Наш герой собрался с духом,
Подгадал момент, рывок,
Прыг – и он уже над ухом
Выдры. «Ну, теперь вперёд!»

Зверь его привёз на берег.
Расти спрыгнул на песок,
И в себя безмерно веря,
Зашагал среди осок.

Так он шёл среди травинок,
Пил с них воду, ел цветы.
Видел множество личинок,
Муравьиные следы.

Потихоньку вечерело.
Жук устал, озяб, промок.
Что же было ему делать,
Прям на землю взял и лёг.

Он уснул без задних ног.
И проспал бы двое суток,
Да и трое тоже мог,
Если бы не крики уток.

Видит Расти: нет травы,
Нет земли и нет листвы.
Может, это просто сон,
Иль он ветром унесён?!

Видно мост вдали и пруд,
Как он оказался тут?
Сам на дереве лежит,
Рядом чей-то хвост торчит.

Вооот как жук сюда попал,
Он на шкурке белки спал.
Видно, то, на что прилёг,
Не земля была, зверёк!

Как же здорово тут жить:
Солнце ближе, ветер тише.
Можно домик смастерить
Из пустых сосновых шишек.

Где-то дятел застучал,
Это враг жуков заклятый.
«Что-то я не замечал,
Рядом с домом красношляпых.
Делать ноги срочно нужно
Или дятел съест на ужин».

Быстро жук спустился вниз,
Запыхался, весь вспотел,
Кто-то мимо пролетел
И на ниточке повис.
Как, откуда, почему?
Злой паук ползёт к нему.

Вот где Расти наш попался,
Паука не проведёшь.
Раньше он от них спасался,
А теперь по телу дрожь.

Раньше Расти был моложе,
Силы больше, глаз острей,
А сейчас мороз по коже,
«Ну, съедай меня скорей!»

Вот сейчас жучок погибнет,
«Что я дома не сидел?!»
А потом кааак с ветки прыгнет,
Злой паук аж обомлел.

«Не встречал ещё пока
Я такого старика,
Чтоб стоял дрожал и ап!
Ускользнул из цепких лап».

А тем временем жучок
Приземлился на сучок.
Пополам сук разломился
И на землю жук свалился.

«Я от дятла лихо скрылся,
С пауком чуть не сразился.
Если дело так пойдёт,
Слух по лесу поползёт:

«Расти – храбрый, быстрый, ловкий,
Переплыл он пруд без лодки.
И доехал до моста
Лишь при помощи хвоста.

На сосну поднялся с белкой,
Спрыгнул вниз и был таков.
Вроде и породы мелкой,
Все ж из смелых он жуков».

Отряхнувшись от земли,
Расти дальше зашагал.
Лапки были все в пыли,
Старый рюкзачок пропал.

Только жук не унывал.
Шёл он бодро по тропинке,
Залезал на колоски,
На зеленые травинки,
на сухие лепестки.

Вдруг все резко изменилось,
Снизу все зашевелилось,
Из-под ног ушла земля,
Что-то на жука свалилось –
По листве ползёт змея.

Как прекрасно быть жуком –
Путешествовать верхом
И на выдре по воде,
И на кошке по дорожке.

Змей привёз его к пещере,
Расти прыг и убежал,
Счастью своему не веря,
Он жучиху повстречал.

Что за крылья! Что за глазки!
Лапки, усики, ой-ей!
Словно очутился в сказке.
Эх, теперь бы с ней домой!
Доживать свой век вдвоём,
В тёплом домике своём!

К незнакомке подошёл,
«Здравствуйте!» и шляпу снял,
Больше слов он не нашёл,
Шляпу лапками измял,

Потоптался, помолчал,
Глаз не в силах оторвать,
Что-то будто промычал,
И промолвил: «Как вас звать?».

А она не растерялась
И ответила: «Женева,
Раньше вы мне не встречались,
Вы недавно здесь, наверно?»

Расти был ужасно рад,
Проболтали до заката,
Оказалось, что она
За прудом жила когда-то,

Но однажды ветер сильный
В пруд корзину опрокинул,
А она внутри сидела
И в клубочках лапки грела.

Нитки бабушкины были,
А жуки меж досок жили,
В домике её уютном,
Так, однажды рано утром
Бабушка взяла лукошко
И уселась у пруда,
Задремала там немножко
И Женева уплыла.

Только бабушка вернулась,
Начался переполох,
Дом вверх дном перевернули,
Все искали - кто где мог.
Но Женеву не нашли,
Горько плача, спать пошли.

Наш доблестный Расти
С прелестной Женевой
Решили отправиться в путь.
«Не бойся, Женева,
Я всех одной левой,
О страхах своих позабудь!»

Дошагали до пруда,
Где зелёная вода.
«Как его преодолеть
И в воде нам уцелеть?!

Перейти никак нельзя,
Обойти не хватит дня»
Долго сидя размышляли
Под корой сырого пня.

Взяли б щепку вместо лодки,
Но не хватит сил столкнуть
На воду. Такой работы
Старику не потянуть.

«Вот бы сделаться моложе, –
Жук подумал. – Ну и что?!
Старики мы тоже можем,
Сила без ума ничто!

Думай, Расти, поскорее,
Как домой попасть вдвоём,
Скоро станет холоднее,
Опоздаем – пропадём!»

Тут откуда не понятно
С неба падает перо.
Расти шепчет: «Вероятно,
Нас оно спасти должно!»

Взявшись за руки, они
За пером помчались лихо,
Ухватились, заползли
И верхом уселись тихо.

Ни один жучок на свете
Над прудом не пролетал,
Ни один жучок на свете
Много так не испытал!

Если хочется, то надо
Не печалиться, не ныть,
Со смекалкой и отвагой
Пруд на выдре переплыть.

Оказаться там, где не был,
Посмотреть, что не видал.
Не трястись, укрывшись пледом,
Как бы дятел не напал.
Как бы ворон не склевал.
Как бы ветер не ворвался.
Как бы домик не сломался.

Много очень страшных «как»,
Неспокойно жить трусливым,
Каждый будет тебе враг,
Если будешь боязливым.

Перо опустилось,
Конец приключеньям,
Конец испытаньям,
Бездомным скитаньям!

Вернулся наш Расти
Довольный собою.
Он понял, что счастье –
Идти за мечтою!

Мечтается – делай!
Рискуй, добивайся!
Теперь он с Женевой
И не о чем каяться!

Теперь у него сыночки и дочки
И думать «А вдруг бы...» боязно очень.
А вдруг не решился б,
Не сел бы на кошку,
А вдруг его съел бы паук, словно мошку.

Теперь он не только пожил на земле,
Теперь он оставил детей на планете,
Теперь он так много узнал о себе
И понял, что самый счастливый на свете!

*А.Г.Хәйретдин*

# КОРЪӘНДӘ БӘЯН ИТЕЛГӘН РЕИНКАРНАЦИЯ ТӘГЪЛИМАТЫ ТУРЫНДА

*(Дәвамы. Башын карагыз: № 1, 2, 3, 2019)*

Коръән айәтләренең дөрес аңланмавы, мәгънәләрнең бозып аңлатылуының, әлбәттә, сәбәбе бар. Бу сәбәпнең ни кадәр зур бер нәрсә булуын аңлатыр өчен бер мисал китерәсем килә. Төрле төсле һәм төрле зурлыктагы боҗралардан җыелган «пирамидка», дип аталган балалар уенчыгын һәркемнең күргәне бардыр. Ул боҗралар нигез боҗрага кадап утыртылган кендеккә киертеләләр. Кендек урынында булганда, боҗралар иң зурысыннан башлап кечкенә сенә таба җайлы гына итеп берсе өстенә берсе куелып тезеләләр дә, пирамиданың башына капкачсыман өслек киертелеп куела. Өслек йозак вазыйфасын да башкара. Кендек белән өслек үз урыннарында булганда, пирамида шактый нык була. Аны аударсаң да, тәгәрәтеп йөртсәң дә, астын өскә әйләндерсәң дә ул таралып китми, чәчелми, сүтелми. Андый дөрес җыелган пирамидага уңнан карасаң да, сулдан карасаң да – ул бертөрле булып күренә.

Инде шул ук пирамиданы кендексез җыйганнар ди. Нигез боҗра тигез урынга куелып, җил-фәлән, кеше кулы тими торган бер урын булса, боҗраларны берсе өстенә берсен өеп куеп, пирамиданы, бәлки, җыеп та буладыр. Тик ул никадәр озак торачак? Аны ишеп төшерер өчен җил дә кирәк түгел, кеше кулы тиюе дә кирәк түгел, бер сизелер-сизелмәс тетрәү дә җитә кала. Ислам дине белән дә әнә шундый хәл булган. Бүгенге көндә ислам дине тәгълиматыннан пирамидада кендек вазыйфасын үти торган кендеккә тиң булган үтә дә әһәмиятле бер төшенчә алынган, яшерелгән. Ислам динен төзек, җыйнак, эшлекле һәм актив хәлдә тота торган кендекнең, ягъни мөһим төшенчәнең булмаганына күрә ни Коръән айәтләре дөрес аңланмый, ни, гомумән, ислам дине, ислам дөньясы таркау, җимерек, тузгытылган хәлдә кала бирә.

Тыныч, аулак урында пирамида кендексез дә тора ала, дигән идек. Тик, дин ул пирамида түгел. Дин җәмгыятьнең, иҗтимагый яшәешнең үзәгендә тора торган нәрсә. Дин ул яшәешне оештыра торган чара, яшәешнең, хәтта үзәге булырга тиешле. Дин аулак урында посып ятар өчен бирелмәгән. Аулакта качып ятар өчен яратылмаганга күрә ислам динен тәшкил иткән «боҗралар» аның бер мөһим өлеше, тәгълиматының кендеге юкка чыгарылганга күрә бик тиз ишелеп төштеләр дә кая килде шунда аунап яталар. Араларында өслек тә ята. Аның исеме «Аллаһ». Югарыдан беренче булып торасы боҗра «тәүхид», дип атала, икенчесе –

«гыйбадәт»... Араларында «иман», дигән бөҗра да бар, «шәригать», дигәне дә бар, «әхлак», дигәне дә бар. Беренче карашка, барысы да урында кебек, тик төзек, җыелган, тупланган шәкелдә түгелләр шул...

Кая килде шунда таралышып яткан ул бөҗраларны, ягъни, ислам динен тәшкил иткән нигез төшенчәләр турында галимнәр гасырлар дәвамында берсеннән берсе калын булган тау-тау китаплар язганнар: «Алай түгел, болай ул!», дия-дия бәхәсләшкәннәр, берсен берсе ялгышуда, адашуда, көферлектә гаепләгәннәр, берсе берсенең канын коешканнар... Шулай итеп чыгырыннан чыгарылган ислам дине бүгенгә кадәр ничек булса шулай килеп җиткән. Ә гаугалар, талаш-ызгышлар, узара сугышлар әлегә кадәр дәвам итә. Әлегә кадәр Аллаһ исеме белән кан коела...

Ислам дине тәгълиматының кендеге урынында булса әгәр, ислам дөньясы, мөселманнар, минемчә бу хурлыкка калмас иделәр.

Ислам динен төзек һәм нык хәлдә тотачак ул кендек нәрсә соң ул?

Ислам динен төзек хәлдә җыеп тотарга тиешле булган кендек ул җаннарның кеше тәненә иңеп, шунда сынаулар үтеп, кеше үлгәч, яңа тәнгә иңдерелеп, яңадан яшәп, сынаулар узып, үткән тормышта кыйлганнарның җәзасын һәр алдагы тормышта алып, тәннән тәнгә күчеп йөрүләре турындагы тәгълиматтыр, ягъни реинкарнация тәгълиматы, дип атап була.

Әлеге реинкарнация тәгълиматы ислам дине нигезләренең берсенә дә каршы килми. Ул ни Аллаһны инкяр итми, ни фәрештәләрне, ни җеннәрне, ни китап вә пәйгамбәрләрне, ни Кыямәтне, ни ахирәтне... Ни намазга орынмый. Ни уразага. Ни хаҗ вә зәкәткә. Ни Ахыр заманга, ни илаһи гаделлеккә, ни илаһи газап вә рәхмәткә кимчелек китерми. Ни җан төшенчәсенә, ни нәфес төшенчәсенә хилафлык китерми... Болай булганда, җаннарның тәннән тәнгә күчеп йөрүе турындагы тәгълимат турында белеп торуның, аның ислам диненең, Пәйгамбәр, галәйһис-саләт вә-с-сәлам, китергән хәбәрнең асылы булуын белүнең нинди зыяны була алсын, нинди ялгышлык бар аны кабул итүдән?

Үзләрен дин галимнәре дип атаган белгечләр тарафыннан ул тәгълимат кире кагылса да, аның асыл төшенчәләре Пәйгамбәр теле белән ишеттерелеп, Коръән кәримдә сакланылган. Эшнең нидә икәнлеген аңлар өчен Коръән айәтләрен аек акылга таянып, тиешле ният белән коралланып, уяу йөрәк белән кавышып аз гына булса да игътибарлырак итеп укырга кирәк.

Мәсәлән, бер айәткә күз салыйк: ***«үә калү ә изә даләл-на фи-л-арды ә ин-на лә-фи халкын җәдидин бәл һум би-лика'и рабби-һим кяфирун»*** (32:10).

Башка бик күп айәтләрнең мәгънәләре кебек, бу айәтнең дә мәгънәсе тупас рәвештә бозылып, үзгәртелеп аңлатыла килгән. Нәтиҗәдә барлыкка килгән ул бозыкны күрер өчен башта, гадәттәгечә, халык арасында

таралыш тапкан тәрҗемә вә тәфсирләргә карыйк. Аларда бу айәтнең мәгънәсе болай аңлатыла:

*«Без җир эчендә югалып китсәк тә, яңадан яратылган булачакбызмы?» – диделәр алар. Юк, алар – шул Аллаһка юл куючы, ышанмучылар»* (Г. Исаев тәҗемәсе);

*«Үлгәннән соң череп туфракка әверелгәч, чынанн да, без яңадан терeләчәкбезме?* (без моңа ышанмыйбыз), *– диделәр. Хактыр ки, алар* (Ахирәттә) *Раббылары белән кавышуны инкарь итте»* (Р. Батулла тәрҗемәсе);

*«Үлгәннән соң терелүгә ышанмаган кешеләр әйттеләр: «Җирдә туфрак булып югалсак, яңадан кеше булып яратылырбызмы?» Аллаһ әйтте: «Алар, күрәсез кубарылып Раббыларына юлыгуны инкяр итәләр».»* (Ногмани тәфсире).

Бу айәтнең чын мәгънәсен аңлар өчен башта аның сүзгә-сүз тәрҗемәсен китерик:

| | |
|---|---|
| *үә калү* | һәм әйттеләр |
| *ә изә даләл-на* | югалгач без |
| *фи-л-арды* | җирдә |
| *ә инна* | чыннан дамы без |
| *лә-фи халкын* | булдырылышта |
| *җәдидин* | яңа |
| *бәл һум* | әмма дә алар |
| *би-лика’и* | очрашуны |
| *рабби-һим* | раббылары белән |
| *кяфирун* | кире кагучылар |

Инде айәттәге бу сүзләрне тоташ бер җөмлә итеп җыйыйк:

*«Алар әйттеләр: «Без җир эчендә югалгач, без чыннан да яңа булдырылыштабызмы?», – диделәр. Алар Раббылары белән очырашуны кире кагуычылардыр!».*

«Булдырылыш» итеп мин *халкъ* дигән сүзне тәрҗемә иттем. «Булдырырга» мәгънәсенә ия булган *халәка* фигыле турында моннан алда инде әйтелгән иде. *Халкъ* сүзе, ягъни *булдырылыш* шул фигыльдән ясалган. Ул сүзне ничек бар шулай итеп халык дип тә, ягъни «бер булдырылган нәрсә», «бер мәхлүкъ», «халык кыйлынган нәрсә», итеп тә тәрҗемә итеп булыр иде. Бу очракта айәтнең тәрҗемәсе болай булыр иде: *«Алар әйттеләр: без җир эчендә югалгач, чынлыкта, яңа халыктамыни/мәхлукътамыни/халык кыйлынган нәрсәдәмени?», – диделәр. Алар Раббылары белән очырашуны кире кагуычылардыр».*

Нигә соң мин бу айәтне «*яңадан яратылачакбызмы*», дип тәрҗемә итмәдем? Гомумән, нигә мин үземнең тәрҗемәмдә югарыда китерелгән Г. Исаев тәрҗемәсендәге кебек «*яңадан яратылган булачакбызмы*», яки

Р.Батулла тәрҗемәсендәге кебек «*яңадан терeләчәкбезме*», яки Ногмани тәфсирендәге кебек «*яңадан кеше булып яратылырбызмы*», сыман фигыльләр кулланмадым?

Чөнки бу айәттә кайчандыр киләчәк заманда булачак яратылыш, яңадан туу, кубарылу турында хәбәр бирүче фигыль аслән юк. Айәттә ике фигыль бар, анысы хак. Ул фигыльләрнең беренчесе үткән заман шәкелендә килгән ***үә калү*** (*һәм әйттеләр*) фигыле; икенчесе кайчандыр киләчәктә тәмамланачак хәлне белдергән ***изә даләл-на*** (*без югалгач*), дигән фигыль. Бу фигыльләрнең беренчесе ап-ачык мәгънәгә ия, ягъни Пәйгамбәрнең әйткәннәрен исе-акыллары китеп тыңлап торган кешеләр, шак катып аңа сорау рәвешендә шикләнүләрен, инанмауларын белдереп *әйттеләр*. Икенче фигыль исә үзләрен кабергә салынган тән буларак кабул итүчеләрнең кабердә таркалып югалачак гәүдәләре турында, череп юкка чыгачак мәетләре турында әйткәндә, *без югалгач*, дигән сүзтезмә буларак кулланылган. Әмма *яратылачакбыз, яратылырбыз, яратылган булабыз*, мәгънәсен белдергән киләчәк заман шәкелендә килгән фигыль, кабатлап әйтәм, айәттә юк.

Тагын да тирәнгә керсәк, әлеге айәтнең ике җөмләдән, яки, теләсәгез, тәмамланган ике фикердән торганын күрәчәкбез. Ул җөмләләрдә бер-бер артлы килә торган, берсе артыннан берсе була торган ике хәл, ике халәт бәян ителә. Табигый тәртибе буенча беренче халәт ошбудыр: «без югалгач», ягъни, сүз кабердә таркалып югалу турында бара, тәртибе буенча икенче халәт исә: «*без булдырылыштамыни?*». Бу халәт табигый булса да, кешеләр моңа ышана алмыйлар, шуңа күрә ишеткәннәренә исләре китеп сорау бирәләр.

Беренче халәт фигыль җөмлә рәвешендә белдерелгән, ягъни, җөмләдәге ия алмашлык белән белдерелгән (*без*) була, хәбәр исә фигыль белән белдерелгән (*югалгач*). Икенче халәт сораулы исем җөмлә белән, ягъни фигыльсез җөмлә белән бирелгән: «*без булдырылыштамыни?*» Бирeдә ия булып (*без*), дигән алмашлык, ә хәбәр булып *булдырылышта*, дигән исем килә.

Исем җөмлә нәрсә ул?

Тәмамланган бер фикерне бәян итәр өчен, аны башка берәүгә җиткерер өчен төзелгән җөмләдә фигыль кулланылмаса, андый җөмлә «исем җөмлә», дип атала. Мәсәлән, «*Мин укытучы*», «*Син сатучы*», «*Ул өйдә*», кебек җөмләләр исем җөмлә булалар. Күренгәнчә, нинди дә булса тәмамланган фикерне белдерер өчен фигыль куллану мәҗбүри шарт түгел. Исем җөмләгә тагын мисаллар китерик: «*Мин мәктәптә*», «*Сез мәчеттә*»; «*Мин зур матур авылның борынгы мәктәбендә*», «*Сез мәшһүр каланың яңа мәдрәсәсендә*», «*Теге шаян малай агач башында*», «*Аның кадерләп саклаган борынгы китабы өстәл өстендә*». Күренгәнчә, исем җөмләнең ике генә сүздән торуы да шарт түгел, андый җөмлә җәенке дә

була ала, шул ук вакытта ул әйтеләсе фикерне дә төгәл чагылдыра. Без тикшергән айәтнең «*без, чынлап та, яңа булдырылыштабыз мыни?*», дигән өлеше дә нәкъ әнә шундый исем җөмлә дөресрәк итеп әйткәндә, сорау исем җөмлә булып тора.

Исем җөмләнең фигыль җөмлә белән чагыштырганда нинди үзенчәлеге бар? Фигыль җөмлә теләсәң дә, теләмәсәң дә, хәбәр ителгән халәтнең вакытка карата нинди дә булса мөнәсәбәттә торуын чагылдыра: «*мин мәктәпкә бардым*», «*мин мәктәпкә барам*», «*мин мәктәпкә барачакмын*», «*мин мәктәпкә баргач...*», «*мин мәктәпкә барганчы...*» һ.б. Ә исем җөмлә әйтеләсе фикерне үткәнгә дә күчерми, киләчәккә дә. Исем җөмлә белән бары тик хәзерге вакытта күзәтелә торган хәл, хәзерге вакыттагы вәзгыят, вакыйга, процесс белдерелә. «*Мин укытучымын*», дигәндә минем хәзерге минутта, хәзерге вакытта укытучы булуым турында хәбәр ителә. «*Мин укытучымын*», дигән җөмләне «*Мин укытучы булачакмын*», дип аңлау мөмкин нәрсә түгел. «*Теге китап өстәлдә*», дигән тәмамланган мәгънә, хәбәр белдергән исем җөмләне дә «*Теге китап өстәлдә ятачак*», дип аңлау мөмкин түгел. Һәрхәлдә, акылы сәламәт булган кеше алай итмәс.

Ә инде Коръән айәте кадәр айәткә килгәндә ни сәбәптән әле без андагы исем җөмлә белән белдерелгән фикерне башкача аңларга тиешбез? Әйе, безгә аны шулай итеп аңлатырга тырышалар: Аллаһы тәгалә безгә: «***чынлыкта, сез мәетләрсез***», дигән, әмма безгә Аның сүзен «*чынлыкта, сез үләчәксез*», дип тәрҗемә-тәфсир итәләр. Аллаһы тәгалә безгә: «*кабердә югалып таркалгач сез яңа булдырылыштасыз*» ди, әмма безгә Аның сүзен «*кабердә югалып таркалгач сез яңадан терелтеләчәксез*», дип, яки мәгънәсен башка бер ысул белән бозып аңлаталар.

Коръән айәтләренең мәгънәләрен аңлауны мондый гаделсезлектән арындырсак, хәйран калдырырлык нәрсәләр ачылачак. Шуңа күрә дәвам итик.

Әлеге «*Алар әйттеләр: без җир эчендә югалгач без, чынлап та, яңа булдырылыштамыни?», – диделәр. Алар Раббылары белән очрашуны кире кагуычылар*», дигән айәттә ислам тәгълиматын кямил һәм төз бер корылма итеп тотып торучы кендеге булырлык белем хәбәр ителә. Ул белем нинди юл белән бирелгән, шуңа күз салыйк.

«*Алар әйттеләр*», дигәндә, Мөхәммәт пәйгамбәр галәйһис-сәламгә каршылык күрсәтүчеләр, аның вәгазьләреннән йөз чөерүчеләр, ягъни кәферләр күздә тотыла. Андыйларның әйткән сүзләрендә дә хикмәт бар. Кәферләр: «*без җир эчендә югалгач без, чынлыкта, яңа булдырылыштамыни?*», дип сорыйлар. Бу нәтиҗәгә алар үзләре килгәнме, әллә бу турыда аларга кем дә булса хәбәр биргәнме? Кәферләрнең бу сорауны тәмам хәйран калган бер хәлдә бирүләренә игътибар итсәк, әлбәттә, үзләре килгән нәтиҗә булмавы күренәчәк. Димәк, аннан алда аларга: «*Җирдә югалгач*

*сез, чынлыкта, яңа булдырылышта*», дигән берәү булган. Аңлашыла ки, ул берәү безгә мәгълүм булмаган әллә кем түгел, ә нәкъ менә Мөхәммәд Мостафа, салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләредер. Димәк, Мөхәммәд Мостафа Мәккә кәферләренә мөрәҗәгать итеп: «*Җир эчендә югалгач сез, чынлыкта, яңа булдырылыштасыз*», дигән булган. Бу сүзләрне ул үз белдеге белән әйткәнме? Юк, әлбәттә. Бу «*җир эчендә югалгач сез, чынлыкта, яңа булдырылыштасыз*», дигән төшенчәне аңа Аллаһы тәгалә вәхий кыйлган. Үз чиратында аларның пәйгамбәр әйткән бу сүзләргә ышанмаулары Аллаһ тарафыннан имансызлыкның яман бер галәмәте буларак бәяләнә. Бу хакта айәттә болай диелгән: «*Алар Раббылары белән очрашуны кире кагуычылар*». Гарәпчә бу җөмлә болай яңгырый: «***һум би-лика'и рабби-һим кяфирун***», ягъни Раббылары белән очрашуга карата көферлек белдерәләр. Димәк, *җир эчендә югалгач үзенең яңа булдырылышта булуына инанмаган кеше кәфер була.*

Инде тагын бер нәрсәгә игътибар итик: Мөхәммәд хәзрәтләре кәферләргә *кабердә* югалу турында түгел, ә нәкъ менә *җирдә* югалу турында әйткән. Болай дип әйтүенең дә тирән мәгънәсе бар. Миңа калса, Мөхәммәд хәзрәтләре, әлбәттә, чын кабернең нәрсәдән гыйбарәт булуын белгән... Ул чын кабердә чынлыкта кемнең «ятуын» да ул, әлбәттә, белгән.

Кәферләр пәйгамбәрләрдән мондый шаккаттыргыч нәрсәләр турында ишеткәч, әлбәттә, сүзсез кала торган булганнар. Чөнки кәферләрнең яшәеш белән үлемгә карата булган карашларын Коръән кәримнең: «***ин һийә илләә мәүтү-на әл-үлә үә ма нәхнү би-муншаринә***» (44:35), дигән айәте теркәп куйган.

Әлеге айәтнең сүзләтә тәрҗемәсе болайдыр:

| | |
|---|---|
| *ин һийә* | ул ич |
| *илләә* | гайре |
| *мәүтү-на* | үлемебез |
| *әл-үлә* | беренче |
| *үә ма нәхнү* | һәм түгел без |
| *би-муншаринә* | янә терелтелүчеләр |

Ягъни: «*безнең беренче үлемебез генә бар ич, һәм без һич тә янәдән терелтелүчеләр түгелбез*».

Югарыдагы айәттә фиргавен кавеменең сүзләре китерелгән булса, алда китереләчәк айәттә башка дәвердә яшәгән кәферләрнең үзләренә күндерелгән пәйгамбәргә әйткән сүзләре күрсәтелә: «***ин һийә илләә хәйату-на әд-дуньйа нәмүтү үә нәхьйа үә ма нәхнү би-мәбгусинә***» (23:38).

Әлеге айәтнең сүзләтә тәрҗемәсе болайдыр:

| | |
|---|---|
| *ин һийә* | ул ич |
| *илләә* | гайре |

| | |
|---|---|
| *хәйату-на* | яшәешебез |
| *әд-дүньйа* | түбәндәге |
| *нәмуту* | үләбез |
| *үә нәхьйа* | һәм яшибез |
| *үә ма нәхну* | һәм түгел без |
| *би-мәбгусинә* | янә тудырылучылар |

Ягъни «*безнең түбәндәге яшәешебез генә бар ич: үләбез һәм яшибез, һәм без һич тә янәдән тудырылучылар түгелбез*».

Димәк, Мөхәммәд хәзрәтләре дә шул ук хәлгә тарыган булган, ягъни, башка кәферләр кебек Мәккә кәферләре дә аның үлемнән соң яшәеш барлыгы турындагы кисәтүләренә ышанмый торган, каршы чыга торган булганнар. Коръән кәримдә бу хакта дәлилләр, чыннан да, бар: «***үә ин тәгъҗәб фә-гаҗәбүн каулү-һум ә изә күн-на түрабән ә ин-на лә-фи халкын җәдидин үлә’икә әл-ләзинә кәфару би-рабби-һим үә үлә’икә әл-әгълалү фи әгънакы-һим үә үлә’икә әсхабу ән-нари һум фи-һа халидуна***» (13:5).

Өлеге айәтнең сүзләтә тәрҗемәсе болайдыр:

| | |
|---|---|
| *үә ин тәгъҗәб* | һәм әгәр гаҗәпләнсәң |
| *фә-гаҗәбүн* | гаҗәптер |
| *каулү-һум* | әйткәннәре |
| *ә изә* | кайчан исә |
| *күн-на* | булдык |
| *түрабән* | туфрак |
| *ә инна* | чыннандамы без |
| *лә-фи халкын* | шиксез булдырылышта |
| *җәдидин* | яңа |
| *үлә’икә* | андыйлар |
| *әл-ләзинә* | шундыйлардыр |
| *кәфару* | кире кактылар (көфер кыйлдылар) |
| *би-рабби-һим* | раббыларын |
| *үә үлә’икә* | һәм андыйлар |
| *әл-әгълалү* | богаулар |
| *фи әгънакы-һим* | муеннарында |
| *үә үлә’икә* | һәм андыйлар |
| *әсхабу* | ияләре |
| *ән-нари* | ялкынның |
| *һум* | алар |
| *фи-һа* | аңарда |
| *халидуна* | мәңге калучылар |

Ягъни: «*Һәм әгәр гаҗәпләнсәң, аларның: «Без туфракка әверелгәннән соң, чыннан да, яңа булдырылыштабызмыни?», дип әйтүләре, чын-*

*нан да, гаҗәп. Алар Раббыларын кире кагучылар, һәм аларның муеннарына богаулар тагылган, һәм алар ялкын* (җәһәннәм) *ияләредер, алар анда мәңге калучылардыр*».

Ул гына да түгел, Коръән кәримнән аңлашылганча, әллә ничә айәттә «*сез туфракка әверелгәч чыннан да яңа булдырылыштасыз*», рәвешендә яңгыраган кисәтүнең нәкъ менә Мөхәммәт пәйгамбәр тарафыннан әйтелгән булуы күренә: «***үә калә-л-ләзинә кәфәру һәл нәдүллә-күм галә раҗүлин йүнәбби'ү-күм изә мүззикътүм күллә мүмәззәкын иннә-күм лә-фи халкын җәдидин***» (34:7).

Әлеге айәтнең сүзләтә тәрҗемәсе болайдыр:

| | |
|---|---|
| *үә калә* | һәм диделәр |
| *әл-ләзинә* | шундыйлар, кемнәр |
| *кәфәру* | кире кактылар (көфер кыйлдылар) |
| *һәл нәдүллә-күм* | күрсәтикме сезгә |
| *галә раҗүлин* | бер кешене |
| *йүнәбби'ү-күм* | белдерә сезгә/хәбәр бирә сезгә |
| *изә мүззикътүм* | таркалганыгыздан соң |
| *күллә мүмәззәкын* | бөтенләе белән таркалышның |
| *иннә-күм* | чынлыкта сез |
| *лә-фи халкын* | шиксез булдырылышта |
| *җәдидин* | яңа |

Ягъни: «*Көфер кыйлганнар: «Сезгә: «Таркалышның бөтенләе белән таркалганыгыздан соң сез яңа булдырылыштасыз», – дип хәбәр бирүче бер кешене күрсәтергәме сезгә?», – дип әйттеләр*».

Бу айәттә телгә алынган «*бер кеше*» нәкъ менә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафадыр. Татарчага «*сезгә белдерүче*», буларак тәрҗемә ителгән сүзтезмә айәттә ***йүнәбби'ү-күм***, сүзтезмәсе белән бирелгән. Аның нигезен *белдерергә, хәбәр итәргә*, дигән мәгънәләренә ия булган *нәббә'ә* фигыле тәшкил итә. Шул ук *нәббә'ә* фигыле белән бер үк тамырдан *нәбий*, ягъни пәйгамбәр сүзе ясала. Димәк, «*таркалыпмы таркалганыгыздан соң сез яңа булдырылыштасыз*», дигән сүзләр пәйгамбәребезнең теле белән хәбәр ителгән илаһи кисәтү булып тора. Ул хәбәрнең асылын яшәешнең үлем белән тәмамланмавы турындагы илаһи вәхи тәшкил итә. Ягъни, Аллаһы тәгалә пәйгамбәренә бу мәгълүматны вәхий рәвешендә иңдереп, аны шул заман кешеләренә ирештерергә боерган.

Шул илаһи боерыкны тормышка ашыру йөзеннән пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа кавемдәшләренә: «*каберегезгә кереп юкка чыкканнан соң сез яңа булдырылыштасыз*», дип кат-кат әйтә торган булган. Аның бу сүзләре байтак айәтләрдә чагылган.

Мәсәлән:

«***унзур кәйфә дарабу лә-кә әл-әмсалә фә-даллү фә-лә йастәтыйгунә сәбилән / үә калү ә изә күн-на гызамән үә руфатән ә ин-на лә-мәбгусунә халкан җәдидән***» (17: 48–49).

Әлеге айәтнең сүзләтә тәрҗемәсе болай була:

| | |
|---|---|
| *унзур* | кара |
| *кәйфә* | ничек |
| *дарабу* | китерәләр |
| *лә-кә* | сиңа |
| *әл-әмсалә* | мисаллар |
| *фә-даллү* | һәм адаштылар |
| *фә-лә йастәтыйгунә* | һәм булдыра алмыйлар |
| *сәбилән /* | юлны |
| *үә калү* | һәм әйттеләр |
| *ә изә* | мени кайчан |
| *күн-на* | булдык |
| *гызамән* | сөякләр |
| *үә руфатән* | мәет калдыклары |
| *ә инна* | мыни чыннан да без |
| *лә-мәбгусунә* | шиксез янә тудырылучылар |
| *халкан* | булдырылыш (буларак) |
| *җәдидән* | яңа |

Ягъни: «*Кара,* (Мөхәммәд) *ничек сиңа мисаллар китерәләр алар. Алар адаштылар да, юлны да* (таба) *алмыйлар һәм әйттеләр: «Без сөякләр һәм мәет калдыклары булгач без чыннан да яңа булдырылыштамыни?*».

Тагын бер мисал:

«***зәликә җәза’ү-һум би-әннә-һум кәфәрү би-айати-на үә калү ә изә күн-на гызамән үә руфатән ә ин-на лә-мәбгусунә халкан җәдидән***» (17:98).

Әлеге айәтнең сүзләтә тәрҗемәсе болай була:

| | |
|---|---|
| *зәликә* | шулдыр |
| *җәза’ү-һум* | җәзасы аларның |
| *би-әннә-һум кәфәрү* | кире какканнары (көфер кыйлганнары) өчен |
| *би-айати-на* | айәтләребезне |
| *үә калү* | һәм әйткәннәре (өчен) |
| *ә* | (сорау кисәкчәсе) |
| *изә күн-на* | әверелгәч без |
| *гызамән* | сөякләр |
| *үә руфатән* | мәет калдыклары |
| *ә инна* | чыннан дамы без |

| | |
|---|---|
| *лә-мәбгусунә* | шиксез янә тудырылучылар |
| *халкан* | булдырылыш (буларак) |
| *җәдидән* | яңа |

Ягъни: «*Айәтләребезне кире какканнары өчен һәм: «Без сөякләр һәм мәет калдыклары булып әверелгәч без чыннан да яңа булдырылыштамыни?», – дигәннәре өчен аларның җәзасы шулдыр*».

Тагын бер мисал:

«***бәл калү мислә калә әл-әүүәлүнә / калү ә изә мит-на үә күн-на түрабән үә гызамән ә инна лә-мәбгусунә***» (23: 81–82).

Әлеге айәтнең сүзләтә тәрҗемәсе болай була:

| | |
|---|---|
| *бәл калү* | тик әйттеләр |
| *мислә* | тиңен |
| *калә* | әйттеләр |
| *әл-әүүәлүнә /* | борынгылар |
| *калү* | әйттеләр |
| *ә* | (сорау кисәкчәсе) |
| *изә мит-на* | без үлгәч |
| *үә күн-на* | һәм без булгач |
| *түрабән* | туфрак |
| *үә гызамән* | һәм сөякләр |
| *ә инна* | чыннан дамы без |
| *лә-мәбгусунә* | шиксез янә тудырылучылар |

Ягъни: «*Тик әйттеләр алар борынгылар әйткәненең тиңен. Алар әйткәннәр иде: «Без үлгәч һәм туфрак белән сөякләргә әверелгәч без чыннан дамы шиксез янәдән тудырылучыларбыз?*».

Кабергә таркалып юкка чыккач кешене нәрсә көткәнен белдерә торган башка айәтләр дә бар. Мәсәлән:

«Һуд» сүрәсенең 7-нче айәтендә: «***үә лә-ин культә иннә-күм мәбгусунә мин бәгъди әл-мәүти лә-йакуләннә әл-ләзинә кәфәру ин һәза иллә сихрун мүбинүн***» (11:7), диелә. Әлеге айәтнең сүзләтә тәрҗемәсе болай була:

| | |
|---|---|
| *үә лә-ин* | һәм әгәр |
| *культә* | әйтсәң |
| *иннә-күм* | чынлыкта, сез |
| *мәбгусунә* | янә тудырылучылар |
| *мин бәгъди әл-мәүти* | үлемнән соң |
| *лә-йакуләннә* | һичшиксез әйтәчәкләр |
| *әл-ләзинә* | шундыйлар, кемнәр |
| *кәфәру* | кире кактылар (көфер кыйлдылар) |
| *ин һәза* | бу ич |

| | |
|---|---|
| *иллә* | тик |
| *сихрун* | сихер |
| *мүбинүн* | ап-ачык |

Ягъни: «*Әгәр дә әйтсәң: «Чынлыкта сез үлемнән соң янә терелтелүчеләрсез», – дип, кире кагучылар һичшиксез: «Бу ап-ачык сихердән кала һични түгел», – диячәкләр*».

«Кырмыска» сүрәсенең 67-нче айәтендә болай диелә: «***үә калә әл-ләзинә кәфәрү ә изә күн-на турабән үә әба’ү-на ә инна лә-мухраҗунә***» (27:67). Әлеге айәтнең сүзләтә тәрҗемәсе болай була:

| | |
|---|---|
| *үә калә* | һәм әйттеләр |
| *әл-ләзинә кәфәрү* | кире какканнар (көфер кыйланнар) |
| *ә* | (сорау кисәкчәсе) |
| *изә күн-на* | әверелгәч бер |
| *турабән* | туфрак булып |
| *үә әба’ү-на* | һәм аталарыбыз |
| *ә инна* | чыннан дамы без |
| *лә-мухраҗунә* | тач чыгарылучылар |

Айәтнең якынча тәрҗемәсе болай: «*һәм кире какканнар (көфер кыйлганнар) әйттеләр: «Без һәм безнең аталарыбыз да туфрак булып әверелгәч без чыннан дамы шиксез чыгарылучыларбыз?*».

Игътибар итик, мәетнең кабергә салынганыннан соңгы хәлләрен бәян иткәндә бу айәттә фигыль кулланылмый: «*туфракка әверелгәч без чыннан дамы шиксез чыгарылучыларбыз*», дигәндә «чыгарылучылар» сүзе ***мухраҗунә***, дигән кайтым юнәлешендәге сыйфат фигыле белән бирелә. Югарыда әйтелгәнчә, сыйфат фигыль хәзерге вакытта, хәзерге минутта булып торган хәлне, процессны, вәзгыятьне, күренешне белдерә.

Инде бу айәттә кулланылган ***мухраҗунә*** (чыгарылучылар) сүзенә күз салыйк. Ул *чыгарырга*, дигән мәгънәгә ия булган әхраҗә фигыленнән ясала. Шуңа күрә аны мәетләрнең терелтелеп каберләрдән чыгарылуы мәгънәсендә аңлау табигый булып күренә. Мәсәлән, Г. Исаев аны «*тагын да чыгарылачакбызмы*», дип тәрҗемә иткән. Хата юк кебек. Әмма, Г. Исаев айәттә кулланылган кайтым юнәлешендәге сыйфат фигыльне кайтым юнәлешендәге киләчәк заман фигыленә әйләндереп (*чыгарылачакбызмы*), аның мәгънәсен бозган.

Ногмани хәзрәтләренең тәфсиренә карасак, тагын да яман хәлгә шаһит булачакбыз: «*Кәферләр әйттеләр: «Без үлеп туфрак булсак һәм аталарыбыз да туфрак булсалар, шуннан соң терелеп кабердән чыгарбызмы?*». Үзенең тәфсирендә Ногмани сыйфат фигыль урынына киләчәк заман фигыль куеп кына чикләнми, аның юнәлешен дә үзгәртә (*чыгарбызмы*). Бу кадәр бозудан да азсынган кебек, тәфсиренә айәттә булмаган

*кабер* сүзен дә куша, ягъни, Аллаһ тәгалә Коръән айәтендә әйтмәгәнне әйтелгән итеп күрсәтә.

Югарыда китерелгән айәтне мәетләрнең терелтелеп каберләрдән чыгарылуы мәгънәсендә аңлау табигый булып күренә, дигән идек. Тик, айәттә сүз, чыннан да, мәетләр турында барамы икән?

Бу турыда фикер йөртеп алыйк.

Әлегә кадәр китерелгән айәтләрнең һәммәсендә дә бер хөкем кабатланып килде: кабердә һичкем калмый. Кәферләр нәкъ менә шушы хәбәрне, шушы хакыйкатьне кабул итә алмаганнарына күрә җавап йөзеннән: «*Бер генә мәртәбә яшибез дә, аннары үләбез һәм юкка чыгабыз*», – дия торган булганнар. Пәйгамбәрнең кабердә һичкемнең дә калмавы турындагы хәбәрен кабул итәр өчен адәм баласы ул хәбәрне башының як-ягындагы ике колагы белән түгел, күңеле белән, җаны белән, рухы белән ишетергә тиеш. «Минмин»леге нәфесенә береккән кеше ул хәбәрне ишетсә дә, аңлый алмый. «Минмин»леге нәфесенә береккән», димәк ни димәктер? Андый кешенең дөньяга карашы шайтан тарафыннан оештырыла. Ягъни, «Минмин»леге нәфесенә береккән кеше дөньяны шайтан күзлегеннән күрә. Кешенең дөньяга шайтан «киерткән күзлек» аша караячагын Коръәннән күрә алабыз: «***калә рабби фә-әнзыйр-ни илә йәүмин йубгасунә / калә фә-иннә-кә мин әл-мунзаринә / илә йәүми әл-уакъти әл-мәгълүми / калә рабби би-ма әгъуәйтә-ни лә-үзәййинәннә лә-һум фи әл-арды үә лә-үгъвийәннә-һум әҗмәгыйнә***» (15: 36–39). Ягъни: «[Иблис] *әйтте: «Раббым, аларның терелтеләчәк көннәренә кадәр мине кичектерсәнә», – диде /* [Аллаһ] *әйтте: «Чынлыкта, син вакыты мәгълүм булган көнгә чаклы кичектерелеп торучылардансың», – диде /* «[Иблис] *әйтте: «Раббым, минем адашуымны фаш иткәнең өчен мин алар өчен һичшиксез җирдә бизәкләндерәчәкмен һәм һичшиксез аларның һәммәсен дә адаштырачакмын*».

Шайтан «киерткән күзлек», дигәндә, маңгай күзенә киертелгән күзлек турында әйтелми, әлбәттә. Сүз шайтанның кеше күңелен, җанын томалап торуы турында бара. Дөресрәк итеп әйткәндә, күзләр кешенең үзенеке, колаклары да шулай, ә аның күргәннәрен, ишеткәннәрен кабул итүче, теге яки бу шәкелдә хәрәкәт иттерүче, гамәл кыйлдыручы булып шайтан үзе тора. Җепкә асылган курчаклар бар ич, рухы уянмаган кеше дә шайтан кулында уйнатылган әнә шундый курчакны хәтерләтә. Шуңа күрә, Аллаһы тәгаләне, үзен булдыручыны исенә төшергәнчегә кадәр, җан шайтан тозагында кала, аның кубызына бии. Мондый хәлдә адәм баласы һәрчак нәфесенең колы булып тора, нәфесенә буйсына, нәфесе кушканны кыйла: «***әш-шайтану йәгыйду-кум әл-фәкъра вә йәэмүру-кум би-л-фәхша'и...***» (2:268), ягъни: «*шайтан сезне фәкыйрьлек белән куркыта һәм сезгә яманлык* [кыйлырга] *боера*».

Кеше күңеле белән, җаны белән ишетә алсын өчен, ул күңел уянган булырга тиеш, уяу булырга, агәһ булырга тиеш. Ә күңел уянсын өчен нәфес үләргә тиеш. Нәфеснең үлүе дә, кешенең үлүедер, дигән сүз түгел. Әлбәттә, нәфеснең табигый үлеме бар, ул да булса, әҗәл җитүе нәтиҗәсендә, тәннән җанның кубарылып алынуы нәтиҗәсендә. Әҗәле җитеп кешенең гәүдәсе үлгәч, аның нәфесе үлми булдыра алмый. Үлеп киткән тәннән кубарылган җан исә, киресенчә, уяна. Уяна да, яңа булдырылыш кичерә. Пәйгамбәребез: «*Чынлыкта сез үлемнән соң янә терелтелүчеләрсез*» (11:7), – дигәндә әнә шул турыда кисәтә дә инде. Башка айәтләрдә телгә алынган «яңа булдырылыш», дигән нәрсә, минем фикеремчә, ул җанның җиргә кат-кат кеше гәүдәсендә килүе, димәктер. Җан ана карынында ук кеше яралгысына йөкләтелеп түбән яшәеш урыны булган бу дөньяга кителелә, Аллаһ язган кадәр тәндә кала, гамәлләр кыйла, аннары җанны үзендә йөрткән тән нинди дә булса бер сәбәптән үлә, кабергә салына. Тәннең үлүе дә җанның кубарылу вакыты килгәнгә күрәдер. Кубарылган җанга җирдә яшәгәндә тупланган әҗер-савапларына, гөнаһ-хаталарына күрә яңа тәкъдир языла, яңа тән, ягъни булдырылыш бирелә, җан янә кеше тәненнән гыйбарәт булган кабергә иңдерелә, туа, үсә, яши, кубарыла, җавапка тартыла. Шушы рәвешле күчеп йөрү, җанның бу рәвешле сәфәре бихисап мәртәбә кабатлана.

Минем фикеремчә, җәһәннәм өстеннән сузылган сират күперен узу ул җанның кеше тәннәрен алыштыра-алыштыра үсешен дәвам итүедер, җәннәткә таба, Аллаһка таба күтәрелүедер. Сират күпереннән егылып төшүне дә җанның яңадан бу дөньяга китерелүе буларак аңларга кирәк.

Җанның бу рәвешле тәннән тәнгә күчеп йөрүе, сират күперенә басып, аны үтәргә тырышуы никадәр дәвам итә? Аның чиге бармы? Туу белән үлемнән соң яңадан туып яңадан үлүдән котылу юлы бармы?

«Туу белән үлемнән, яңадан туу белән яңадан үлемнән котылуы», дидем дә, бу силсиләнең нәфес күзлегеннән генә шулай булуына игътибар иттем. Ә җан күзлегеннән караганда ул силсилә ничек күренә? Ә менә ничек: кеше тәненнән гыйбарәт булган кабергә салынып, ул тән үлгәч кубарылудан, яңадан кеше тәненнән гыйбарәт булган кабергә салынып, ул тән үлгәч яңадан кубарылудан гыйбарәт булган бу өзлексез чылбырның ахыры бармы? Сират күпереннән баруның ахыры бармы?

Ахыры бар, әлбәттә. Җаннарны шул туктаусыз газап әйләнешеннән коткару өчен Аллаһ тәгалә чыгу юлын күрсәткән, Коръәнне иңдергән, шәригатьне биргән, аң бирән, акыл биргән, кул-аяк, күз-колак биргән. Ягъни, караңгыдан яктыга ничек чыгасын тәфсилләп аңлатып та биргән, аңын өчен кирәк булган әсбапларны да биргән.

Асылда, сират күпереннән кат-кат узарга тырышып кат-кат җәһәннәмгә егылып төшүдән котылу өчен җан үзенең Раббысын, үзен бул-

дыручыны исенә төшерергә тиеш. Һәм бу искә төшерү җан әле кеше гәүдәсендә булган чакта, ягъни кабердә яткан чагында вакыйг булырга тиеш. Шулай булса, җан уяна, үзенең кабердә ятканын аңлап ала. Чын кыямәт, чын кубарылу шул инде ул. Монысы кыен, әмма мөмкин. Болай булганда, нәфес кеше әле исән чакта ук үлә. Нәкъ пәйгамбәребез әйткәнчә: «Үлгәнче үлеп кал!», – дигән булган ул. Башкача караганда, җан шайтан кулында әсир булудан котыла. Нәтиҗәдә, кешенең дөньяга карашы үзгәрә, чөнки аның күргәннәренә, ишеткәннәренә бәяне бирүче, ни кыйласын карар итүче булып шайтан түгел җан үзе була башлый.

Югарыда реинкарнациянең барлыгы турында белдерә торган байтак кына айәтләр китердем. Алар һәммәсе дә яшәешнең үлем белән тәмамланмавы турында, җаннарның туктаусыз рәвештә тәннән тәнгә күчеп йөрүләре турында хәбәр бирәләр. Монысы бер нәрсә.

Ә инде ул хәбәрне кабул итү яки кабул итмәү, аңа ышану яки ышанмау – икенче нәрсә. Югарыда бәян ителгән айәтләрнең күбесе Коръән укучыларны бу хакта да аңарта. Мәсәлән: «*безнең беренче үлемебез генә бар ич, һәм без һич тә янә терелтелүчеләр түгелбез*» (44:35), дигән айәтне алыйк.

Аңлашылганча, биредә сүз үлемнән соң яшәешнең дәвам итүенә инанмаучылар турында бара. Үлемнән соң яшәешнең дәвам итүен аңлау өчен кеше тәнендә, ягъни кабердә яткан җан уянган булырга тиеш, чөнки җанның яшәеше дәвам итә, акылныкы да түгел, тәннеке дә түгел, нәфеснеке дә түгел, җанныкы. Җаны уянмаган кешеләр: «*без һич тә янә терелтелүчеләр түгелбез*», дияләр. Болай дию табигый, чөнки үлемнән соң яшәешнең дәвам ителүенә бары тик җан гына ышана, дөресрәге – исенә төшерә ала, чөнки бу хакыйкатьне ул баштан ук белә килә.

Әмма җан Аллаһы тәгаләнең әмере белән генә уяна ала. Чөнки җаннарның Раббысы, ягъни аларны тәрбия[1] кыйлучы Аллаһ үзедер. Җанның нинди дәрәҗәдә торуын Аллаһ үзе генә белә. Дәрәҗәсе тиешле булмаганда Аллаһ андый җанны уятмый, ягъни аңа кыямәт кичертми. Ул гына да түгел, әзерлеге җитмәгән җаннарга Аллаһ тәгалә Коръәнне дә аңларга мөмкинлек бирми: «*Син Коръәнне укыганда ахирәткә инанмаучылар белән синең арада Без күзгә күренми торган пәрдә урнаштырдык / аны аңламасыннар өчен аларның йөрәкләренә япма яптык, колакларында чукраклык хасил кыйлдык...*» (17:45–46).

Шулай итеп, җаннары мәет хәлендә булу сәбәпле: «*безнең беренче үлемебез генә бар ич, һәм без һич тә янә терелтелүчеләр түгелбез*», дигән кешеләргә Аллаһы тәгалә җәһәннәм газапларын вәгъдә итә: «***хузү-һу фә-гътилү-һу илә сәүәи-л-җәхими***» (44:47), ягъни: «*аны алыгыз да җәһимнең үзәгенәчә өстерәп барыгыз*».

1 Рабб (тәрбия кыйлучы) сүзе белән тәрбия сүзе тамырдаш сүзләр.

Сүзебез Коръәнне укып та реинкарнация турындагы хәбәрне кабул итмәүчеләрнең хәлләре турында аңарта торган айәтләр турында бара иде. Тагын бер мисал:

«*Алардыр Раббылары белән очрашуны кире кагуычылар*» (32:10). Димәк, үлгәннән соң кешенең кабердә таркалып юкка чыгуына иналып, ул тәндә булган җанның шундук диярлек яңа тәнгә иңдереләчәгенә инанмаучылар Аллаһ тәгалә белән очрашуны да инкяр итәләр. Мондый кешеләр асылда җанның барлыгына, җанның мәңгелегенә, җанның Аллаһ белән очрашу өчен, кавышу өчен сәфәрдә булуына ышанмыйлар. Алар хәтта җанның барлыгына ышанмыйлар.

Әлегә кадәр Коръәндә реинкарнация турында ачыктан ачык хәбәр иткән айәтләрне китергән идек. Әмма бу күренеш турыда бәян итә торган башка төр айәтләр дә бар. Мәсәлән: «***Әйт: «Аллаһ сезне терелтә, аннан соң Ул сезне үлдерә, аннан соң Ул сезне аның хакында шикләнү булмаган Тураеп басу көненә туплый, ләкин кешеләрнең күбесе белми», – диген***» (45:26).

Ошбу айәтнең реинкарнация барлыгын ни рәвешле дәлилләвен аңлатыр алдыннан «Тураеп басу көне», дигән төшенчә турында бер-ике сүз әйтеп узыйм. «Тураеп басу көне», дип мин айәттәге «*йәүм әл-кыйамәт*», дигән гыйбарәне тәрҗемә иттем. Аны «Кыямәт көне», дип тәрҗемә итү гадәткә кергән. Әмма болай итү «кыямәт»нең нәрсә булуын ачыкламый, шуңа күрә бу сүзнең асыл мәгънәсе турында кешеләр хәбәрсез калалар.

Әлеге сүзнең мәгънәсен аңлар өчен аның чыганагы булган фигыльгә карарга кирәк, ул фигыльгә нинди мәгънәләр хас булуын күрергә кирәк. Кыямәт сүзенең башлангычы булып *кāмә*, дигән фигыль тора. Бу фигыльгә *аягүрә басып торырга, торып басарга, басып торырга; ятактан торырга (мәс.: камә мин нәүми-һи* / ул йокысыннан торды); *кубарга* (мәс.: *камәт әз-зәүбәгату* / буран купты); барлыкка килергә (мәс.: *камәт әл-фикра* / фикер барлыкка килде), *бар булырга*, һәм башка байтак кына мәгънәләр хас. Алар арасында *яңадан тере хәлгә килергә*, дигән мәгънә дә бар, урысча әйткәндә *воскресать* була. Табигый ки, тәфсир язучылар аны *каберләрдән кубарылу*, ягъни каберләрдә үле хәлдә яткан мәет калдыкларының терелтелеп җиргә чыгарылуы буларак аңлаганнар.

Хуш, шулай булсын ди. Әмма кабернең чынлыкта нәрсә булуын, һәм кубарылучының кем булуын истә тотканда, Кыямәт көне ул терелгән мәет калдыкларының җирдәге каберләрдән чыгуы түгел, кеше гәүдәсеннән гыйбарәт булган каберләр эчендә бикләнеп яткан җаннарның уянулары, *тураеп басулары* булып чыга. Мондый уяну ике төрле була: берсе кешенең әҗәле җитүе сәбәпле гомере өзелгәч була. Бу очракта нәфес мәҗбүри

сурәттә юкка чыгарыла һәм нәфес идарәсе астында булган җан үзен әсир итеп, буып, богаулап тотучы көчтән котыла. Уянуның икенче төре кеше әле исән чакта ук нәфесне җиңгән җанның үзенең Кем катыннан килгән булуын, ни өчен кабергә салынган булуын исенә төшергәненнән соң була. Бу очракта җан Аллаһ ярдәме белән нәфеснең әсире булуыннан җан тәннән кубарылганчы ук үк котыла һәм кыямәт кичерә, уяна гына түгел, терелә, чөнки Раббысын исенә төшерә.

Инде баягы айәткә әйләнеп кайтыйк: «***Әйт: «Аллаһ сезне терелтә, аннан соң Ул сезне үлдерә, аннан соң Ул сезне аның хакында шикләнү булмаган Тураю көненә туплый, ләкин кешеләрнең күбесе белми», – дигән***» (45:26).

Бирәдә «***Аллаһ сезне терелтә***», дигән сүз Аллаһның җаннарны булдыруын белдерә. «***... аннан соң Ул сезне үлдерә***», дигән сүз һәр җанның аңа ризык итеп бирелгән кеше гәүдәсенә, кабергә иңдерелүен белдерә. Бу хәлдә калган җан мәеткә әйләнә, чөнки Раббысын исенә төшерүдән гайбарәт булган иң мөһим вазыйфасын онытырга мәҗбүр ителә. «***... аннан соң Ул сезне... Тураеп басу көненә туплый***», дигән җөмлә җаннарның «түбән булган яшәеш» мәйданына китерелүләрен белдерә. Җир йөзендә кеше гәүдәсе эчендә бикләнгән хәлдә «яшәүче» җаннар әнә шул тураеп басулары киләчәк сәгатьне көтәләр. Җан өчен тураеп басу, чын кыямәт кичерү бары тик шушы дөньяда гына мөмкин, тик моны «***кешеләрнең күбесе белми***».

Тагын бер кызыклы айәткә күз салыйк: «Әйт: Яшерен булганны Аллаһтан кала күкләрдәгеләр дә, җирдәгеләр дә белмиләр. Алар хәтта җибәрелгән чакларын да сизмиләр. Әмма ахирәттә аларның белеме үзләренә ирешәчәк. Тик алар аның хакында шикләнәләр, аңа карата алар хәтта сукырлар» (27:65–66).

Бу айәттә Аллаһы тәгаләгә генә мәгълүм *яшерен булган* (әл-гайб), дигән төшенчә искә алына. Айәттә әйтелгәннәрдән аңлашылганча, ошбу *яшерен булган*, дигән төшенчәнең җаннарның халәтенә дә катнашы бар. Ягъни җаннарның билгеле бер халәте турында Аллаһ кына белә булып чыга. Ул нинди халәт? Минемчә, биредә сүз җаннарның кеше тәненә иңдерелеп җиргә җибәрелүләре турында бара. Дөньяга килгәч җан үзенең кайдан килгәнен оныткан булып чыга, моны сизми: «***алар хәтта җибәрелгән чакларын да сизмиләр***». Ягъни җан үзенең кеше яралгысына иңдерелер алдыннан булган терек халәтен хәтерләми. Аның бу халәте җан өчен әл-гайб була, ягъни яшерен була. Әлбәттә, шулай булырга тиеш, чөнки җан дөньяда яши башлаганчы үзенең терек халәтен исендә тотса иде, ул чакта андый җан бу дөньяның сынау мәйданы булуын, үзенең кабергә салынган мәет булуын аңлар иде. Аңлады исә, сынау тәмам булыр

иде. Биредә, ягъни бу түбән яшәештә булуның мәгънәсе дә бит җанның шул Аллаһ хозурындагы мәңгелек яшәешне, үзенең дә мәңгелек булуын исенә төшерүенә кайтып кала.

«***Әмма ахирәттә аларның белеме үзләренә ирешәчәк***», дигән айәт җанның тән тозагыннан, кабердән котылганнан соң Аллаһ хозурына алынуын һәм шуның нәтиҗәсе буларак бөтен *әл-гаебне* исенә төшерүен, ягъни кямил белем иясенә әйләнүен белдерә. Тәннән кубарылып Аллаһ хозурына алынуы белән җан өчен ахирәт башлана, ягъни ул башка төрле яшәешкә ирешә. *Ахирәт*, дигән сүзнең дә мәгънәсе *башка төрле, үзгә* димәктер.

Айәтнең «***тик алар аның хакында шикләнәләр, аңа карата алар хәтта сукырлар***», дигән өлеше җаннарның кабердә яткан чакта нинди халәттә булуларын тагын бер кат искәртә: җан мәет булганда, ягъни кеше тәнендә яшәгәндә, җаны үле булганда кеше ахирәт барлыгына ышанмый, аның хакында шикләнә, барлыгын күрергә теләми, чөнки сукырдыр. Биредә сүз, әлбәттә, маңгай күзе турында түгел, җан күзе турына бара. Җан үзенең мәңгелек булуын үз күзе белән күргәндәй аңламаса, *якыйни иман* иясе ителмәсә, үзенең бу табигатен танымаса, шул кабердә кала бирәчәк, кабере искереп җимерелгәч, яңа кабергә иңдереләчәк, ул кабере тузгач, яңа кабергә...

Үзенең Аллаһтан булуын, Аның белән бәйләнештә булырга тиешлеген исенә төшергәнче, шул бәйләнешне торгызганчы җанның кабердә яшәеше, мәет булуы, тәннән алыштыра-алыштыра Аллаһка таба кайтарылуы дәвам итәчәк.

Җан уянгач, үзенең кайдан китерелгәнен, ни өчен китерелгәнен, кемнәнә булуын исенә төшергәч аның кабердә ятуы тәмам була да, җан кыямәт кичереп яшәешнең оҗмах дип аталган яңа баскычына күтәрелә. Бу турыда бик гыйбрәтле айәт бар: «***анда*** [оҗмахта] ***беренче үлемнән башка үлемне татымаячаклар. Ул аларны тәмугъ газабыннан коткарды***» (44:56).

Бу айәттә искә алынган «беренче үлем» җанның бихисап мәртәбә кеше тәненнән гыйбарәт булган каберләргә иңдерелеп, түбән дөньяда мәет хәлендә кичергән халәтен белдерә. Җан кеше гәүдәсендә җиргә ничә генә мәртәбә килмәсен, Раббысы белән элемтәне корганчыга кадәр мәет булып кала, ягъни үле була, үлем халәтен кичерә. Аның бу халәте «беренче үлем», дип атала. Раббысы белән бәйләнешне торгызган җаннар өчен Аллаһның рәхмәте белән терелеп, каберләреннән чыгу юлы ачыла. Андый җаннар оҗмах ияләре ителәләр. Биредә аларны мәңге терек булу халәте, мәңгелек яшәеш көтә. Шуңа күрә җәннәттә ул җаннар «***үлемне татымаячаклар***».

## Юбилярлар турында сүз

## Слово о юбилярах

# «АВЫЗГА СУ КАБЫП ЯШИКМЕНИ?!»

### Рәшит Минһаҗ белән әңгәмә

*– Мине бәйләнчек дип әйтә торганнардыр. Тел һәм милли мәсьәләләр турында сүз чыга икән, чәчрәп чыкмыйча булмый. Чөнки җәмгыятьтә – битарафлык чире. Син дә, мин дә авызга су капсам, кем дәшәр? Бу көннәрдә 60 яшен тутырган журналист Рәшит Минһаҗ белән әңгәмә әнә шулай башланып китте.*



Журналистны бүгенниләр борчый? Татар матбугаты ни хәлдә? Без әнә шул сорауларга ачыклык керттек.

– «Мәдәни җомга» газетасында Алмаз Хәмзиннең татар матбугаты турында шигыре дөнья күрде. Ничек уйлыйсыз, матбугатның хәле чыннан да мөшкелме?

– Матбугатның хәле яхшы дип әйтеп булмый. Бу журналистларның үзләренә дә, илдәге вәзгыятькә дә бәйле. Без Ельцин заманында алган мөмкинлекләрне, ирекләрне югалттык, илдә хакимият вертикале отыры

көчәя бара. Журналистлар, чыннан да, бәладан – башаяк, дип яши башлады. Күптән түгел «Күңел» радиосы күңелне кайтара торган гамәл кылды. Алып баручы хәтта коммерция шартларында да, халык шагыйре Роберт Миңнуллинның, туган тел хакына үз-үзен яндырган удмурт галиме Альберт Разинга багышлап язылган шигырен укудан баш тартты. Цензура, беренче чиратта, үзебездә утыра. Үзебез кыюрак булсак, газета-журналлар, тапшырулар да эчтәлеклерәк булыр иде.

– ***2016 елгы тел кризисында*** журналистлар үзләрен ничек тотты?

## Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр

## Информация о краеведческих трудах. Рецензии

*Зәрия Хәбипова*

### «КАРАБӘК» РОМАНЫ ТУРЫНДА

Һәр китап укучы өчен языла. Шул уйдан чыгып, танылган язучы, күп әдәби бүләкләр иясе В. Имамовның соңгы тарихи романы турында берничә сүз әйтмәкче булам.

Язучы Алтын Урда дәүләтенең таркалуга барган чорын әдәби яссылыкта сурәтләүгә алынган. Татар дәүләте өчен бик катлаулы һәм фаҗигале чор бу. «Казан утлары» яңа басылган роман хакында түгәрәк өстәл артында сөйләшү дә үткәрде һәм анда катнашкан мөхтәрәм затларның фикерләре журналның 2017-нче елгы № 10-нчы санында басылып та чыкты.

Дастан герое Идегәй «Карабәк» романында үзәк фигура кебек күренмәсә дә, чорны сурәтләгәндә аны әйләнеп үтеп, яки «Золотая Орда» балетындагы кебек, исемсез итеп биреп булмый. Идегәй әмир – тарихи шәхес. Аның исеме белән дастан барлыкка килгән икән, бу бит юктан түгел, димәк аны таныганнар. Әлбәттә, һәркемнең үз фикере. Роман авторы Вахит әфәнде Идегәй турында: «Әллә үз кавеме – мангыт шагыйрьләре, әллә Алтын Урда дәүләтенең бөеклеген инкяр иткән төркемнең максаты нигезендә туган дастан буенча, Идегәй морза бүгенге көнгә чаклы халык хәтерендә уңай герой саналып йөри.», – дип белдерде [Казан утлары: 2017. № 10. 126 б.].

Фикер төгәл әйтелгән: беренчедән, дастан Алтын Урданың бөеклеген инкяр итә, икенчедән, Идегәй «ләгънәт белән телгә алудан башкага лаек булмас» [шунда ук]. Әлеге сүзләрдән Вахит әфәнденең Идегәй шәхесенә каты нәфрәтле булуы, дастанны күрә алмавы аңлашыла. Ләкин язучының кискен һәм тискәре карашы гына дастанны һәм аның героен халык хәтереннән сызып ташларлык сәбәп була алмый. Язучы романында үз карашын нинди тарихи фактларга таянып ача, бу дөрес дәлилме, үз фикереме? Менә бит нәрсә әһәмиятле.

Әсәрдәге кайбер күзгә ташланган кытыршы дәлилләргә күчкәнче, ата-бабаларыбызның үткән дәүләтчелек тарихын кыскача күзаллап үтик. Татар дәүләтчелегенең тамырлары бик тирәндә. Тарихчылар аны ике мең

елдан артык та, ким дә түгел диләр. Татарларда шул чорларда ук дәүләт тотуның үз тәртибе бирлыкка килгән. Башта «дәүләт», «ил» сүзләренә игътибар итик. Һәр ике сүз дә уңай мәгънә йөртә, байлык, берләшү кебек аңлашыла. «Илбәк», «илхан», «ил башы» кебек сүзләр дә тискәре караш тудырмыйлар, илне коручы, җитәкләүче буларак күз алдына киләләр. Төрки каһаганлык чорына караган Орхон-Енисей язмаларыннан күренгәнчә, ил башлары V гасырларда да үзләрен шундый җитәкче итеп күрсәткәннәр һәм тышкы дөнья да аларны шул сыйфатта таныган. Кытай елъязмаларында Төрки каһанлыкта дәүләт белән идарә итү тәртибе турында мондый сүзләр сакланган: «Аларда идарә итү тәртибе бик гади. Хаким белән халык арасындагы мөнәсәбәтләр нык һәм дәвамлы» [Паркер: 2009].

Һәр дәүләтнең нигезе – халык, аның үрчеп, күп булып, ныклы эшчәнлек алып барып яшәве һәм шул яшәешне тәэмин итә һәм үстерә алырлык идарә (безгә аны элегрәк базис һәм өскорма дип аңлаталар иде). 100 меңлек гаскәрне сугышка алып чыкканчы, аны кемдер киендерергә, ашатырга, корал ясарга, өйрәтергә тиеш бит. Әкияттә генә ул сызгырсаң барсы да була. Дөнья төрки-татарларның тормышны һәм гаскәрне оештырудагы өстенлекләрен таныган, юкка гына Һиндстан, Кытай һәм башка илләрдә хакимлек итмәгән бит алар. Дөресрәге, үзләрен танытканнар безнең бабайларыбыз. Аларның дәүләт белән идарә итү тәртибен башка дәүләтләрнең өске катламы да өйрәнгән, идарә өлгесе итәргә тырышкан. Монда Чыңгыз ханның бөек Ясасын искә төшереп китү дә урынлы булыр. Алтын Урда дәүләте дә Яса нигезендә идарә ителгән бит.

Бөек Ясаның таләпләре бик гади: алдашмау, урлашмау, әйткән сүзгә тугры калу, хыянәт итмәү, диннәрне хөрмәт итү һ.б. Нәкъ шушы таләпләр христиан дөньясының бугазына сөяк булып утырган да инде. Рим папасы үзен җир йөзендә Алла тарафыннан утыртылган бердәнбер хаким дип санаган. Ә бу кыргыйлар нindидер тигезлек, диннәр ирекe, алдашмый хакимлек итү турында кануннар чыгарып яталар имеш. Халыкларны исә һәр кешегә аңлаешлы уртак уй, уртак тәртип, гадел таләпләр ныграк берләштерә. Әгәр гади халык Яса таләпләре турында белсә, алар бит чиркәүне, Рим папасын танымаячак! Моңа һич юл куярга ярамый! Бетерергә аларны. Римдә шуны да яхшы аңлаганнар: Яса кануннарын җимермичә Алтын Урда дәүләтен җиңеп булмый. Шуңа да Рим чиркәве Алтын Урда белән көрәштә бар ысулларны да мул кулланган: шымчылар, ялган хәбәр таратучы провакаторлар җибәргән, байлык белән котырткан, үз уен һәр очракта тыңлаучының колагына салырга тырышкан.

«Агач башын җил бора, адәм башын сүз бара», – ди мәкаль. Алтын Урда дәүләтенең өске катламында Ясадан читләшү теләге барлыкка килгән, ахрысы. Заман үзгәрде дибез, заманны бит кеше уе үзгәртә. Заман-

ның ничек үзгәргәнен Никколо Макиавелли [Макиавелли: 2009. Ч. XVIII] бик ачык язып калдырган:

«Излишне говорить, сколь похвальна в государстве верность данному слову, прямодушие и неуклонная честность. Однако мы знаем по опыту, что в наше время великие дела удавались лишь тем, кто не старался сдержать данное слово и умел кого нужно обвести вокруг пальца: такие государи в конечном счете преуспели куда больше, чем те, кто ставил на честность.»

Әйе, әкеренләп дәүләтләр арасында башка уен кагыйдәләре өстенлек алган. Ә Алтын Урда үзенең Яса кануннары белән бу уенда чит – ят карачкы хәлендә калган. Һәм аңардан әкеренләп карачкы ясаганнар да.

1342-нче елда Алтын Урда хакиме Үзбәк хан бакыйлыкка күчә. Тәхеткә дәгъва кылучы Чыңгызыйлар бик күп була. Яса таләбе бозыла – хан сайлауны корылтайда хәл итү читкә кагыла. Шунда таркалуга беренче адым ясала да инде. Тәхет тирәсендә ыгы-зыгы, үзара суеш-үтереш башлана. Бу фетнәләр 20 ел дәвам итә. Шул елларда тарих мәйданына мәкерле, аяусыз Аксак Тимер күтәрелә. 1370–1405-нче еллар – Аксак Тимернең канлы йолдызы балкыган чорлар. Ханнар, дәүләтләр һәрчак аның каты кулын тоеп торган.

Ул чорның өске катламында туганлык бәйләнешләре булуы да билгеле – Идегәйнең кыз туганы Аксак Тимердә кияүдә булган. Димәк, җиһангир аңа җизни тиеш, ә Туктамыш – Чыңгыз нәселеннән булуы белән Аксак Тимергә кирәк. Хан итеп Чыңгызыйларны гына утырткаганнарын беләбез. Туктамыш, белән Идегәй бер даирәдә кайнаган дияргә нигез бар. Туктамышның туган елы төгәл күрсәтелми, XIV гасыр уртасы дип кенә бирелә, Идегәй Википедиядә 1352-нче елда туган дип күрсәтелә, бу да бик үк төгәл түгел (бәлки, 1356-нчы елдыр).

В. Имамов романда Идегәйне Туктамыш кызына өйләндерә. Күрәсең, Туктамыш үзе бик иртә өйләнгәндер, шуңа яшьтәше, кордашы Идегәйгә кияүгә бирерлек кызы булгандыр дип без дә ышаныйк ди. Ул шуның аркасында гына гаскәр башы булган дип бара автор. Идегәй имеш «бернинди яуларда да дан казанган сәрдәр түгел әле, башы керсә, бүксәсе кермәгән дигәндәй...», яу турында сүз барган мәҗлестә чәчрәп чыгып, үзен күрсәтергә омтыла. Ә Идегәйне күреп, ишетеп, белгәннәрдән сорашкан тарихчы Ибне Гарәбша аны башкачарак сурәтли: «Ул кара кучкыл йөзле, урта буйлы, нык гәүдәле, кыю, гайрәтле, зирәк акыллы, юмарт, якты елмаючан, үткен күзле, тирән фикерләүчән...». Әлбәттә, язучы үзенең фантазиясендә ирекле, ләкин Идегәй кебек тарихи шәхесне сурәтләгәндә аны яманлап, кара ягып кына күрсәтү берьяклы яңгырый.

Тагын тарихка күз салыйк. Максатларына ирешкән кебек тоелган бу өчлекнең аралары тиз бозыла – Туктамыш, хан булгач, Аксак Тимер үзе-

неке дип санаган җирләрне яулап алырга омтылып (котырту буенчамы), берничә тапкыр гаскәр белән аңа каршы сугышка күтәрелә, Идегәй әтисен Туктамыш кушуы буенча үтергәннәрен белгәч, үзенә дә шул язмыш килүдән куркыпмы, җизнәсе янына кача. Бәлки куркып та түгел, үзе үч алырга план корыптыр – Идегәй Аксак Тимерне Туктамышка каршы яу белән барырга өнди башлый. 1390-нче елда Аксак Тимер бу фикерне кулай күрә, зур гаскәр җыеп Алтын Урдага яу белән килә. Яуда Идегәй дә катнаша. Сугыш 1391-нче елда Кондырча буенда була, анда Туктамыш җиңелә.

Бер сорау куярга кирәк – Аксак Тимер чит кеше коткысы белән йөри торган яугир булды микәнни? Аның һәр адымында чынлыкта үз максаты булган бит. 1391-нче елгы сугыштан соң ул башка төбәкләрне яуларга китә, 1395-нче елда кабат Алтын Урда өстенә килә. Туктамыш сугышны булдырмаска тели, илчеләр җибәреп тәүбә иткәнен белдерә, әмма Аксак Тимер аңа ышанмый. Идегәй сугышта катнашудан баш тарта, «элекке кылганнарым өчен дә үкенәм», – дигән сүзләре сакланган.

В. Имамовның Идегәйне әдәби герой буларак ачуның төп алымы – аны төрле начар сүзләр белән мыскыллау, сүгү, ул сүзләрне әсәрнең башка персонажлары авызыннан да әйттерү. Романда Аксак Тимер Идегәйгә шикләнеп карый. Гаскәр бирми, 10 мең гаскәрне аңа мангытлар җыеп биргән имеш. Шул гаскәр белән яңадан Аксак Тимер катына килә. «Этҗан, сатлык, соран – Идегәй», – Тимер шулай уйлый. «Идегәй соран, бу җиһанда синең Газраилең мин булырмын», – бусы Хәсән авызыннан. Роман азагында Идегәйне Хәсән үтерә. «Синең хәтта татар туфрагында күмелергә дә хокукың юк!» – бу әсәрнең соңгы сүзләре.

Пафос белән әйтелсә дә, соңгы сүзләр тарихи дөреслеккә туры килми. Бердән, Хәсән кайчан яшәгән, очрашканмы ул Идегәй белән? Үзе Идегәйдән алдарак үлгән түгелме? Икенчедән, Идегәйнең күмелгән урыны билгеле һәм ул изге урын саналган. Татар җирендә хокукына килгәндә, аны Идегәйнең оныклары дәвам иткән – Нугай Урдасы, Сөембикә ханбикә, кнәз Йосыпов, Урысовлар аның дәвамчылары бит. Идегәйнең ерак оныклары рус патшаларының киңәшчеләре булганы билгеле. Тарихта һәрберсенең үз эзе бар. Ничек карасак та, Идегәйне үз заманыннан аерып, бүгенге көн күзлегеннән чыгып бәяләү дөрес булмас. Шул тарихи җирлек тудырган көчле, фаҗигале шәхес ул. Уйлавымча, дәлил рәвешендә алынган мыскыллы сүзләр генә Идегәйнең шәхес биеклеген түбәнәйтә алмый. Замандашлары көчле, курку белмәс, гаярь ир-егетне күргәннәр Идегәй йөзендә. Заман идеалы шундый булган.

Безнең узган югалтулар (соңгы 100 елны гына алсак та), үткәннәрне ачык күзалларга комачаулый, аңыбыз үзебез кичкән мескенлектән котыла алмый. Хакимлек дилбегәсе кулдан төшкән, үткәннәр турында тирән белем

туплау, тышкы дөнья белән иркен аралашу мөмкинлегебез юк дәрәҗәсендә. Ә элеккеләрнең фикерләү колачы башка – алар илләр җыеп, дөньяда үз тәртипләрен урнаштырырга омтылып яшәгәннәр, шуңа уй-хыяллары, омтылышлары күктә, биектә булган. Идегәйнең көрәш максаты да дастанда ачык әйтелгән – ул Алтын Урданы Чыңгыз хан заманындагы кебек киңәшле йорт итү өчен көрәшә, ягъни Яса таләпләрен кайтарырга тели.

«Агаларны алдырып,
Киңәшсез үскән бу йортны
Киңәшле йорт кылдырды», – диелә дастанда. [Идегәй: 1988. 168 б.]

* * *

Түгәрәк өстәл артында барган әңгәмәдән хөрмәтле затларның «Идегәй» дастанын бик бәяләп бетермәүләре аңлашылды. Дамир Исхаковның Идегәйне каралтып күрсәтүгә каршы чыгып: «Сөйләшүләр алып барганда, үзебезнең милли, героик шәхесләрне дөрес күрсәтергә кирәк», – дигән фикере һавада эленеп калган кебек булды. Ә дастан Алтын Урда дәүләте таркалуга барган чорда (XIV йөз ахыры – XV йөз башы) Туктамыш белән Идегәйнең фаҗигале көрәшен Гётеның «Фаусты», Шекспир драмалары югарылыгында сурәтләп, мәдәниятебез биеклеген дөнья күләмендә күрсәтерлек әсәр булып тора. Безнең бөтен бәлабез – дастанны тирәнтен өйрәнмәүдә һәм халыкка җиткермәүдә. Әйтерсең 1944-нче елның 9-нчы август карары һәм аны кабул иткән кешеләр бүген дә безнең арада яшиләр. Дастанның әһәмиятен бик төгәл ачып биргән философ һәм эзотерика белгече Рашат Сафинның сүзләрен укучыга ишеттерәсем килә: «Идегәй» дастанында илаһи идарәчелектәге тәртипнең дөньяви җитәкчелектәге чагылышы тасвирлана; бу – татарда метафизик караш булганын, җәмгыять тормышын (безнең) шул югарылыктан анализларга сәләтлелеген күрсәтүче дәлил».

Әйтәсе килгәннәрем шулар иде. Ялгышам икән, белгән укучы мине төзәтер.

### Әдәбият


1. Идегәй. Татар халык дастаны. Казан: Татар кит. нәшр., 1988.
2. Казан утлары. 2017. № 10.
3. Макиавелли Николо. Государь. М.: АСТ, 2009.
4. Паркер Эдуард. Татары. История возникновения великого народа. М.: Центрполиграф, 2009.

# МУСА АБДУЛЛИННЫҢ «Ә НАРАТЛАР ШАУЛЫЙЛАР ДА ШАУЛЫЙЛАР...» КИТАБЫНА АННОТАЦИЯ

Китап Татарстанның Байлар Сабасы төбәгендә яшәүче Муса Абдуллин тарафыннан иҗат ителгән. Ни өчен ул «Ә наратлар шаулыйлар да шаулыйлар...» дип атала соң? Чөнки китапның беренче бүлеге авторның тормыш юлын чагылдырып, шушы исем астында дөнья күргән. Бу бүлектән күренгәнчә, М. Абдуллин беренче класска кергән 1964-нче елда әтисе Мәхмүт һәм ике абыйсы белән урманнан алып кайтып бакча башындагы елга кырыенда буш яткан урынга «Һәр гаилә әгъзәсенә бер агач», дигән лозунгтан чыгып җиде нарат агачы утырталар. Китапның авторы тормыш юлын тәбигатьтә шаулап үскән шушы җиде нарат агачы белән бәйли, чөнки армия хезмәтенә кадәр үзен карап үстергән Гәлимә әбисе белән бертуган Сәүбән абыйсын, районда бердәнбер Ленинград блокадасында катнашкан матрос – яраткан әтисе Мәхмүт һәм сөекле әнисе Минсрүрне, армиядән кайткач бертуган сеңлесе Ләлә һәм абыйсы Харисны җирләп 20 яшьлек егет тормыш юлы чатында бер үзе басып калган була. Бакча башындагы җиде нарат агачы гүя аның гаиләсе, төрле корылыкларга, ачы җилләргә бирешмичә үсүләрен дәвам итәләр. Алар көн дә Мусаны, аның тормышын күзәтеп, бу якты дөньяда авырлыкларга бирешмичә, аларны җиңеп яшәвен телиләр кебек тоела китап авторына.

Китапның тышлыгында икенче исеме «Саба – тарихым минем», күзгә чалынып китә, чөнки хезмәтнең күпмедер өлеше Байлар Сабасы тарихын чагылдыра. Төбәкнең борынгы бер исеме (Мәмәт Бушлыгы), аның үзгәреп яңа исем алуы (Байлар Сабасы) нигә бәйлелеге, анда 1832-нче елгы пожарга кадәр Минзәлә өязе Ташлыяр авылында 1779-нчы елда туып үскән бу төбәккә килеп зур фабрикалар тоткан Бикчәнтәй Абалаков язмышын, аннан соң яшәгән күп кенә байларның тормыш юлларын, төбәк өчен үзенчәлекле үзгәрешләрне эченә алган бу хезмәт, шулай ук беренче мәктәпләр һәм аннан соңгылары, төбәктәге мәчетләр, аларның салыну еллары, мәдрәсәләр тарихы һәм ул якларда хезмәт иткән имам хатиплар турындагы язмалар да бар монда.

Шулай ук бу әсәрдә фашистик концлагерьда тоткынлыкта яшәгән кешеләр турында эзләнүләр, Байлар Сабасында беренче ир-ат һәм хатын кыз трактористлар турында, сугыш чоры балаларының башларыннан үткән чын тормыш юллары һәм тормышта шәхесләр сөйләп калдырган үкенечле ялгышлыклары, ахырдан очрашулар, яраткан әниләребезгә багышланган хикәяләр дә кергән китапка.


Муса Абдуллин
Ә наратлар шаулыйлар да шаулыйлар...
Саба – тарихым минем

## 2019 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ЯЗМАЛАР ИСЕМЛЕГЕ


Ел йомгаклары һәм алдагы бурычлар. №4.

***Киләчәккә юл: Татар стратегиясе – 2050***

*Бәйрәмова Ф. Ә.* Шаукыммы, әллә соңгы шансмы? №1.

*Гатауллин Р. Ф.* Этник җитештерү механизмы. №1.

*Искәндәров Г. А., Лотфуллин М. В.* Татар матур яшәсен! Татар халкының үсеш стратегиясенә. №2.

«Киләчәккә – көннән-көн». Төмән өлкәсе Себер татарларының тормыш шартларын нәтиҗәле үстерү стратегиясе. №2.

*Мириханов Н. М.* «Татар халкының үсеш стратегиясе»нә кертү өчен тәкъдим ителгән юнәлешләр һәм темалар. №1.

Мәскәүнең Люблино районы ТҖМММ иҗтимагый оешмасы рәисеннән «Татар халкының үсеш стратегиясе»нә тәкъдимнәр. №2.

*Надиров А. К.* Татар халкының үсеш стратегиясе. №2.

*Нигъмәтҗанов Т. Т.* 2020–2050 елларга халыкның, татар теленең һәм мәдәниятенең иҗтимагый үсеш стратегиясен күзаллау. №1.

Редакциягә хат. №1.

Редакциягә хат. №2.

Стратегия әзерләүчеләргә хат. №2.

Татарстан Республикасының БДБ илләрендәге вәкиллекләре тәкъдимнәре. №2.

Татарстан Республикасының РФ төбәкләрендәге вәкиллекләре тәкъдимнәре. №2.

«Татар халкының үсеш стратегиясе» структурасы. №3.

***Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары***

*Бакиров М. Х.* Болгарга тоташкан тамырларыбыз. №3, 4.

*Гатауллин Р. Ф.* Милли мохитнең асылы һәм чикләре. №3.

*Гатауллин Р. Ф., Аслаева С. Ш.* 1990–2017-нче елларда Башкортостан Республикасындагы институциональ үсешнең төп контурлары. №4.

*Измайлов И. Л.* Үзәк Азиядәге борынгы татарлар (VI–IX гасырлар). №2, 3.

*Исхаков Д. М.* Халкыбызның эпик әсәрләрендә яшеренгән милли тарихыбыз. Икенче язма: «Идегәй» дастанының серләре. №1, 2.

*Исхаков Д. М.* Халкыбызның эпик әсәрләрендә яшеренгән милли тарихыбыз. Өченче язма: «Чура батыр» дастаны һәм «киләчәк буыннарны кисәтү». №3, 4.

*Кыямов И. Ә.* Саваплы мирас нечкәлекләре. №1.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Иделдәнме, Себердәнме син, Идегәй? №1.

**_Төбәк тарихы буенча фәнни мәкаләләр_**

*Алексеев И.Е.* Мәрьям Ана иконасы барлыкка килү тарихында «татар эзе»... №3.

*Борһанов А.А.* Иске-Казан тарихи-мәдәни һәм табигый комплексы һәйкәлләре. №1, 2.

*Бугарчёв А.И., Степанов О.В.* XV гасыр тәңкәләренең Олы Әтрәч авылы тирәсендәге хәзинә янчыгы (Татарстанның Тәтеш районы). №1.

*Бугарчёв А.И., Степанов О.В.* Маклашеевка авылыннан (Татарстан) Җучи тәңкәләре. №2.

*Бугарчёв А.И., Степанов О.В.* Татарстан Республикасы Әлки районыннан нумизматик материаллар. №3.

*Бәйрәмова Ф. Ә.* Новосибирск өлкәсендә татар тарихы. №1.

*Бәйрәмова Ф. Ә.* Самар ярымутравында татар тарихы. №2, 3.

*Бәйрәмова Ф. Ә.* М.Г. Худяковның Татарстан тарихына керткән өлеше. №4.

*Гариф Н.Г.* Казан ханлыгы чорына караган эпиграфик ташларны барлау һәм аларга статистик анализ. №4.

*Голодяев К.А.* Новосибирск шәһәрендә борынгы Чат авылы җирлеге һәм соңгы Себер ханының көрәше. №1.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Риваятьле, җырлы-моңлы Самара. №2.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Әстерхан татарларында үзенчәлекле сәнгать төре – хушавазлар. №4.

*Нуриева Ф.Ш.* Татар халкы кулланган еллар, айлар һәм көннәрнең атамалары хакында Хәсән Гали язмасы. №3.

*Саначин С.П.* Казан Богородица иконасы барлыкка килүенең һәм Гермоген биографиясенең ике рәсемле повесть буенча яңа нечкәлекләре. №3.

*Хисамов О.Р., Гомәров И.Г., Закирова И.Г.* Ангараның буйларында Өркет дигән кала бар. №1.

*Худяков Ю.С.* Урта гасырлардагы борынгы төркиләрнең дәүләтчелеген үстерү – дала Евразиясендәге төрки цивилизациянең үсешендә әһәмиятле этап. №1.

*Әмирханов Р.Х., Габдуллин И.Р.* Нефть сәнагатьчесе Надыр Уразмәтов һәм аның заманы. №2, 3.

**_Фәнни-популяр язмаларда төбәк тарихы_**

*Абдуллин М.М.* Сабам – минем тарихым. №1.

*Биккинин И.Д.* XVIII гасырдагы Пенза губернасы татар солдатының эстон хатыны. №2.

*Биккинин И.Д.* XVII гасыр башындагы Мордовия үзәгендәге татар зонасы. №4.

*Вәли Р.К.* Болак артында ни бар? №1.

*Газизов Р.Р.* Самара шәһәр берәмлегенең «Яктылык» мәктәбе. №2.

*Гариф Н.Г.* Нәсел тамырыңны барлыйм дисәң... №3.

*Газизьянова С.М, Сабирьянова Ф.Ф.* Татар төбәкләре тарихын өйрәнүне үстерү һәм Мари Эл республикасы татар авылларының туристик потенциалы. №4.

*Гыйльманов Ф.М.* Чуракайның Пенза татарлары. №3.

*Гыймадиев М.М.* Иске Шәйморза авылы тарихыннан. №3.

*Закирова И.Г., Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Халык җәүһәрләре сагында. №3.

*Мәхмүтов Ф.С.* Самара татарлары. №2.

*Надыров А.К.* Без мең ел буена сузылган юлны ачтык. №2.

*Нигъмәтҗанов Т.Т.* Җиде муза-алиһә клубы. №3, 4.

*Салиев Р.З.* Исламга кайту. №4.

*Сибгатова Э.М.* Пугачёв явы каһарманы. №2.

*Таҗи Д.Н.* Кыям Җәгъфәрев: автобиографик истәлекләр. №1, 2, 3, 4.

*Хабибиуллин А.А.* XX–XXI гасыр башы үзгәрү шартларында Идел буе Саратов татарларының милли телен саклап калу. №4.

*Хәбипова З.Г.* «Идегәй» дастанының яңа басмасы турында. №1.

*Хәмзина Р.К.* Чат татарларының тарихи яшәү урыны. №1.

*Хөсәинов С.Ә.* Сәхип-Гәрәй ярлыгы хакында уйлану. №4.

*Әскаров Р.Р.* Кыйгы Терегуловлары. №4.

***Мирасыбызның төбәк тарихына кагылышлысы***

«Идегә» дастаны. №1, 3, 4.

*Закирова И.Г.* Әйтүкә җырлары. №1.

*Закирова И.Г.* Ак Күбек. №4.

*Яхин Ф.З.* «Мәликә китабы» тарихы. №1, 2.

***Төбәк тарихына караган тарихи чыганаклар***

XVIII гасыр Томск губернасы татарлары буенча документаль материаллар. №1.

Геодезия укучысы Павел Зубринскийның Надыр Уразмәтов бакчасындагы нефть урыннары турында Оренбург тау башлыгына белдермәсе. №3.

Надыр Уразмәтов биләмәсендә нефть урыннарының геодезия буенча укучы Павел Зубринский тарафыннан ясалган тасвирламасы. №2.

П.С. Паллас китабыннан өзек. №3.

***Олуг Татар иле***

*Норлан Балгынай.* Чәүчәккә сәяхәт. №3.

*Шәйхи Г.Ф.* Польша татарлары. №2.

*Гәрәева-Акчура А.Н.* Төркиягә күченүләр. №4.

***Ирек майданы: бәхәс клубы***

*Нәбиуллин Ф.М.* Халыкның җәрәхәте. №2, 3.

***Шәхесләребез***

*Гайнетдинова Г.М.* Татарның бөек улы Атнабай. №4.

*Закирова И.Г.* Луиза Себерле. №3.

*Маликов Р.И.* Танылган ишан Әхмәр хәзрәт Юнысны (1765–1810) искә алу кичәсендәге чыгыш. №4.

*Минһаҗ Р.Р.* Игелек эшлә дә суга сал. №1.

*Минһаҗ Р.Р.* Ялантауга ай кунган. №3.

*Тычинских З.А.* Төбәк тарихын өйрәнүче, каһарман. Гөлсинә Газизова турында. №4.

*Төхбәтуллина Н.Г., Мифтахов Л.Г., Көбәшев И.Г.* «Аһ! Бу нигә болай дисең...». №1.

*Фаткуллин Ф.М.* Лидерлар картлыкка бирешми. №2.

***Татар рухы***

*Айсин Р.В.* Бер хыянәтнең тарихы. №2.

*Батулла Р.М.* Чыңгыз хан. №1, 3.

*Галимова А.К.* Расти маҗаралары. №4.

*Гыйсметдин Д.М.* Демократия. №4.

*Курчаков Р.С.* Туган җирем – туган телем. №1.

*Хәйретдин А.Г.* Аллаһы тәгалә барлыкны нәрсәдән булдырган? №1, 2.

*Хәйретдин А.Г.* Корьәндә бәян ителгән реинкарнация тәгълиматына кереш. №3,4.

*Хәйретдин А.Г.* Катлаулы сорауларга гади җаваплар. №4.

***Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар***

*Гарифуллин И.* Башкортстанның Татар иҗтимагый үзәгенә – 30 ел. №4.

Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр форумы резолюциясе. №4.

Тарихи үзаң өлкәсендә Болгарның 1100 ел элек ислам динен кабул итүгә багышланган мөрәҗәгать. №4.

Угра елгасында Торуны бәйрәм итү уңаеннан мөрәҗәгать. №4.

Хроника. №1, 2, 3, 4.

***Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр***

Муса Абдуллинның «Ә наратлар шаулыйлар да шаулыйлар...» китабының аннотациясе. №4.

*Зөфәр Мәхмутовның.* «История татар Кокшетау и Акмолинской области» китабы турында. №2.

*Б.Р.Рәхимҗановның.* «Москва и татарский мир: сотрудничество и противостояние в эпоху перемен, XV–XVI вв.» китабы турында. №2.

*Сурметова Л.Р.* Ф.Йосыповның «Себер татарлары фольклоры антологиясе»нә бер күзәтү. №3.

Татарның бер Согыты. №1.

Түбән Абдулның данлы тарихы. №2.

*Б.Л.Хәмидуллинның.* «…Окаянная дщерь Златой орды…» китабына рецензия. №1.

Татарстан Республикасының торак пунктлары. №1.

*Т.Ф.Хайдаровның* «Эпоха «Чёрной смерти» в Золотой Орде и прилегающих регионах (конец XIII–первая половина XV вв.)» китабына рецензия. №1.

*Хәбипова З.Г.* «Карәбәк» романы турында. №4.

### ***Юбилярлар турында сүз***

Авызга су кабып яшикмени?! Р.Минһаҗ белән әңгәмә. №4.

### ***Хушлашу***

Милләтнең ак бае. №2.

Ул яшәргә тиеш иде... №3.

### ***Шигырьләр***

*Сабиров Нурислам.* Әби-бабайларга. №2.

*Шәйдуллина Р.Ш.* Оныкларга хат. №3.

*Әхмәтшина Миңзифа.* Тарих утлары. №4.

### ***Новосибирск өлкәсе татар иҗтимагый берләшмәләре буенча мәгълүмат***

«Новосибирск өлкәсе Татар мәдәният үзәге» Новосибирск өлкәсе дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе. №1.

«Новосибирск өлкәсе төбәк татар милли-мәдәни мөхтәрияте» иҗтимагый оешмасы. №1.

# СПИСОК МАТЕРИАЛОВ, ОПУБЛИКОВАННЫХ В ЖУРНАЛЕ В 2019 ГОДУ

Итоги года и задачи на будущее. №4.

***Путь в будущее: Татарская стратегия – 2050***

*Байрамова Ф.А.* Татарская стратегия: смута или последний шанс? №1.

*Гатауллин Р.Ф.* Механизм этновоспроизводства. №1.

*Искандяров Г.А., Лотфуллин М.В.* Пусть татары живут красиво! К стратегии развития татарского народа. №2.

*Мириханов Н.М.* Предлагаемые направления и темы для включения в «Стратегию развития татарского народа». №1.

*Надиров А.К.* Стратегия развития татарского народа. №2.

*Нигаматзянов Т.Т.* Видение общественной стратегии развития народа, татарского языка и культуры на 2020–2050 годы. №1.

Письмо в редакцию. №1.

Письмо в редакцию. №2.

Письмо разработчикам стратегии. №2.

Предложения представительств РТ в странах СНГ. №2.

Предложения представительств РТ в регионах РФ. №2.

Предложения для «Стратегии развития татарского народа» от председателя МООТНКА Люблинского района г. Москвы. №2.

Стратегия эффективного развития и роста жизненных условий сибирских татар Тюменской области «В будущее – с каждым днём!». №2.

Структура «Стратегии развития татарского народа». №3.

Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения

*Бакиров М.Х.* Наши корни из Булгар. №3, 4.

*Гатауллин Р.Ф.* Сущность и границы этнопространства. №3.

*Гатауллин Р.Ф., Аслаева С.Ш.* Основные контуры институционального развития Республики Башкортостан в 1990–2017 гг. №4.

*Измайлов И.Л.* Древние татары в Центральной Азии (VI–IX вв.). №2, 3.

*Исхаков Д.М.* Наша национальная история, запрятанная в эпических произведениях народа: Вторая публикация. Тайны дастана «Идегей». №1, 2.

*Исхаков Д.М.* Наша национальная история, запрятанная в эпических произведениях народа. Третья публикация: дастан «Чура батыр» и «предупреждение будущих поколений». №3, 4.

*Кыямов И.А.* Тонкости богоугодного наследия. №1.

*Мухаметзянова Л.Х.* С Идели или из Сибири ты, Идегей? №1.

### *Научные публикации по краеведению*

*Алексеев И.Е.* «Татарский след» в истории обретения Казанской иконы Божией Матери. №3.

*Амирханов Р.Х., Габдуллин И.Р.* Нефтепромышленник Надыр Уразметов и его время. №2, 3.

*Байрамова Ф.А.* История татар в Новосибирской области. №1.

*Байрамова Ф.А.* Татарская история на Самарской луке. №2, 3.

*Байрамова Ф.А.* Вклад М.Г. Худякова в историю Татарстана. №4.

*Бугарчёв А.И., Степанов О.В.* Клад-кошелёк монет XV века из окрестностей с. Большие Атряси (Тетюшский район Татарстана). №1.

*Бугарчёв А.И., Степанов О.В.* Джучидские монеты из деревни Маклашеевки (Татарстан). №2.

*Бугарчёв А.И., О.В. Степанов.* Нумизматические материалы из Алькеевского района РТ. №3.

*Бурханов А.А.* Памятники Иске-Казанского историко-культурного и природного комплекса. №1, 2.

*Гариф Н.Г.* Учет эпиграфических (надгробных) памятников периода Казанского ханства и их статистический анализ. №4.

*Голодяев К.А.* Древнее чатское поселение на территории Новосибирска и последний бой последнего сибирского хана. №1.

*Мухаметзянова Л.Х.* Легенды и мелодичные песни Самары. №2.

*Мухамметзянова Л.Х.* Особый вид искусства у астраханских татар – хушаваз. №4.

*Нуриева Ф.Ш.* Об использовании татарским народом терминов наименований годов, месяцев и дней в публикации Хасана Гали. №3.

*Саначин С.П.* Новые подробности обретения Казанской иконы богородицы и биографии Гермогена по двум лицевым повестям её явления. №3.

*Хисамов О.Р., Гумеров И.Г., Закирова И.Г.* На берегах Ангары есть такой город – Иркутск. №1.

*Худяков Ю.С.* Развитие государственности древних тюрок в раннем средневековье – важный этап в развитии тюркской цивилизации в степной Евразии. №1.

### *Краеведение в научно-популярных публикациях*

*Абдуллин М.М.* Сабы – моя история. №1.

*Аскаров Р.Р.* Кигинские Терегуловы. №4.

*Биккинин И.Д.* Эстонская жена татарского солдата из Пензенской губернии, XVIII век. №2.

*Биккинин И.Д.* Татарская зона начала XVII века в центре Мордовии. №4.

*Вали Р. К.* Что есть за Булаком? № 1.

*Газизов Р. Р.* Школа «Яктылык» городского округа Самара. № 2.

*Газизьянова С. М., Сабирьянова Ф. Ф.* Развитие татарского краеведения и туристический потенциал татарских сел Республики Марий Эл. № 4.

*Гариф Н. Г.* Если захочешь установить свою генеалогию. № 3.

*Гильманов Ф. М.* Пензенские татары в Чуракаево. № 3.

*Гимадеев М. М.* История села Старое Шаймурзино. № 3.

*Закирова И. Г., Мухаметзянова Л. Х.* На страже жемчужин народа. № 3.

*Махмутов Ф. С.* Самарские татары. № 2.

*Надиров А. К.* Мы открыли дорогу длиною в тысячи лет. № 2.

*Нигаматзянов Т. Т.* Клуб семи муз. № 3, 4.

*Салиев Р. З.* Возвращение в ислам. № 4.

*Сибгатова Э. М.* Герой Пугачевского восстания. № 2.

*Тажи Д. Н.* Киям Жагфаров: автобиографические воспоминания. № 1, 2, 3, 4.

*Хабибиуллин А. А.* Сохранение национального языка у татар Саратовского Поволжья в условиях меняющихся реалий XX–начала XXI вв. № 4.

*Хабипова З. Г.* О новой публикации дастана «Идегей». № 1.

*Хамзина Р. К.* Историческое поселение чатских татар. № 1.

*Хусаинов С. А.* Размышления по поводу ярлыка Сахип-Гирея. № 4.

### ***Наше историко-краеведческое наследие***

Дастан «Идегэ». № 1, 3, 4.

*Закирова И. Г.* Песни Айтука. № 1.

*Закирова И. Г.* Ак Күбек. № 4.

*Яхин Ф. З.* История «Книги Малики». № 1, 2.

### ***Известные личности***

Твори добро и ложи в воду. Интервью Р. Мингазова. № 1.

*Тухбатуллина Н. Г., Мифтахов Л. Г., Кубашев И. Г.* «Ах! Почему это так...». № 1.

### ***Исторические источники по краеведению***

Документальные материалы по татарам Томской губернии XVIII в. № 1.

Доношение геодезии ученика Павла Зубринского Оренбургскому горному начальнику о нефтяных местах в дачах Надыра Уразметева. № 3.

Описание нефтяных мест в дачах Надыра Уразметева ученика геодезии Павла Зубринского. № 2.

Отрывок из книги П. С. Палласа. № 3.

### ***Magna Tartaria***

*Норлан Балгынай.* Путешествие в Чаучак. № 3.

*Шайхи Г.Ф.* Польские татары. №2.

*Гараева-Акчура А.Н.* Переселения в Турцию. №4.

**_Площадь свободы: дискуссионный клуб_**

*Набиуллин Ф.М. Травмы народа.* №2, 3.

**_Известные личности_**

*Гайнетдинова Г.М.* Атнабай – великий сын татарского народа. №4.

*Закирова И.Г.* Луиза Сибирская. №3.

*Маликов Р.И.* Выступление на вечере памяти известного ишана Ахмера хазрета Юнусова (1765–1810). №4.

*Мингазов Р.Р.* Взошел месяц над Ялантау. №3.

*Тычинских З.А.* Краевед, подвижник. Слово о Гульсине Газизовой. №4.

*Фаткуллин Ф.М.* Лидеры не поддаются старости. №2.

**_Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики._**

Хроника. №1, 2, 3, 4.

Резолюция Всероссийского форума татарских краеведов. №4.

Обращение в честь памятной даты – 1100-летия принятия ислама Волжской Булгарией. №4.

Обращение по поводу празднования Стояния на р. Угре. №4.

*Гарифуллин И.* Татарскому общественному центру Башкирии – 30 лет. №4.

**_Татарский дух_**

*Айсин Р.В.* История одного предательства. №2.

*Батулла Р.М.* Чингиз хан. №1, №3.

*Галимова А.К.* Приключения Расти. №4.

*Гисметдин Д.М.* Демократия. №4.

*Курчаков Р.С.* Родная земля – родной язык. №1.

*Хайрутдинов А.Г.* Из чего создал Аллах бытие? №1, 2.

*Хайрутдинов А.Г.* Введение в учение о реинкарнации, изложенное в Коране. №3,4.

**_Слово о юбилярах_**

Жить, словно воды в рот набрали?! Интервью с Р. Мингазовым. №4.

**_Информация о краеведческих трудах. Рецензии._**

Аннотация книги Мусы Абдуллина «Ә наратлар шаулыйлар да шаулыйлар…». №4.

Населённые пункты Республики Татарстан. №1.

О книге Б.Р. Рахимзянова «Москва и татарский мир: сотрудничество и противостояние в эпоху перемен, XV–XVI вв.». №2.

О презентациях книги Зуфара Махмутова «История татар Кокшетау и Акмолинской области». №2.

Рецензия на книгу Б.Л.Хамидуллина «…Окаянная дщерь Златой орды…». №1.

Рецензия на книгу Т.Ф.Хайдарова «Эпоха «Чёрной смерти» в Золотой Орде и прилегающих регионах (конец XIII–первая половина XV вв.)». №1.

Славная история Нижнего Абдулово. №2.

*Сурметова Л.Р.* Обзор книги Ф.Юсупова «Себер татарлары фольклоры антологиясе». №3.

Татарские Сугуты. №1.

*Хабипова З.Г.* О романе «Карабек». №4.

***Некрологи***

Меценат – «Ак бай». №2.

Он должен был жить… №3.

***Стихи***

*Ахметшина Минзифа.* На костре истории. №4.

*Сабиров Нурислам.* Бабушкам и дедушкам. №2.

*Шайдуллина Р.Ш.* Письмо внукам. №3.

Информация о татарских общественных объединениях Новосибирской области

ГБУК НСО «Новосибирский областной Татарский культурный центр». №1.

ОО «Региональная Татарская Национально-Культурная Автономия Новосибирской области» («РТНКАНО»). №1.

## 2020 ЕЛДА БАСЫЛАСЫ БАСМАЛАР.
## ПУБЛИКЦИИ, ПЛАНИРУЕМЫЕ НА 2020 ГОД.

*Абдуллин М.М.* Сабам – тарихым минем. Тарихыбызны барлап.

*Алексеев И.Е.* «Чуваши … называют каменные орудия камнями бога Юмы – «Юман-ки», татары – «Яшень-Таш» – громовыми камнями…» (археологические изыскания профессора Н.Ф. Высоцкого).

*Бакиров М.Х.* «Идегәй» дастанына яңа караш.

*Батулла.* Мәңгелек «Сак-Сок».

*Бәйрәмова Ф. Ә.* Лашманда Исхакыйлар нәселе.

*Бәйрәмова Ф. Ә.* Казах даласында татар тарихы.

*Биккинин И.Д.* Туристический потенциал татарских сел Пензенской области и Мордовии и вопросы развития татарского краеведения.

*Вострякова Р.И., Худякова Н.С.* Олёкминские татары.

*Гаитов Анас.* Идеже прежде был град Чимги –Тура.

*Галимов Ф.Г.* Здравоохранение Спасского района в Советский период (1922–1991 гг.)

*Закирова И.Г.* Төмән өлкәсе Вагай районы фольклоры.

*Ибрагимов М.Х.* Социально-экономическая катастрофа в Башкирии: голод 1921–1923 гг.

*Ислаев Ф.Г.* Татарские тамги: происхождение и функции.

*Исхаков Д.М.* Из истории племени Кай: новый взгляд на средневековую историю татарского народа.

*Исхаков Д.М.* Сөембмкә ханбикә: тарихи шәхес һәм символик образ.

*Минһаҗ Р.Р.* Татар дастаннарында милли тарих.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Курган татарларында сакланган дастаннар турында.

*Нуриева Ф.Ш.* Татарстан Республикасының Чистай районы татар авылларында кулланылышта йөргән көн атамалары.

*Сәетов Р.Р.* Минзәлә районы Калморза авылы.

*Тажи Д.Н.* Кармыш авылы мисалында мөселман мәхәлләләре язмышы.

*Тажи Д.Н.* Кирлемар сөргенендә.

*Тажи Д.Н.* Лишуннар.

*Хаҗиева Г.С.* Авылым кушаматлары.

*Хаплехамитов Р.Б.* Интеллигенция и татарский язык в постсоветский период.

*Хәертдинова Р.Х.* Гасырлар кичкән авыл.

*Шәрифуллина Р.З.* Балачак эзләре буйлап.

*Яхин Ф.З.* О сибирском татарском поэте XIV века шейхе Икани.

*Яхин Ф.З.* Средневековые мамлюкские произведения, написанные на арабском Востоке XIII века на половецком языке.

## Авторлар буенча белешмә

**Аслаева Сәлимә Шамил кызы**, икътисад фәннәре кандидаты, РФА ӨФҮ СЭТИ фәнни хезмәткәре, Уфа.

**Бакиров Марсель Хәернас улы**, филология фәннәре докторы, КФУ профессоры.

**Биккинин Ирек Дамир улы**, төбәк тарихын өйрәнүче, журналист, юрист.

**Бәйрәмова Фәүзия Әүхади кызы**, тарих фәннәре кандидаты, язучы, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан язучылар берлегенең Идарә әгъзасы.

**Гайнетдинова Галия Михей кызы**, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә, Ә. Атнабаев исемендәге әдәби премия лауреаты.

**Газизьянова Сания Мансур кызы**, Мари Эл Республикасының Татар төбәк тарыхын өйрәнүчеләр берлеге рәисе.

**Галимова Асия Камил кызы**, тәрҗемәче, ТФАның Ш. Мәрҗәни ис. Тарих институты аспирантурасын тәмамлаучы.

**Гариф Нурулла Гыймадетдин улы**, тарих фәннәре кандидаты, педагогия хезмәте ветераны.

**Гарифуллин Ильнар Зөлфәт улы**, «Idel.Реалии» мәгълумати басмасының сәяси күзәтүчесе, тарихчы, политолог, тарих фәннәре кандидаты, дәүләт милли сәясәте һәм милли хәрәкәт мәсьәләләре буенча белгеч

**Гатауллин Ринат Фәйзлтдин улы**, икътисад фәннәре докторы, РФА ӨФҮ СЭТИ.

**Гыйсметдинов Дамир Минсәгыйрь улы**, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, сатирик-язучы, шагыйрь, танылган җырлар авторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, җәмәгать эшлеклесе.

**Гәрәева-Акчура Айзирәк Наил кызы**, журналист, публицист, ТР Журналистлар берлеге әгъзасы, журналистика һәм иҗади эшчәнлек өлкәсендәге премияләр лауреаты.

**Закирова Илсөяр Гамил кызы**, филология фәннәре докторы, ТФАның Г. Ибраһимов исемендәге ТӘСИның Халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре, гыйльми совет әгъзасы.

**Исхаков Дамир Мәүләви улы**, тарих фәннәре докторы, РТФА академигы, БТК Милли Шура әгъзасы, журналның баш мөхәррире.

**Маликов Рәшид Ильяс улы**, тарих фәннәре кандидаты, КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр иститутының өлкән фәнни хезмәткәре.

**Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы**, филология фәннәре докторы, доцент, ТФАның Г. Ибраһимов ис. ТӘСИның баш фәнни хезмәткәре, гыйльми совет әгъзасы.

**Нигъмәтҗанов Томас Тимерхан улы**, ТР һәм РФ журналистлар берлеге әгъзасы, «Теплоконтроль» акционерлар җәмгыяте Казан приборлар төзү предприятиесе баш метрологы.

**Таҗиев Дамир Нәзир улы**, РФ Журналистлар берлеге әгъзасы, Р. Төхфәтуллин исемендәге бүләк иясе, Әлмәт төбәгенең җәмәгать эшлеклесе, төбәк тарихын өйрәнүче.

**Тычинских Зәйтүнә Әптрәшит кызы**, тарих фәннәре кандидаты, РФА УрБның Тубыл комплекслы фәнни станциясе өлкән фәнни хезмәткәре.

**Сабирҗанова Фирзия Фәйслам кызы**, Мари Эл Республикасы Медведково районының Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе.

**Салиев Равил Зөфәр улы**, төбәк тарихын өйрәнүче, Россия Федерациясе Мактаулы гомуми белем бирү хезмәткәре.

**Хәбибуллин Артур (Али) Әхәт улы**, тарих фәннәре кандидаты, Саратов өлкәсе мөселманнары Диния нәзәратенең «Шейх Саид» мәдрәсәсе директоры урынбасары.

**Хәбипова Зәрия Габдулла кызы**, төбәк тарихын өйрәнүче, публицист җәмәгать эшлеклесе.

**Хәйретдинов Айдар Гарәфетдин улы**, фәлсәфә фәннәре кандидаты, доцент, ТФАның Ш. Мәрҗани ис. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

**Хөсәинов Салават Әнвәр улы**, төбәк тарихын өйрәнүче-тикшерүче, «РСУ-2 СантехРемМонтаж» ҖЧҖ техник директоры.

**Әскәров Рамил Рәхимьян улы**, тарихчы, төбәк тарихын өйрәнүче, БР Кыйгы районының төбәк тарихын өйрәнүчеләр берлеге рәисе, БР хәрби хезмәткәрләрне һәм аларның гаилә әгъзаларын социаль яклау комитеты идарә әгъзасы.

**Әхмәтшина Миңзифа**, төбәк тарихын өйрәнүче, шагыйрә, җ әмәгать эшлеклесе.

## Сведения об авторах

**Аскаров Рамиль Рахимьянович**, историк, краевед, председатель общества краеведов Кигинского района РБ, член правления Комитета социальной защиты военнослужащих и членов их семей Республики Башкортостан.

**Аслаева Салима Шамилевна**, кандидат экономических наук, научный сотрудник ИСЭИ УФНЦ РАН, г. Уфа.

**Ахметшина Минзифа**, краевед, поэт, общественный деятель.

**Байрамова Фаузия Аухадиевна**, кандидат исторических наук, писательница, общественный деятель, член Правления Союза писателей РТ.

**Бакиров Марсель Хаернасович**, доктор филологических наук, профессор КГУ.

**Гайнутдинова Галия Михеевна**, поэт, член Союза писателей РТ, лауреат литературной премии им. А. Атнабаева.

**Газизьянова Сания Мансуровна**, председатель Общества татарских краеведов Республики Марий Эл.

**Галимова Асия Камильевна**, переводчик, прошла аспирантуру Института истории им. Ш. Марджани АН РТ.

**Гараева-Акчура Айзиряк Наилевна**, журналист, публицист, член Союза журналистов РТ, лауреат премий в области журналистики и творческой деятельности.

**Гариф Нурулла Гыймадетдинович**, кандидат исторических наук, ветеран педагогического труда.

**Гарифуллин Ильнар Зульфатович**, Политический обозреватель информационного издания «Idel.Реалии», историк, политолог, кандидат исторических наук, специалист по вопросам государственной национальной политики и национальных движений.

**Гатауллин Ринат Файзлтдинович**, доктор экономических наук, профессор, ИСЭИ УФНЦ РАН.

**Гисметдинов Дамир Минсагирович**, заслуженный работник культуры Республики Татарстан, писатель-сатирик, поэт, автор популярных песен, член Союза писателей Республики Татарстан, общественный деятель.

**Закирова Илсеяр Гамиловна**, доктор филологических наук, главный научный сотрудник отдела народного творчества ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, член ученого совета.

**Исхаков Дамир Мавлявеевич**, доктор исторических наук, академик РАЕН, член Национального Совета Всемирного конгресса татар, главный редактор журнала.

**Маликов Рашид Ильясович**, кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Института международных отношений КФ(П)У.

**Мухаметзянова Лилия Хатиповна**, доктор филологических наук, доцент, главный научный сотрудник ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, член ученого совета.

**Нигаматзянов Томас Тимерханович**, член Союза журналистов РТ и РФ, главный метролог Казанского приборостроительного предприятия АО «Теплоконтроль».

**Тазиев Дамир Назирович**, краевед, член Союза журналистов РФ, лауреат премии имени Рафаила Тухватуллина, общественный деятель г. Альметьевска, сотрудник ООО «ТаграС-ХимСервис».

**Тычинских Зайтуна Аптрашитовна**, кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Тобольской комплексной научной станции УрО РАН.

**Сабирьянова Фирзия Файсламовна**, председатель Общества татарских краеведов Медведевского района Республики Марий Эл.

**Салиев Равиль Зуфарович**, краевед, Почётный работник общего образования РФ.

**Хабибуллин Артур (Али) Ахатович**, кандидат исторических наук, заместитель директора медресе «Шейх Саид» Духовного управления мусульман Саратовской области.

**Хабипова Зария Габдулловна**, краевед, публицист, общественный деятель.

**Хайрутдинов Айдар Гарифутдинович**, кандидат философских наук, доцент, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ.

**Хусаинов Салават Анварович**, краевед-исследователь, технический директор ООО «РСУ-2 СантехРемМонтаж».

# Туган җир

*Төбәк тарихы буенча журнал*

# Родной край

*Краеведческий журнал*
4’2019

Подписано в печать 22.11.2019 г. Формат 70×100 1/16
Усл. печ. л. 19,5 Тираж 1000 экз.
Отпечатано с готового оригинал-макета.
в типографии ООО «Грумант»
В данном номере журнала использованы фотографии из личных архивов авторов



Төбәк тарихын өйрәнүчеләр Новосибирск өлкәсендәге чат татарлары утарында. Л. Гобәйдуллин фотосы.



Томск шәһәренең Татар бистәсендәге татар баеның йорты. Л. Гобәйдуллин фотосы.



Бөтенроссия татар төбәк тарихы өйрәнүчеләр форумының секция утырышы. Томск шәһәре. Л. Гобәйдуллин фотосы.




ТРның Әгерҗе районы Иж-Бубый авылында Мөхлисә-Бубиның 150-еллыгына багышланган фәнни-гамәли конференция.



Мәскәү шәһәре Татар мәдәният үзәгендә Д. М. Исхаков лекциясеннән соң фикер алышу.




Казанда – быелгы Хәтер көне



Томск шәһәрендәге татар байларының йорт күренеше.
Л. Гобәйдуллин фотосы.


Игелекле һәм изгелекле
булсын
Яңа аяк басар яңа ел!